Безнен МИРАС
НАШЕ НАСЛЕДИЕ
05
май 2018
ISSN:2500-011X
ФӘННИ-ПОПУЛЯР, ӘДӘБИ-НӘФИС ҺӘМ ДОКУМЕНТАЛЬ ЖУРНАЛ

РӘШИТ ГОСМАНОВ. «ИДЕЛ МОҢНАРЫ»

ТАТАР МӨХӘРРИРЛӘРЕ – КАСТАМОНУДА

16-20 апрельдә Төркиянең Кастамону шәһәрендә IX нчы Халыкара төрки телле журналларның баш мөхәррирләре конгрессы булып узды. Евразия Язучылар берлеге (рәисе – Якуп Өмәроглы) ТЮРКСОЙ халыкара оешмасы белән бергә уздырган әлеге мәртәбәле чарада Татарстаннан да вәкилләр катнашты.

Каләм! Кальбеңдә ни сер бар – гаян ит,
Килеп кичмешләр әхвален бәян ит.

Дәрдемәнд

Безнең МИРАС

12 +

05 (293)

май 2018

1991 елның апреленнән башлап «Мирас», 2012 елның маеннан, «ТАТМЕДИА» АҖ тарафыннан кабат гамәлгә куелып, «Чын мирас» исемнәре белән чыкты. 2014 елның маеннан «Безнең мирас» итеп үзгәртелде.

110

18 *Ирек Һадиев, Раиф Мәрданов*
ИСКЕ ҖӨРИНЕҢ БОРЫНГЫ ЯДКӘРЕ

100 *Харис Закиров*
ӘТИЕМНЕҢ КҮРГӘННӘРЕ

ЭЧТӘЛЕК

ДӨНЬЯДА СҮЗЕМ КАЛЫР...

3 **Илдус Гыйләҗев**

ТАРИХИ МИРАС

4 **Нурсолтан.** *О.Иванова*
10 **Идел кичми ил булмас**
15 **«Каләм-е Шәриф»ме, әллә «Каләм Шәриф»ме?** *А.Хәйретдин*
18 **Иске Җөринең борынгы ядкәре.** *И.Һадиев, Р.Мәрданов*
22 **Олуг Мөхәммәд.** *М.Әмирханов*
27 **Кулатлы укулары**
30 **Халык язган китап.** *Э.Ихсанова*
34 **Меңьеллык тарихлы Яуширмә.** *Н.Фатыйхова-Потеева*
39 **«Немесчә аш».** *Э.Сәлахова*
43 **Русия мәмләкәтендә аутодафе.** *Р.Фәхретдинов*
46 **Маргарет ханым.** *С.Цвиклински*

ТАТАР ГАМЕ

48 **Безнең заман каһарманы.** *Р.Батулла*

ТӨРКИ ДӨНЬЯ

52 **Казакъ халкының мәшһүр улы**

ДИНИ МИРАС

54 **Ислам дөньясы.** *Г.Ибраһимов*
60 **Хаҗга озату догасы.** *Ж.Фазлыев*

ӘДӘБИ МИРАС

62 **Аяз Гыйләҗев һәм мин.** *Ф.Кутлу*
66 **Булат Сөләймановның ике гаризасы.** *Л.Лерон*

ОЧТЫ ДӨНЬЯ ЧИТЛЕГЕННӘН...

68 **Галимҗан Нигъмәти**

ХӘТЕР САНДЫГЫ

73 Шагыйрь Макс Гатау һәм аның туган авылы Тозау
76 Истә, һаман да истә!

СӘНГАТИ МИРАС

78 Әз-мәз үзем турында. *Р.Шәрәфи*
82 Чын иҗат кешесе. *Ю.Сафиуллин*

МУЗЫКАЛЬ МИРАСНЫ БАРЛАГАНДА

88 Җырлар артыннан илләр гизеп… *Э.Каюмова*

СУГЫШ КАЙТАВАЗЫ

93 Солдат бабай Миргазиз. *А.Гаделша*
100 Әтиемнең күргәннәре. *Х.Закиров*

ТЕЛ КҮРКЕ – СҮЗ

104 Миллият сүзлеге. *А.Тимергалин*

ХӘТЕР САГЫНДА

106 Татарстан Республикасының Милли китапханәсе
110 Затлы китап
112 Киез итекләр иле

116 «Безнең мирас» хәбәрләре
118 Мирасворд
119 «Безнең мирас» елъязмасы. *Май*

Баш мөхәррир
Лемон Лерон улы ЛЕРОНОВ
(Ләбиб Лерон)
(843) 222-09-83 (17-91)

Баш мөхәррир урынбасары
Ленар Гобәйдуллин
(843) 222-09-83 (17-91)

Киңәшче идарә
Разил Вәлиев
(ТР Дәүләт Советының Мәгариф, мәдәният, фән һәм милли мәсьәләләр комитеты рәисе)
Илдар Гыйльметдинов
(Татар федераль милли-мәдәни автономиясе Советы рәисе)
Айрат Зарипов
(Матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр буенча Республика агентлыгы җитәкчесе)
Андрей Кузьмин
(«ТАТМЕДИА» АҖ генераль директоры)
Рөстәм Мөхәммәдиев
(«Татнефть» ААҖ генераль директоры урынбасары, «Рухият» фонды рәисе)
Васил Шәйхразиев
(ТР премьер-министры урынбасары, БТК Милли Шурасы рәисе)
Лотфулла Шәфигуллин
(«ТАТТЕЛЕКОМ» АҖ генераль директоры)

Редколлегия
Ислам Әхмәтҗанов
Марсель Әхмәтҗанов
Ирада Әюпова
Альберт Борһанов
Рәдиф Җамалетдинов
Фәнзилә Җәүһәрова
Ринат Закиров
Фәйзелхак Ислаев
Зиннур Мансуров
Ким Миңнуллин
Гөлчәчәк Нәҗипова
Данил Салихов
Сөмбел Таишева
Рафаил Хәкимов
Ирек Шәрипов

Җаваплы мөхәррир
Фирдәвес Зарифуллин
(843) 222-09-83 (17-93)

Бүлек мөхәррирләре
Ләйсән Данилова
(843) 222-09-83 (17-92)

Дизайнер һәм биткә салучы
Диләрә Нәүрүзова
(843) 222-09-83 (17-93)

Корректор
Дания Фәйзуллина
(843) 222-09-83 (17-92)

Гомуми мәсьәләләр буенча мөхәррир
Рәдиф Сәгъдиев
(843) 222-09-83 (17-91)

Редакция һәм нәшрият адресы:
420066, Казан шәһәре,
Декабристлар урамы, 2 нче йорт
Электрон почта:
yanamiras@mail.ru

«Наше наследие»
Ежемесячный научно-популярный, литературно-художественный журнал (на татарском языке)

Заказ №Е-1007. Тираж – 2000 данә. Формат 70 X 108 1/16
Басарга кул куелды: 23.04.2018
Журнал айга бер тапкыр чыга. Бәясе иркле.

Журнал 2012 елның 17 апрелендә Федераль элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсендә ПИ №ФС77-57844 нче таныклык белән теркәлде.

Чыганак-текстларда авторларның стиле, шул чор лексикасы һәм орфографиясе саклана.
Мәкалә авторларының фикере редакция фикере белән туры килмәскә дә мөмкин. Редакциягә юлланган язмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый. Материаллар бары тик электрон вариантта гына кабул ителә. Журналга кергән язмаларны редакция рөхсәтеннән башка күчереп бастыру тыела.
Типография гаебе белән киткән хаталар өчен редакция җавап бирми. Андый хаталар булса, техник контроль бүлегенә 519-44-61 телефоны белән хәбәр итә аласыз.

Бу санда Л.Гобәйдуллин, Л.Лерон төшергән, авторлардан һәм Татарстан Милли музееннан, «Татар энциклопедиясе» томнарыннан алынган фотосурәтләр, җиде томлык «Татар тарихы»ннан рәсемнәр файдаланылды.

«ТАТМЕДИА» акционерлык җәмгыятенең «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылды. Адресы: 420066, Казан шәһәре, Декабристлар урамы, 2 нче йорт.

Тышлыкның 1 нче битендә – « Идел моңнары». *Рәшит Госманов рәсеме*

Илдус Гыйләҗев

(15.01.1946 –19.03.2018)

МҮКЛӘКЛӘР ИЛЕНДӘ

Кәеф-сафа корып яши торгач,
Кимеп куйса казна акчалары,
Бәрәкәтле Казан якларына
Килеп чыга Мәскәү патшалары.

«Ничек болар? Тиеш ясакларын
Вакытында түләп баралармы?
Бик тә сөзгәк иде бабалары...
Үзгәрмәде микән балалары?»

Ә балалар... күптән мүкләк сыер,
Мөгез урыннары яндырылган.
Карашыңнан куркып, дер калтырап
Тора торган итеп калдырылган.

Кирәк, дисәң, илтеп бирәчәкләр
Үзен, кызын, улын, туганнарын.
Агызалар алып байлыкларның
Җир астында хәтта булганнарын.

Тынычланып китә «атакайлар»:
«Килер җире иркен мөлкәтләрнең».
...Исәнлеген бирсен илен сатып
Көн күрүче өркәк мүкләкләрнең... ■

НУРСОЛТАН

Ольга Иванова

Тәрҗемәчедән

Ольга Ефимовнаны бу тарихи трилогияне язарга нәрсә этәргән соң? «Казанский альманах» журналындагы әңгәмәсендә ул моны кече яшьтән үк тарихка һәм әдәбиятка булган мәхәббәте белән аңлата. «Мәктәптә укыганда шул ике фән иң яратка映нарымнан булды. Әдәбият, тарих дәреслекләрен җәй көне үк кат-кат укып куя идем», – ди ул. «Тарих укытучысы белән, ул исенә килеп, утыр, минем әле башкаларны да тикшерәсем бар, дигәнче гәпләшә идем», – дип өсти. Сабыйлык-үсмерлек еллары кирәкле китапны табуы кыен булган чорга туры килгәнлектән (күптомлыкларны да «итәк астыннан» гына таратканнары ул буынның хәтерендә әле), кулына ни эләксә, шуны алып укыган. Мәсәлән, Толстойның «Сугыш һәм солых» романын, әле байтак өлешләрен соңыннан аңларга калса да, өченче класс баласы чагында «йотып» куйган ул. Үсә төшкәч, тарихи романнар Ольга Ефимовнаның күңел киштәсендә иң мәртәбәле урынны алган. Менә шуңа күрә дә, иҗатка тартылу, язу дәрте уянгач та, тарих үзе аның каләменә «уралган». Ә татар тарихына аерым мөнәсәбәте, алда әйткәнебезчә, ана сөте белән кергән...

Мөдәррис Вәлиев

Дәвамы. Башы журналның 1 нче (2018) санында.

Берәр сәгатьтән, берүзенә артык зур булып тоела башлаган киң түшәгендә яткан көе, Мәхмүд, уйлары белән, Сәрби ханша хәбәр иткән нәрсәләргә әйләнеп кайтты. Өлкән хатыны алдында тыныч һәм битараф булып кылану аңа җиңел түгел иде. Өлкән бикәсенең сүзләре аның газаплардан арыган йөрәгенә хәнҗәр булып кадалды. Чынлыкта бу кичтә бакчада нәрсә булды икән соң? Аның хакыйкатьне бик тә беләсе килә иде! Шашынган хатыннар уйлап чыгарган яки фараз иткән генә түгел, ә чыннан да булган дөреслекне. Ул Нурсолтанның Хәлилгә хыянәт итүенә ышанмый. Ханның күңеле сизә: кече солтанша мондый түбәнлеккә төшмәс. Ләкин моны Ибраһим эшли ала! Хан белә: икенче улының канында ана сөте белән кергән кара көнчелек бар. Хәзер ул, күптән, малай әле бәләкәй чагында ук, Ибраһимны явыз анасыннан аерып, Камал бикәнең әшәке сулышы күңелен аздырырга өлгергәнче, читтә тәрбиялисе булган, дип, бик үкенә. Шул хатын Ибраһимны, сиңа тиешле бар нәрсәне Хәлил алып бетерде, дип сихерләргә өлгерде, улын кече яшеннән үк, көчсез-зәгыйфь Хәлил үсмер булганчы да яшәмәячәк, Казан тәхетенә аның аягы беркайчан да басмаячак, дип ышандырды. Хан таҗын инде ул әллә кайчан үз улының башына үлчәп куйды һәм хәтта хәзер дә, ире сөргенгә җибәргән ерак биләмәдә яшәгән хәлдә дә, бу мәкерле бикә Ибраһим белән астыртын гына хәбәрләшеп тора, аны, теләсә нинди юл белән, иң югары хакимияткә ирешергә котыртып ята.

Мәхмүд хан бу турыда белә, аның шымчылары инде әллә ничә тапкыр Камал ханшаның дошманлык сөреме белән ысланган һәм улын көч куллану юлына этәргән хатларын кулга төшереп китерделәр. Ибраһимның да тынычланмавын, атасы карары белән килешмәвен белә хан. Кече угыл хакимияткә ирешү турында көн-төн хыяллана, атасы үлү белән, Казан тәхетен Хәлилдән тартып алырга тели. Ә инде тәхетне агасыннан алу турында хыяллана икән, нигә әле аның хатынын да, бигрәк тә Нурсолтан кебек акыллы сылуны, кулга төшерү теләге белән янмаска, ди. Карт хан арыган күзләрен учы белән каплады. Ул тартып барган йөк нинди авыр! «Йа Ходам, бу эшемне башкарып чыгарга ярдәмеңнән ташлама, хаталанмаска булыш, гаделсезлеккә юл куйма!» Шулчак йөрәге кыса башлады, ул бер кулын җайлап кына күкрәк турысына күчерде, әмма авырту барыбер кимемәде, рәхимсез тырнакларын тагын да тирәнрәк батырган кебек булды, ә ханның башында өметсез бер уй гына бөтерелде: «Әгәр бу төндә яткан җиремдә үлә калсам, ул чакта Хәлилем, Нурсолтан, Казаным белән ни булыр?.. Йа, мәрхәмәтеңне күрсәт, сакла бу илне, якын кешеләремне, кодрәтле Аллаһ! Бу төнне чыгарга ярдәм итә күр!»

***

Сәрби ханша төнката авыр төшләрдән газап чигеп ятты, әллә ничә тапкыр бастырылып алды, ә иртә таңнан торып мунчага барырга ниятләде. Зәвык белән эшләнгән Шәрык мунчасының иркен һавасы тәнне вә җанны аруландырырга, тынычландырырга тиеш булганлыктан, аның исәбе – анда Нурсолтанны да, хаким ире әйткән тыюларны да онытып тору иде. Ләкин тынычсыз үткән төн ханшаның башында яңа шикшөбһәләр генә уятты: «Нишләп әле бөек хан хәтта хәзер, хатын-кыз гына кыла ала торган гөнаһларның иң әшәкесен исбатлаганнан соң да, шул нугай фахишәсен яклый? Мәхмүд хан килененә үзе гашыйк булган, дигәнне аңлатмыймы икән соң бу?!»

Шундый уйлардан Сәрби ханшаның башында каны кайнады, ул хезмәтчеләр озатуында ничек итеп хан мунчасына барып кергәнен дә хәтерләми диярлек иде. Менә инде Казан ханбикәсе мунча алдында, кинәт авыраеп киткән кулларын түбән төшереп, җитез хезмәтче кызларның үзен чишендергәнне дә тоймаслык, хуҗабикәнең күңелен

күрү өчен, аларның төрлечә сайрашуларын да ишетмәслек дәрәҗәдә исәңгерәп утыра...

Мунча эчендәге пар, үтә күренмәле йомгаклары белән, ханшаны чорнап алгандай булды, әмма бу да шактый олы яшьтәге хатынны туктата алмады. Чөнки анда, кулларына балчыктан ясалган кечкенә чүлмәкләр тоткан хезмәтче кызлар бөтерелеп йөргән пар эчендә, Нурсолтан үзе күренде. Чүлмәкләрдән үлән кушып төнәтелгән бал исе таралган иде. Килененнән авыр карашын алмыйча, Сәрби ханша түземсезләнеп бармакларын шартлатты һәм кызларны ишеккә таба куган ишарә ясады. Тегеләр исә шунда ук, җил өргәндәй, күздән югалдылар. Хәтта сулышны кысарлык пар эчендә, эсселек ялмап алган бүлмәдә дә Нурсолтан хәрәмханәнең өлкән бикәсеннән бөркелгән нәфрәт утын тоймый калмады. Хәер, үзен башта ук сөймәгән каенанасының шундый мөнәсәбәте кайчан да булса ачыктан-ачык ызгышка китерәсен ул күптән сизеп йөри иде. Сердәш булырга тиешле әлеге хатын – Хәлилнең әнисе белән һичничек уртак тел таба алмавына гел эче пошты Нурсолтанның. Сәрби ханшаның аңа мөнәсәбәте – ананың улын башка хатын-кыздан гадәти көнләве генәме, әллә моның тагын нindидер хикмәте бармы икән, дип баш ватты.

Нурсолтан, тыныч булырга тырышып, эскәмиядән торды да кечелекле тавыш белән:

– Ханым-әфәндем, Аллаһ Сезнең кайгы-хәсрәтләрегезне миңа алу мөмкинлеген бирсен иде, – дип эндәште. – Бик алҗыган төсле күренәсез, бүген яхшы йокладыгызмы соң?

Теләсә нинди бүтән сүзләр әйтсә дә, алар Сәрби ханшаны болай ук шартлар хәлгә җиткермәс иде. Тагын да ныграк кызарынып-бүртенеп, тәхет варисының анасы акырып җибәрде:

– Ә син, тәмуг кисәве, күрәсең, бик шәп йоклагансыңдыр! Бер көн эчендә ике ирнең мәхәббәт алмасыннан авыз итүне синдәй уйнашчы хатын гына булдыра ала! Ибраһимның кочагыннан чыгып кайткач, иреңә ничек бер гөнаһсыз булып күренә алдың да ничек, оялмыйча, аның күзләренә карадың?!

Нурсолтан каенанасының ярсуыннан һәм аңа көтмәгәндә ябырылган гаепләүләрдән өнсез калды. Сәрби ханшаның болай ут чәчүе ни сәбәптән, нинди хыянәт, нинди уйнаш турында сөйли ул? Яшь хатын, әлбәттә, аның Ибраһим исемен атавын ишетми калмады! Ибраһим... Шунда ук кичәге очрашулары, иңрәүләрдән буыла башлагач, ирнең, аны юатырга тырышып, үз кочагына алуы исенә төште. Димәк, шулвакытта кемдер аларны бакчада күреп калган да моңа бөтенләй бүтән мәгънә салган, ә хәзер инде бу турыда Сәрби ханшага да мәгълүм булган. Нурсолтан, каенанасының ярсуыннан, аңа да килеп ирешкән гайбәтләрдән ышыкланырга теләгәндәй, киндер сөлгесен ирексездән күкрәгенә ныграк урап, аның бер почмагын каты итеп кысты. Йа Аллаһ, әгәр бу турыда Хәлилгә һәм ханның үзенә үк билгеле булса? Нишләргә соң аңа, үзен ни рәвешле тотарга, гаепсез икәнлеген ничекләр генә исбатларга?!

Ә Сәрби ханша исә, чабыну бүлмәсенең кайнар һавасын йодрыклары белән дер селкетеп, җикеренүен дәвам итте:

– Башыңа Аллаһның ачы каһәре яусын, азгынлыгың сиңа кәфен булып ябырылсын! Ләгънәт төшкере фәхеш кызы, кыяматкәчә рәхәт күрмә! Улым белән бөек ханның күзләрен будың! Ул бичаралар йөрәкләренә кемне якын итеп керткәннәрен күрмиләр!

Сәрби ханша, килененең яклаучысыз бугазына ябышыр өчен, комсыз кармак кебек кәкрәйгән бармакларын алга сузып, котырынып, яшь хатын өстенә килә иде. Ишек киңлегендәге гәүдәсе белән бердәнбер чыгып котылу юлын да каплаганлыктан, куркып калган Нурсолтан, бу аяусыз кысрыклаудан чигенергә мәҗбүр булып, бер мизгелдән аркасының кайнар тамчылар белән капланган диварга килеп терәлүен тойды. Хәлилнең анасы, ачудан кыйшайган йөзен ыржайтып, почмакка кадакланган киленгә таба атлады,

алагаем кизәнде, тик кинәт кенә йөзе тагын да кызарынды һәм симез карчык, ачык авызыннан һичбер аваз чыгара алмыйча, чабыну бүлмәсенең кызган һавасын уртлады да идәнгә ишелеп төште.

Бу хәлдән югалып калган Нурсолтан бака сыман җәелеп яткан гәүдәне күздән кичерде, ләкин шунда ук үзен кулга алып, әлегәчә карчык каплап торган имән ишеккә ташланды. Гамьсез генә гайбәт сатып торган хезмәтче кызларны күреп, шунда ук аларны орышып ташлады.

– Хуҗабикәгез бәхетсезлеккә юлыкты. Агач төпләре кебек тырпаеп баскансыз, тизрәк имче карчыкны алып килергә йөгерегез! Ә калганнарыгыз аны мунчадан алып чыгарга булышыгыз, ханшага саф һава кирәк! Тизрәк кыймылдагыз әле, һәр минут исәптә бит!

Чишенү бүлмәсендә имләүче әби күренгәч кенә, Нурсолтан җиңел сулап куйды. Имченең нык тавыш белән биргән күрсәтмәләре барысын да бераз тынычландырды. Ханшаны җәймә белән төреп, хатын-кызлар ягына күтәреп чыктылар. Анда инде аны хан гаиләсен дәвалаучы табибә көтеп тора иде. Ә Нурсолтан үз бүлмәсенә кайтып китте. Исәбе – тынлык-тынычлык эчендә үз башына килгән бәлане аңларга иде, әмма иң элек кол кызны Сәрби ханшаның хәлен белешергә җибәрде. Кыз көтелмәгән хәбәр алып кайтты: табибә, ханшаның миенә кан сауган булырга тиеш, ул көч-хәл белән генә селкенә, дигән.

Нурсолтан ирен эзләргә чыкты. Аңа теләктәшлек итү, хәленә керү бу мәлдә никадәр кирәклеген аңлый иде ул. Хәлил солтан бакчада икән. Хан тәхетенең варисы басынкы һәм тыныч булып күренде, тик аның күзләрендә яңадан хәсрәт һәм сагыш уты көйрәгәне генә сизелде. Хатынга дөньяның кызыгын тапмаган мондый кыяфәт, арыган кебек сыгылган арка, яшәргә һәм көрәшергә теләмәү билгеләре таныш иде. Хәзер ир үзенең элеккеге, ярты ел элек Нурсолтан белән очрашканчы булган төсенә кире кайткан. Купшы чәчәкләргә күмелгән куаклар артына яшеренеп аны күзәткәндә, яшь хатын, нәүмизләнеп, иреннәрен тешләде. Барысы да: озын-озак әңгәмәләр, атасы оештырган хисапсыз мәҗлесләр, аларның икәүләшеп Хәлилгә үз-үзенә ышанычын арттыруда, аның дәүләт башында торырлык ир буларак фикер йөртүенә ирешү өчен тырышлык куюлары юкка гына булдымы икәнни соң?! Чираттагы уңышсызлык яки бәла-каза булсын гына, Хәлил шунда ук үз эченә, үз кичерешләренә йомылырга тора.

Нурсолтан бу мәлдә яшеренгән урыныннан чыгып ире каршысына басарга базмавын аңлады. Солтанның анасы аның йөзенә ташлаган гаепләүләр, әйтерсең лә пот-пот герләр сыман, аякларын җиргә богаулап куйды. Хәлилнең әлеге халәте әнисе авырып китүгә түгел, Нурсолтан турында шул мәгънәсез чыш-пышлар килеп ирешкәнлектән түгелме икән? Мәхмүд хан моны һичкайчан гафу итмәячәк инде! Никадәр оят! Бер гаебе булмаган килеш... Шуңа күрә ул акланырлык сүзләр дә таба алмый... Нурсолтан үзен Хәлил каршына ниндидер көч тартып чыгарганын аңышмый да калды, тагын бер мизгелдән ул ире алдында тезләнеп тора иде. Хәзер инде Хәлил аннан көткән тынычландыру сүзләренә хатын үзе мохтаҗ. Нурсолтанның күз яшьләре белән мөлдерәмә күзләре иреннән каһәрләү, нәфрәт яки кичерүне көтә... Ә Хәлил кинәт аның белән янәшә тезләнде дә сүзсез-тынсыз гына хатынының җилкәсенә башын төртте. Ефәк күлмәген кайнар яшьләр чылатканын тойды Нурсолтан, ирнең ашыгып пышылдау сүзләре колагын өтеп алды:

– Нурсолтан! Әнием... ул үлмәсме?

Яшь хатын, көтелмәгән көч тоеп, иренең йөзен үзенә тартты, иреннәре белән үбеп, аның яшьләрен йотты:

– Аллаһ андый хәлгә юл куймас, Хәлил, без аның өчен дога кылырбыз!

Ә үзалдына ул бүтән уйга бирелде: «Йа Илаһым, пычрак гайбәтләр әлегә иремә килеп җитмәгәне өчен сиңа мең рәхмәт укыйм. Алга таба да мине мәрхәмәтеңнән ташлама! Явызлыкның тантана итүенә юл куйма!»

***

Икенче көнне иртүк Нурсолтан Мәхмүд хан хозурына чакырулы иде. Хан бусагасыннан беренче тапкыр яшь йөрәгендәге куркуны баса алмыйча атлап керде ул. Бу ишек артында аны ни көтә: ханша ташлаган гаепләүләр һәм мыскыл итүләр кебек, башкайга бәрә-бәрә яуган утлы-бозлы яңгырмы, әллә, моңа кадәр булганча, ата белән кызның ихлас әңгәмәсеме?

Карт хан киленен һәрвакыттагыча ачык йөз белән каршы алды. Саулыгы белән кызыксынды. Нурсолтан, хакимгә күзләрен күтәреп карарга кыенсынып, ишетелер-ишетелмәс тавыш белән генә җавап кайтарды. Мәхмүд яшь хатынның үз-үзен тотышындагы бу үзгәрешне шунда ук сизеп алды.

– Сине нәрсәдер борчыймы, кызым? Бәлки, безнең уртак эшләр белән шөгыльләнергә керешкәнче, сөйләшеп аласың киләдер?

Ханның теләктәшлек белән тулы бу сүзләре Нурсолтанны, менә-менә яңа гына чабып җибәрәселәрен көткән шикелле, кәнәфидә тагын да киеренкерәк, куырылыбрак утырырга мәҗбүр итте. Ул, бик авырлык белән генә кыюлыгын җыеп, Хәлилнең атасына күзләрен күтәреп карады.

– Хуҗам... мин...

Үз сүзләрендә буталып, әлегә хәтле бер читен уып торган кисея япманы хәлсезләнеп калган кулыннан төшереп җибәрде. Көтмәгәндә, күзеннән яшь бәреп чыкты.

Мәхмүд хан авыр сулап урыныннан кузгалды, яшь хатынга елаудан туктар өчен беркадәр вакыт биргән кебек, кулларын артка куеп, уйчан төс белән бүлмә буйлап йөренеп алды.

– Синнән берни дә сораштырырга теләмим, Нурсолтан, – дип, килене янәшәсенә басып, салмак кына сүзен ялгап китте ул. – Кайчандыр сиңа ышаныч ишекләремне ачканмын икән, хәзер инде мин аларны ябарга җыенмыйм. Юкка гына үзеңне газаплыйсың, икеләнүләрең сине көчсезләндерә, кызым, ә сиңа көчсез булырга ярамый. Син икеләтә көчле булырга тиешсең, – үзең өчен дә, Хәлил өчен дә. Моны һәрвакыт исеңдә тот, Нурсолтан! Ялган белән яла безнең күңел чишмәләрен агулый. Тормышны түзеп булмастай итәргә сәләтле алар, әмма синең бурычың – түзү, авырлыклардан өстен булып калу. Кара әле миңа, кызым! – Хан буйсындыра торган көчле кулы белән Нурсолтанның яшькә манчылган йөзен күтәрергә мәҗбүр итте. – Бүтән беркайчан да мин күз яшьләреңне күрергә тиеш түгел! Мин сиңа көчле булырга әмер бирәм!

Ханның боерулы тавышына ирексездән буйсынып, шул ук вакытта кинәт кибеп өлгергән күз яшьләреннән йөзе янганын тоеп, Нурсолтан кәнәфидән күтәрелде. Куллары белән битен сөрткәләде, шулай итеп, иреннәре калтыравын да, кипкән тамагыннан тибеп торган сулкылдавын да берьюлы баскан кебек булды.

– Бер генә киңәш бирегезче, хакимем: язмыш шаяруларыннан ничек сакланырга мөмкин? Әгәр агулы, әшәке исле бу имеш-мимешләр минем иремә – Хәлил солтанга барып ирешсә, нишләргә миңа?!

Нурсолтанның тавышы дулкынланудан тетрәнүле иде, шуңа күрә хан, аны тынычландырырга тырышып, кулларын үзенең бирчәйгән каты учларына алды.

– Хәлил һич тә җүләр түгел, кызым. Әгәр гайбәт сүзләре аңа барып җитсә, ул бу ялганга һичкайчан ышанмаячак. Ә син рухыңны ныгыт һәм бернидән дә курыкма, –

Мәхмүд хан, баш кагуы белән кәнәфигә ишарәләп, Нурсолтанны утырырга чакырды.

– Бүген иртән мин Ибраһим солтанны, даругаларны тикшереп кайту өчен, сәфәргә җибәрергә куштым. Кече солтанны ел ахырына кадәр башкалада күрә алмабыз, дип уйлыйм. Мин моны гайбәт капчыкларының авызын бәйләр өчен генә түгел, Ибраһимның Казаннан мөмкин кадәр ераграк булуын теләгәнемә күрә эшләдем. Ул – Хәлилгә куркыныч янаучы көчле көндәш! Ә мин әҗәл сулышын торган саен ешрак тоям. Таңнарның берендә уяна алмавым бар, шулчакта, Нурсолтан, без уйлаганнарның барысын да башкарып чыгу өчен синнән зур ихтыяр көче таләп ителәчәк.

– Әмма, хуҗам, Сез миңа артык авыр бурыч йөкләмисезме, мин бит бары хатын-кыз гынамын.

– Син ялгызың булмаячаксың, таянычың булырдай бер кеше белән таныштырып калдырырмын. Ул – мин ышанган, Казан тәхетендә, минем шикелле үк, Хәлилне күрергә теләгән зат. Уйлыйм ки, үзара киңәш-уңаш итеп эшләсәгез, икегезнең көчегез бергә кушылып, теләсә нинди явызлыкның муенын бора алырсыз.

Нурсолтан, карт ханның сүзләреннән уянган кызыксынуын җиңә алмыйча, урыныннан купты.

– Кем соң ул кеше, ханым-солтаным?

Мәхмүд хан елмайды:

– Син аны хәтерләргә тиеш, кызым. Әйтер идем, синең аркаңда аның башы муеныннан аерыла язды, ул ярты ел гомерен җәбер күреп яшәде. Әмма бу аның күңелен каралтмады, миңа һәм улым Хәлилгә тугрылыгын үзгәртмәде...

Мәхмүд хан килененә таба атлады, кискен кул хәрәкәте белән тагын аның башын күтәрергә мәҗбүр итте, күзләрен кысып, яшь хатынның куерып киткән зәңгәр күзләренә текәлде:

– Миңа беркем дә каршы сүз әйтә алмый, Нурсолтан! Сиңа шикләреңне калдырырга боердым, мин хәзер Хәлил турында гына уйлавыңны телим...

– Мин бит аның турында гына уйлыйм да инде!

Хатынның күтәренке тавышы ханны ярты сүздә бүленеп калырга мәҗбүр итте һәм ул көтелмәгән бу җаваптан тынып калды. Соңгы елларда Мәхмүд хан кем дә булса аның нотыгын бүлдерергә батырчылык иткәнен хәтерләми иде. Ул әлеге шактый четерекле хәлгә ничек карарга икәнен уйлап өлгергәнче, Нурсолтан яңадан аның фикерләреннән алга йөгереп чыгып дәвам итте:

– ...Хәлил әнисенә артык бәйле. Кичә миңа аны, Сәрби ханым һичшиксез савыгыр, дип сәгать буе тынычландырырга туры килде. Әмма хакыйкатьнең күзенә туры карыйк, хуҗам... Хәлилгә бу гайбәтләрне ишеттермәсләр, дигән ныклы ышанычым юк... Бу яктан тыныч була алмасам, Сез уйлаган эшләрне башкарып чыга алмам, дип куркам...

Колакларны чыңлатырлык тынлыкта бары күпмедер вакыт узганнан соң гына ханның авыр адымнары яңгырады, ә аннары аның тонык, калтыравыклы шикелле тоелган тавышы ишетелде:

– Ихтимал, син хаклысыңдыр да, Нурсолтан, төрле гауга купканын комсызланып көтеп торган гайбәт капчыкларын бәйләп куяр өчен әллә ни эшли алмаганмын шул. Күрсәтмәләрем һәм боерыкларымның гына көче җитмәгәндер. Тик син бер нәрсәдә тыныч була аласың: ул хатыннарның берсе дә хәрәмханәдән читкә чыга алмады. Баш хәрәм агасына шундый әмер бирелгән иде.

Дәвамы бар ■

Идел кичми ил булмас

*3-5 апрельдә Казанда II Бөтенроссия татар авылларын һәм төбәкләрдәге татар тарихын өйрәнүчеләр җыены узды. Бу чарада Россия Федерациясенең 35 регионыннан, Татарстан Республикасының 43 районыннан, Казан һәм Чаллы шәһәрләреннән 374 вәкил катнашты. Игътибарыгызга «Татар төбәк тарихын өйрәнүчеләр җәмгыяте» иҗтимагый оешмасы рәисе **Альберт Борһанов**, «Россиянең татар авыллары» иҗтимагый оешмасы җитәкчесе **Фәнир Галимов** һәм Азнакай муниципаль районы башлыгы урынбасары, Азнакай төбәк тарихын өйрәнүчеләр җәмгыяте рәисе **Нәҗәт Нәгыймов**ларның чыгышын тәкъдим итәбез. Төбәкне өйрәнүче башка белгечләребез сөйләгәннәр яки язган хезмәтләр белән журналыбызның алдагы саннарында танышырга мөмкин булачак.*

Альберт БОРҺАНОВ:
«Татар төбәкчелек мирасы зур кызыксыну уятты»

– Соңгы ике елда без, әйдәп баручы галимнәр белән берлектә һәм җирле хакимиятләрнең булышлыгы белән, күп кенә чаралар үткәрүгә ирештек. Болар – Халыкара, Бөтенроссия һәм төбәк күләмендәге конференцияләр. Татарстанның үзендә генә дә 22 шундый чара узды һәм аларның материалы басылып та чыкты.

Конференцияләрне ТАССРның 100 еллыгына, башка күренекле дата һәм юбилейларга, Экология елына багышлап үткәрдек. 2017 елның 23-24 май көннәрендә Азнакай шәһәрендә «Кеше һәм Көнчыгыш Татарстан табигате. Югалган тарихи авылларны өйрәнү, торгызу проблемалары» дигән темага Икенче Бөтенроссия конференциясе чит ил һәм Россия галимнәре катнашында үткәрелде. Азнакайда шушындый ук масштаблы конференция 2014 елда да булган иде. Шулай ук Сарабиккол авылы, Лениногорск, Чирмешән, Бәйрәкә, Әлки, Биектау, Яшел Үзән, Аксубай һәм башка районнарда тирән эчтәлекле конференцияләр булып үтте. Бу җәһәттән район башлыклары М.З.Шәйдуллин һәм Ф.М.Дәүләтшиннарга аерым рәхмәтемне җиткерәм.

Татарстан Дәүләт Советы һәм Казан педколледжы базасында, республикабыз районнарында Бөек Ватан сугышы, совет чоры тарихы проблемаларына багышланган конференцияләргә зур игътибар бирелде.

Тәтеш районының Әтрәч, Чүпрәледәге Мунчали, Аксубай районының Татар Майнасы авылында, Азнакайның Чатыр Тавында үткәрелгән бәйрәм һәм конференцияләр җирле халыкта да, фәнни җәмәгатьчелектә дә зур кызыксыну уятты.

Яшьләр өчен оештырылган чаралардан Кукмара районындагы «Үтәмеш укулары»н, Актаныш районындагы «Агыйдел» яшьләр лагеренда узган конференцияне атап үтәсем килә.

Кышкар авылы тарихы турындагы китапның авторлары Ләйсән Шәфыйгуллина һәм Гөлнара Ибраһимова

Шулай ук археология, эпиграфик, архитектура ядкәрләрен өйрәнү буенча кыр тикшеренүләренә дә зур игътибар бирелде. Без – галимнәр бу эшне хакимият булышлыгы белән алып барабыз һәм фәнни-тикшеренү процессына җирле укытучыларны, төбәк тарихчыларын, музей хезмәткәрләрен, аспирантларны, студентларны, мәктәп укучыларын җәлеп итәргә тырышабыз. Табышлар, фәнни яктан өйрәнелгәннән соң, район, мәктәп музейларына тапшырыла. Шул рәвешле без Кукмара, Апас, Тәтеш, Яшел Үзән, Сарман, Мөслим, Азнакай районнары музейларын өр-яңа экспонатлар белән баеттык. Бу материаллар, фәнни мәкаләләр төрле җыентыклар, төбәк тарихына багышланган китаплар өчен дә чыганак булды. Шуның өстенә элегрәк табылып, хәзер музейларда сакланучы экспонатлар да яңадан өйрәнелде. Тупланган материаллар нигезендә төркиләр тарихына кагылышлы халыкара конференцияләрдә докладлар ясалды. Әйтик, Истанбул, Әнкара, Баку, Таулы Алтай, Абакан, Мәскәү, Уфа, Казанда үткән чараларда татар төбәкчелек мирасы зур кызыксыну уятты.

Китаплар бастыру – төбәкне өйрәнүчеләр эшендә иң мөһим юнәлешнең берсе. Алар үзләренең күләме ягыннан да, фәнни тирәнлеге җәһәтеннән дә төрле, ләкин барысы да кирәкле һәм файдалы. Мәсәлән, Ф.Вәлиәхмәтов үзенең пенсия акчасына алты китап бастырып чыгарды. А.Сөнкишев «Апас энциклопедиясе»нең өч томын нәшер итте. Шулай ук Г.Мөхәммәтшин, М.Туйкина, Р.Абзалова-Сәлмәнова, Р.Әмирханов, А.Ямаев, И.Кыямов, Я.Шәмсетдинов, М.Гарипов, Д.Тажиев, Н.Гариф, Т.Нигъмәтҗанов, Ф.Ислаев кебек энтузиастларыбыз да бар. Күп китап хакимият башлыклары, эшкуарлар һәм сәнәгать оешмаларының җитәкчеләре ярдәме белән дөнья күрә. «Туган җир» журналының чираттагы саны басылып чыгу бу юнәлештә мөһим бер адым булды.

Фәнир ГАЛИМОВ:
«Безнең китап Уфада икенче урынны алды»

– Төмәнәктә 1200дән артык кеше яши, авыл көннән-көн зурая, үсә. Соңгы мәгълүматка караганда, 200 кеше авылыбыздан җир алырга теләп гариза язган. Шунысы куанычлы: аларның күбесе – Төмәнәктә туып-үскән егет-кызлар.

Безнең якта халык нигездә теплицада яшелчә үстерү белән шөгыльләнә. Авылда яшәр өчен бөтен мөмкинлек тә бар: урта мәктәп, башка җәмәгать объектлары эшли, халык матур яши. Чын татарча, күршесеннән

уздырып, матур-матур йортлар салалар. Мәктәптә 130лап бала белем ала, ә инде беренче сыйныфка керүчеләр 30дан артык. Авылда балалар саны ел саен арта баруы да куанычлы хәл.

Миңа 2002 елгы халык исәбен алу нәтиҗәләрен чагылдырган документлар белән танышырга туры килде. Анда акка кара белән, Төмәнәктә 33 процент башкорт яши, дип язылган. Шушы көннән миндә авылым тарихын барлау, аның уңган кешеләре хакында китап язу теләге туды һәм 2008 елда авылдашларым һәм Казанда яшәүче дустым Шаһинур Мостафин ярдәме белән «Синеке бит без, Төмәнәккәем» исемле басма дөнья күрде.

Әлбәттә, мондый катлаулы эшне ялгызым гына башкарып чыга алмаган булыр идем. Якын дустым, мәрхүм Илфак Шиһаповның бу өлкәдә күрсәткән ярдәме бәяләп бетергесез булды. Аның белән бергә Уфа, Ырымбур, Казан, Мәскәү архивлары документларын, авылдашларымнан алынган мәгълүматларны барлаганнан соң, бары тик архив документларына гына таянып язылган «Кемнәр соң без, Төмәнәк бабай?» исемле китап та дөнья күрде.

Архив документларыннан күренгәнчә, авыл тарихы 1692 елдан башлана, чөнки нәкъ шушы елда Минзәлә ягыннан килеп утырган 6-7 гаиләгә җир бүлеп бирелә. Моны раслаган документның күчермәсе китапта да урнаштырылды. Димәк, 2017 елда авылыбызга 325 яшь тулды. Чыганакларга күз салсак, өч гасыр эчендә Төмәнәктә яшәүче халыкның 1 проценты гына башкорт икәне ачыкланды. Уфада татар авыллары тарихына багышланган конкурста безнең китап икенче урынны алды.

Китап чыгу уңаеннан, 2013 елда авылдашларыбыз белән олы итеп шәҗәрә бәйрәмен уздырдык. Бәйрәмгә чит илләрдән һәм Россиянең төрле төбәкләреннән кунаклар җыелды. Һәркем кулыннан килгәнчә ярдәм итәргә тырышты, гаиләләр нәсел җепләрен барлады, яңа туганнар да табылды.

Үзләре күреп үсмәгәч, балаларга әби-бабаларының ничек тормыш иткәнен сөйләп кенә аңлатып булмый. Халкыбыз: «Мең кат ишеткәнче бер кат күрүең яхшырак», – ди. Авылымның үткәнен яшь буынга җиткерү теләге белән узган елда «Бабай утары» исемле ачык һавадагы этноавыл төзедек. Бу музей комплексында XVIII-XX гасырлардагы татар авылы көнкүреше белән якыннан танышырга, йорт җиһазларын, эш коралларын үз кулларың белән тотып карарга була. Җил тегермәне, борынгы салам түбәле һәм саман кирпечтән салынган өйләр, абзар-куралар... Ватандашларыбыз гына түгел,

Бабай утары. Башкортстан Республикасының Туймазы районындагы Төмәнәк авылы

«Бабай утары»н инде Австралия, Төркия, Германия, Финляндия, Кытай, Испания кебек чит илләрдән килгән кунаклар да үз итте. Җиде ай эчендә 1 меңнән артык кеше кабул иттек. Кыш айларында туристларны җәлеп итү максатыннан, канат юлы төзеп, тюбингта шуу оештырдык. Кунакларга атта йөрү, табигать кочагында ял итү өчен дә шартлар тудырылган.

Агымдагы елда Төмәнәктә археологик эзләнүләр оештырырга, кабер ташларын өйрәнергә дип план корабыз. Кем белә, бәлки авылыбыз тарихындагы башка серләрне дә ачарбыз.

2017 елның июлендә Төмәнәктә тагын бер зур вакыйга булды. «Россиянең татар авыллары» иҗтимагый оешмасы, Бөтендөнья татар конгрессы белән берлектә, Ык буе авыллары Сабан туен уздырдык. Ырымбур өлкәсен, Башкортстанның җиде, Татарстанның алты районын Ык елгасы берләштерә. Ата-бабаларыбызның шушы елга буенда дус-тату көн итәргә дигән изге әманәтен саклау – олы бурычыбыз. Алла боерса, 2018 елда бу күркәм бәйрәм Татарстанның Азнакай районында узачак. Изге башлангычыбыз дәвамлы булыр: ике тугандаш республиканың алда аталган барлык районнары да Ык буе авыллары Сабан туен үзендә кабул итәр, дип өметләнәбез.

Киләчәк буында авыл тормышына мәхәббәт уяту максатыннан, агымдагы елның җәендә «Бабай утары»нда «Сәләт» лагерен оештырырга телибез. Бу эшләр туган авылым тарихын тагы да тирәнрәк өйрәнергә, дуслык-туганлык күперен ныгытып, бабаларыбыз корган тормышны, аларның бердәмлеген саклап калырга ярдәм итәр, дип ышанам. Башка регионнарда да шундый лагерьлар оештырылып, татар балаларының Татарстан белән арасы якынайса, ничек яхшы булыр иде.

Нәҗәт НӘГЫЙМОВ:
«Хәтерсез халык – киләчәксез»

– Беренче мәртәбә Азнакай якларын XVIII гасырда яшәгән галим-сәяхәтче Петр Симон Паллас үзенең «Путешствие по разным провинциям Российского государства» дигән хезмәтендә искә ала. Аның язмаларында бүген дә районыбызның горурлыгы булган Чатыртау сурәтләнә.

Азнакай тарихчысы Роберт Зарипов, төбәгебезнең үткәнен ныклап өйрәнеп, «Урсаем син минем, Урсаем...», «Үткәннәр эзеннән» исемле китапларында: «XIV-XVI гасырларда Тымытык төбәгенә халыкның беренче буыны – күчмә нугайлар буш җирләргә килеп төпләнгән. Ык елгасы буенда беренче авыллар барлыкка килгән. Тымытык авылына – 1690, Урсай авылына – 1698, Чалпыга 1703 елларда нигез салынган», – ди.

Тарихны халык яза... Чөнки тарих һәр нәселнең үткәненә барып тоташа. Бөртекләп җыйган истәлекләр, язмаларга әврелеп, китап битләренә урнаша. Туган як тарихын барлау максатыннан, күп кенә китапларны чыгаруда районыбыз җитәкчесе Марсель Зөфәр улы Шәйдуллин һәм Ниһат Мозаффаров, Илдус Гыйләҗев, Марсель Гариповлар җитәкчелегендәге иҗат төркеме зур тырышлык куйды.

Азнакайга нигез салынуга – 250 һәм аңа шәһәр исеме бирелүгә 25 ел тулу уңае белән чыккан «Азнакай» китабы дүрт – татар, рус, төрек һәм инглиз телләрендә нәшер ителде. Иҗат төркеме туктаусыз хезмәттә. Якташларыбызның тормыш юлын, язмышын, ирешкән казанышларын чагылдырган «Язмышыбыз Азнакай – наша судьба» дип аталган энциклопедик белешмә дә дөнья күрде.

Хәтерсез халык – киләчәксез. «Хәтер түрендәге авыллар – Тепло покинутых деревень» китабы районыбызда югалган авылларны истә тоту максаты, аларның исемнәрен

тарихта калдыру теләге белән язылды. Әлеге китапка халыкның тетрәндергеч истәлекләрен дә, моң-зарлы күз яшен дә туплап бирдек. Нәсел оясын төзек тотарга, нигез-тамырларны корытмаска, бүгенгенең кадерен белеп яшәргә кирәк, дигән фикерне яшь буынга җиткерүне үз алдына куя бу басма. Төрле сәбәпләр аркасында халкы китәргә дучар ителгән 36 авыл тарихын үз эченә алган әлеге китап соңгысы булмас. Районыбызның китапханә хезмәткәрләре башлаган эш төбәкне өйрәнү музее белгечләре белән берлектә дәвам итәр, дип уйлыйм.

Бу китапның гамәли файдасы да гаять зур булды. Юкка чыккан авыл урыннарында массакүләм чаралар оештыру, анда яшәп киткәннәр белән очрашу, ул җирләрдә кече Сабантуйлар үткәрү, зиратларны чистарту, авыл урынына истәлек такта-стеллалар урнаштыру районыбызда матур бер гадәткә әверелде. Бу чаралар тагын шуның белән дә әһәмиятле: хәзер читтә яшәүче кешеләр, ул-кызларын бирегә алып кайтып, туган нигез урыннарын, әби-бабаларының каберләрен күрсәтә. Авыл булмаса да, андагы зират-каберлекләр саклана, мәрхүмнәр рухы исәннәрдән дога өмет итә!

Юкка чыккан дип саналган авылларның яңадан терәкләнеп киткәннәре дә бар безнең районда. Мәсәлән, Кызыл Йолдыз, Тургай, Агымсу авыллары бүген яңарыш кичерә. «Актүбәнефть»тә эшләүче Р.Р.Ишкәев ярдәме белән Александровка һәм Тургайга җан керде. Фаяз исемле бер якташыбыз Кызыл Йолдызда йорт салып бетерде диярлек. Фрунзе, Чалтаймас, Чатыра кебек авыллар да әле кайчан гына перспективасыз дип санала иде.

Районыбызның бай тарихы галимнәрне кабат Азнакай ягына җәлеп итә, яңа эзләнүләр, табышлар барлыкка килә. Альберт Борһанов, Җәмил Мөхәммәтшин кебек белгечләр Азнакай төбәген өйрәнә һәм үз хезмәтләрен халыкка тәкъдим итә. Шул ук вакытта авылларыбызда яшәүче тарихчылар да, бар тырышлыкны куеп, әлеге эшне дәвам итә. Алар тарафыннан ун китап чыгарылды. Авыллар тарихын язганда аерым шәхесләрне генә түгел, ә анда яшәүче барлык ыруг-нәселләрне дә өйрәнергә тырышабыз. Бу китаплар киләчәк буын өчен зур тарихи мирас булып хезмәт итәр, дип ышанам.

*Язманы **Ленар Гобәйдуллин** әзерләде.* ■

«КӘЛАМ-Е ШӘРИФ»МЕ, ӘЛЛӘ «КӘЛАМ ШӘРИФ»МЕ?

Айдар Хәйретдин



Каюм Насыйри. «Мифтах әл-Корьән». 1886 ел

2015-2016 еллар Каюм Насыйриның Коръәнне өйрәнү фәнендә зур әһәмияткә ия «Мифтах әл-Корьән» исемле кульязма хезмәтен басмага әзерләвебез һәм аны җәмәгатьчелеккә тәкъдим итү чараларын үткәрүебез белән истәлекле булды. Бөек мәгърифәтче тарафыннан 1886 елда шәрыкның һәм гарепнең иң алдынгы фәнни ысулларына таянып язылган әлеге Коръән гыйбарәләре сүзлеге ике китап рәвешендә дөнья күрде, ягъни китапларның берсе – Каюм Насыйри кульязмасының факсимиле үрнәге белән «Мифтах әл-Корьән», ә икенчесе – «Кәлам шәриф», ягъни 1861 елгы Казан басмасының факсимилесы.

Без, дигәндә әдипнең кулъязма мирасында «Мифтах әл-Коръән» исемле китап барлыгын ачыклаган, бу хезмәтне басмага әзерләүдә аерым зур тырышлык күрсәткән Каюм Насыйри музее мөдире Раушания Шәфигуллина һәм гарәп телендә язылган 130 еллык кулъязма, шулай ук ике томлы басма буенча да беренче фәнни тикшеренү эшен үткәргән Ш.Мәрҗани исемендәге Тарих институтының фәнни хезмәткәрен – бу мәкалә авторын күздә тотам.

Китапны тәкъдим итү чараларының берсендә тамашачылар арасында утырган мөхтәрәм бер галимебез: «Кәлам шәриф», дип әйтү дөрес түгел, «Кәлам-е шәриф» булырга тиеш!», – дип, бер төзәтмә керткән иде.

Хәер, әллә инде мәшәкатебез чамадан тыш күп булганга, ул чакта мин ул белгечкә җавап бирми калдым һәм әлеге мәсьәләгә аерым тукталып торырлык форсат та чыкмады. Әмма күңелемә: «Бу мәсьәләне кайчан да булса хәл итәргә кирәк!» – дигән фикер уктай кадалып калды. Ниһаять, җавабымның насыйп сәгате җитте бугай. Ул җавапның ни өчен шулчакта ук бирелмичә әлегә кадәр кичектерелеп торганын да аңладым кебек: бүген биредә фәнни дөреслек мәсьәләсен күтәрү генә түгел, татар теленең киләчәге турында кызу бәхәсләр килеп кушылды. Телебезне саклап калырга телибез икән, бу савaплы эшне телнең иң кечкенә берәмлекләреннән башларга кирәк. Ул берәмлекләрне кадерләп барлап чыгып, кулланылышка кертү, популярлаштыру һәм мәңгеләштерү мәслихәт. Борынгыдан сакланып бүгенгәчә килеп җиткән һәр авазның, һәр сүзнең, һәр гыйбарәнең, орфоэпик, грамматик, синтаксик һәр кагыйдәнең кадерен белергә тиешбез, чөнки болар – безгә бабаларыбыздан калган тере мирас, милләтебезнең киләчәген тәэмин итүче иң әһәмиятле корал. Хәзерге көндә бу байлыгыбыз, газиз телебез, һәр татарның күзенә төбәп карап: «Мине саклап кала алачаксыңмы? – дип сорый кебек. Алга таба язачагымны милләтебезнең иң зур байлыгын саклап калу юнәлешендә эшләнгән кечкенә генә бер эш итеп кабул итүегезне үтенәм.

Димәк, мәсьәлә болай куелган: «Кәлам-е шәриф» диеп әйтү дөресме, әллә «Кәлам шәриф» диепме?

Казан дәүләт университетының йомры башлылар тарафыннан юкка чыгарылган татар теле, әдәбияты һәм тарихы факультетында, аңа кушып Ташкент дәүләт шәрыкшенаслык институтында алган белемнәремә таянып, бу мәсьәлә буенча түбәндәге аңлатманы бирә алам.

«Фәлән-е фәлән» димәк, ул фарсы теле кагыйдәсе буенча ясалган изафә сүзтезмә, ягъни бер исемнең икенче бер исемгә аергыч булып килүе. Мәсәлән, фарсыча *кетоб-е песар*, дигән сүзтезмә «малай китабы» дип тәрҗемә ителә. Болай икән *кәлам-е шәриф* – «Шәриф китабы» яки «Шәрифнең китабы» диеп тәрҗемә ителергә тиеш.

Алга таба безгә күптән таныш бер мисал буларак мәшһүр *«шәһр-е Казан»* гыйбарәсен китерәм. Моның татарчасы – «Казан шәһәре». Шул ук калыпта ясалган *«шәһр-е Рамазан»* – «Рамазан ае» була. Игътибар итегез, «малай китабы», «Казан шәһәре», «Рамазан ае» кебек сүзтезмәләрдә мәгънә – фарсыча яки татарча булсын – ике исем белән бирелә. Димәк, югарыда китерелгән мисалларга ияреп, *«кәлам-е шәриф»* дигән гыйбарә дә «Шәрифнең сүзе/кәламы» диеп тәрҗемә ителергә тиеш.

Хуш, шулай булсын ди. Әмма болай икән «шәриф» дигән сүз, ягъни исем, нәрсәне яки кемне белдерә? Аллаһныдыр, бәлки? Яхшы, шулай булсын, ди. Әгәр Аллаһның андый исеме бар икән, мәзкүр сүзтезмәбез *«кәлам-е шәриф»* дип әйтелә дә, языла да ала. Бу очракта аның тәрҗемәсе: «Шәрифнең (Аллаһның) сүзе» булачак. Әмма, Аллаһының мөбарәк 99 исеме арасында «әш-Шәриф» дигән исем юк. Димәк, «кәлам-е шәриф» гыйбарәсендәге «шәриф» сүзе ул ни сүз төркеме буларак исем була алмый, ни ялгызлык исеме буларак. Болай булгач, «кәлам-е шәриф», дигән саен ул гыйбарәнең мәгънәсен

аңлаган һәркемсәдә: «Тукта әле! Бу нинди Шәрифнең кәламы (сүзе) икән?» – дигән сорау туачак. Аңлашыла ки, мондый сорау туды икән, гыйбарәнең әйтелеше һәм язылышында ниндидер җитешсезлек бар.

Минем аңлавымча, әлеге «кәлам-е шәриф» сүзтезмәсе татар телендә бер ялгышлык белән генә фарсы телендә кулланыла торган изафә итеп кабул кылынган. Чынлыкта бу сүзтезмә шул ук фарсы теле калыбы буенча ясалган аерылмыш-аергычтан гыйбарәт. Шулай икән, ул «кәлам-е шәриф» түгел, «кәлам шәриф», дип әйтелергә-язылырга тиеш. Бу очракта аның мәгънәсе исем белән сыйфатның үзара синтаксик мөнәсәбәткә керүләре нәтиҗәсендә туа һәм «шәрәфле сүз» дигән мәгънәне белдерә. Күренә ки, бу очракта «шәриф» сүзе аергыч булып килгән сыйфат.

Моннан тыш, ошбу «кәлам шәриф» дигән сүзтезмәнең гарәп сүзтезмәсе түгел, ә нәкъ менә фарсы сүзтезмәсе булуы да минем фикеремне раслый. Коръән кебек үзенә күрә бердәнбер китап турында гарәпчә әйтелгәндә аңа «әл» алкисәкчәсе («әл», дигән билгелелек күрсәткече, артикль) кушыла, мәсәлән, «әл-Коръән» дигәндә. Инде китап киштәгездәге бер Коръән китабын алып карагыз: ул Гарәбстанда басылган икән, аның тышлыгында «әл-Коръән әл-Кәрим», ягъни «Игелекле Коръән» дип язылган. Гарәпчә артикль кулланмыйча «Коръән кәрим» диеп булмый, мөмкин дә түгел. Ялгыш кына болай әйтелсә дә, ул сүз без белгән Коръән турында түгел, ә «ниндидер игелекле уку» мәгънәсендә генә булып калачак. Гарәп телендә Коръәнгә карата шундый кырыс какшамас кагыйдәләр хөкем сөргәнне белә торып, «Кәлам шәриф» дигән гыйбарәнең һич тә гарәпчә түгеллеге көн кебек ачык. Болай итеп тик татарча яки фарсыча гына әйтеп була. Татарчасы, мәсәлән, «Изге Коръән», «Шәрәфле Коръән» булсын, ди, ә фарсычасы «Кәлам шәриф» булачак.

Урап йөри торгач, ниһаять, мәкаләнең башына чыгарылган сорауга да җавап бирер вакыт килде: «Кәлам-е шәриф» диеп әйтү һич кенә дә дөрес түгел, ә «Кәлам шәриф» диеп әйтелергә һәм язылырга тиеш. Болай икән аның татарчасы «Шәрәфле кәлам» яки «Изге сүз», «Изге сөйләм» була.

Сүз уңаеннан тагын бер хата мисалы китерәсе килә. Ул Муса Бигиевнең «Кавагыйд фикъһийә» исемле китабының исемен бозып яңгырату турында. Гарәп-фарсы телләре кагыйдәләрен белеп бетермәгән кайберәүләр аны «Кавагыйд-е фикъһийә» диеп язалар. Югарыда әйтелгәннәрне истә тотканда «Кавагыйд-е фикъһийә» дигән гыйбарә «Фикъһийә кагыйдәләре» дип тәрҗемә ителергә мәҗбүр. Әмма дөрес тәрҗемә – «Фикъһий кагыйдәләр».

Дәвам итеп, моңа охшаш башка байтак хаталар турында да аңлатмалар бирә алыр идем, тик матбугат мәкаләсе кысаларыннан чыгып китәргә туры киләчәк. Шулай да, мөмкинлектән файдаланып, әлеге бәхәснең килеп чыгышы, тарихи тамырлары турында да бер-ике сүз әйтәсем килә. Татар дин галимнәренең әсәрләрендә һәм, гомумән, татар ислам мәдәниятендә фарсы теленең бу кадәр көчле тәэсире, калдырган эзләре тиктомалдан түгел. Болар барысы да татар халкының ислам белән гарәпләр аша түгел, күбрәк фарсылар аша танышкан булуына ишарә итә. Әмма монысы инде башка тема. ■

ИСКЕ ҖӨРИНЕҢ
борынгы ядкәре

Ирек Һадиев, Раиф Мәрданов

Иске Җөри каберлегенең һәм шундагы борынгы ташъязманың (19 нчы биттә) эпиграфист-галим Һарун Йосыпов 1950 нче елларда төшергән фотолары. Саклану урыны: ТР ФА ТӘһСИның Язма һәм музыкаль мирас үзәге. Фонд 72, тасвирлама 1, сакл. берәм. 491.

Республикабызның Теләче районындагы зур тарихлы Иске Җөри авылы ханнар заманыннан ук билгеле. Авыл читендә, Мишә елгасы болынының калку ярында, ялгыз нарат астында хәзергәчә сакланган XVI гасыр кабер ташы – шушы борынгылыкның язма-документаль дәлиле. Җирле халык аны «Хан кызы кабере» дип тә йөртә.

Татар халкы тарихын өйрәнүгә зур өлеш керткән галимнәрдән Н.И.Воробьёв белән Сәет Вахиди, 1925 елда Мамадыш кантонына махсус экспедиция оештырып, берничә дистә борынгы ташъязма турында җентекле мәгълүмат теркәп калдырган[1]. Анда Иске Җөридәге эпиграфик истәлек тә тасвирланган: куелган урыны, ташның һәм өслегендәге язуларының начар сакланышы, үлчәмнәре күрсәтелгән һәм якынча вакыты (Казан ханлыгы чоры) билгеләнгән[2].

XVI гасырның беренче яртысы ташъязмалары сакланган торак пунктларның эпиграфист-галим Һарун Йосыпов төзегән исемлегендә Теләче районының Иске Җөри авылы да күрсәтелгән[3]. Әлеге ташъязма Татарстанның археологик истәлекләре белешмә-китабына да кертелгән[4]. Анда шулай ук гомуми тасвир бирелгән: XVI гасырның беренче яртысына нисбәтле кабер ташының авылдан төньяк тарафтагы иске зират урынында торуы, үлчәмнәре, язу һәм бизәлеш үзенчәлекләре әйтелгән.

Татар топонимнары белгече, галимә Фирдәвес Гарипова Иске Җөри авылына багышланган мәкаләсендә болай дип язган: «*Авыл аксакаллары хәтерендә калган риваятьләргә караганда, Иске Җөри авылына XVI йөздә нигез салынган. Монда иң беренче булып килгән кеше Җөрихан исемле булган. Ләкин ул биредән күчеп киткән, дип сөйлиләр. Монда аның кызы үлеп кала. Бу кабер әле дә булса саклана икән*». Шунда ук автор борынгы кабер ташы турында да мәгълүмат биргән[5].

Теләче районына багышлап чыгарылган китапларда бу истәлек, аның өйрәнелү тарихы һәм аңа

[1] Воробьёв Н.И. О болгаро-татарских надгробных камнях Мамадышского кантона ТССР // Материалы по охране ремонту и реставрации памятников ТССР. 3 вып. – Казань, 1929. – С.11-13.
[2] Шунда ук. – Б.12.
[3] Юсупов Г.В. Введение в булгаро-татарскую эпиграфику. – М., Л.: Изд-во АН СССР, 1960. – С.26.
[4] Казаков Е.П., Старостин П.Н., Халиков А.Х. Археологические памятники Татарской АССР. – Казань: Татар. кн. изд-во, 1987. – С.197.
[5] Гарипова Ф. Авыллар һәм калалар тарихыннан. – Казан, 1997. – Б.499-501.

Иске Җөри каберлегенең хәзерге замандагы фотолары

бәйле риваятьләр телгә алынган, кабер ташының иясе *«бер морзаның кызы»*, *«Җөри ханның кызы»* буларак аталган[6]. Язучы Фәнил Галиев туган төбәгенә карата олуг хөрмәт белән сугарылган хикәяләренең берсен нәкъ менә шушы риваять нигезендә иҗат иткән[7]. Мавыктыргыч сюжетлы әлеге әсәрнең ахырында Мишә буендагы кабер ташы тасвирланып, ул: *«Биредә Җөри ханның гүзәл кызы Зөһрә белән ханның тугры дусты һәм көрәштәше Ибраһим Мәхмут җирләнгән булырга тиеш»*, – дип тәмамлана. Иске Җөридәге ташъязма истәлек тарихчы Нурулла Гариф хезмәтләрендә дә телгә алына[8].

Тарихчылар Рәшит Галләм һәм Булат Хисмәтуллин үзләренең бер мәкаләләрендә Җөри хан турындагы риваятьне һәм аның белән бәйле мәгълүматларны бастырып чыгарды[9].

[6] Туган ягым – Теләче: фәнни-популяр басма. – Казан, 2003. – Б.10-11, 191; Теләче йолдызлыгы: тарихи-публицистик очерклар / төз. И.Хәлиуллин. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2006. – Б.164.
[7] Галиев Ф. Ерак һәм якын елларда...: тарихи, драматик һәм детектив әсәрләр. – Казан: Сүз, 2013. – Б.8-21.
[8] Гариф Н. Казан ханлыгы чоры ташъязмалары. – Казан, 2010. – Б.25; Гариф Н. Болгар-татар ташъязмалары = Булгаро-татарские надгробные камни. – Казан: Иман, 2012. – Б.170, 230.
[9] Галлям Р., Хисматуллин Б. Легенда о «Зюри хане» // Из истории и культуры народов Среднего Поволжья. – 2016. – №6. – С.225-231.

Әлеге авторлар тарафыннан биредә без сүз алып бара торган фольклор һәм эпиграфика чыганакларының тарихи әһәмияте билгеләнгән, аларга тасвирлама ясалган.

* * *

Иске Җөри авылындагы кабер ташы тексты фәнни әдәбиятта моңарчы басылмаган, югарыда әйтелгәнчә, ул XVI гасырның I яртысы истәлеге буларак кына телгә алынып килгән. 2001 елның 25 октябрендә һәм 2015 елның 21 мартында без бу борынгы ташны барып карадык, укыдык, фотога төшердек. Элек теркәп алынган һәм соңгы язмаларыбызны чагыштырып, таш текстын яңадан укып, аңа шактый ачыклык керттек.

Бу кабер тимер чардуган белән әйләндереп алынган. Ташбилге ике катламга аерылып, арткы катламы янәшәдә ята. Н.И.Воробьёв мәкаләсендә ташның 1925 елларда ук шундый халәттә булуы әйтелгән. Башка мәкаләләрдә ташның калынлык үлчәмендәге төрлелек тә (9 см һәм 17 см) шушыңа бәйле дип уйлыйбыз. Күптәннән ике мөстәкыйль таш рәвешендә күренеп торганлыктан, халык телендә кайчакта бу урын ике кеше кабере буларак искә алынадыр, мөгаен.

Ташның иң өске өлешендә шул чор ядкәрләренә хас булган бизәк рәсеме ясалган, алгы өслеге тирәли кайма бизәк төшерелгән, хәрефләре күпертеп язылган.

Бу урында ташъязма истәлекнең текстын китерәбез:

Илкилде(?) Исмәгыйль улына куелган кабер ташы. 1516 ел.

1) калә Аллаһу Тәбарәкә вә Сөбханәһә көллү нәфсин
2) заикател-мәүт сүммә иләйна түрҗәгун сада[ка]
3) [калә ән-нәби галәйһиссәлам] әд-дөнья сагать
4) [фә-әҗгальһа тагать тарих ту]куз
5) йөз егерме ике[дә] ... ирде кем
6) Исмәгыйль угылы Ил[килде-?]
7) ...
Үлчәмнәре: 126 х 48 х 9 см

Сүзлекчә: *калә Аллаһу Тәбарәкә вә Сөбханәһә* – Һичбер кимчелексез бөек зат булган Аллаһы әйтте; *көллү нәфсин заикател-мәүт сүммә иләйна түрҗәгун* – һәр җан үлем ачысын татыр һәм Аллаһы хозурына кайтыр; *садака* – тәгаен шулай, хак сүз; *калән-нәби галәйһиссәлам* – Пәйгамбәребез (аңа Аллаһының сәламнәре булсын) әйтте; *әд-дөнья сагать фә-әҗгальһа тагать* – дөнья бер сәгатьлек, аны гыйбадәт белән үткәр; *ирде кем* – иде ки.

Ташта уелган һиҗри 922 ел милади исәп белән 1516 елга туры килә. Шушы рәвешчә, истәлекнең датасы (елы) билгеле булды. Кабер иясенең атасы исеме дә төгәл укылды, ә үз исеменең башындагы «Ил-» иҗеге ачык күренсә дә, дәвамын тану авыр булганлыктан, якынча «Илкилде» вариантына тукталдык. Ташъязма текстындагы кеше исемнәренең халык хәтерендә сакланган тарихи риваятьтә бу ташка нисбәт ителгән исемнәргә туры килмәвен дә искәртик. ■

Безнең мирас №5 май 2018

ОЛУГ МӨХӘММӘД

Марат Әмирханов

Романнан өзек

«Олуг Мөхәммәд хан». Рифкат Вахитов рәсеме

Күренекле язучы Марат Әмирханов – хәзерге татар әдәбиятында тарихи жанрда иң өлгер каләм тибрәтүчеләрнең берсе. Ул иҗатташлары Рабит Батулла, Вахит Имамовлар белән бергә, Нурихан Фәттах, Мөсәгыйт Хәбибуллин кебек олпат әдипләребезнең традицияләрен уңышлы дәвам итә. Аның «Үрбәт ханәкә гыйшкы», «Гәүһәршад», «Әлвидаг», «Ир-Мамай», «Тәхетсез патша» әсәрләре киң җәмәгатьчелек һәм әдәбият сөючеләр тарафыннан җылы кабул ителде.

«Әдип халкыбызның катлаулы һәм каршылыклы, данлы һәм фаҗигале тарихын үз укучыларына, милләттәшләренә үтемле рәвештә, җанлы образлар, киеренке сюжетлар ярдәмендә җиткерергә омтыла, шул юл белән милли үзаңны үстерергә, күзаллауларын тулыландырырга тырыша, һәм шактый дәрәҗәдә моңа ирешә дә», – дип билгеләп үтә танылган әдәбият белгече, профессор Хатыйп Миңнегулов үзенең бер мәкаләсендә.

Марат Әмирханов гомер бәйрәмен билгеләп үткән көннәрдә Казан ханлыгына нигез салучы Олуг Мөхәммәд хан турындагы романын төгәлләде. Аны юбилее белән ихластан котлап, сәламәтлек, иминлек, иҗат уңышлары теләп калабыз һәм журнал укучыларга шул романнан бер өзек тәкъдим итәбез.

Редакция

– Мавыктыргыч тәкъдим, кенәз, үзең әйтмешли, уйлап карарга ярый, – диде Касыйм.

Бу вакытта Мәхмүдәк белән Ягъкуб Казанда ханлыкны рәсми рәвештә игълан итүгә кагылышлы мәшәкатьләр белән мәшгуль иде. Тантана Җәмигъ мәчетендә булачак.

– Мәчетнең эчке җиһазлары шушы хәлендә калачакмы әллә? – дип, Мәхмүдәк кырыс карашын Галибәк әмиргә юнәлтте.

– Ни... без аны...

– Билекнең казнасы сай, ул бу чыгымнарны күтәрә алмый, – дип, Габдулла вәкил әмиргә ярдәмгә килде, – бар булганны тәхет чыгымнары йотып бара.

– Чыгымнарны Урда үз өстенә алыр, мәчет эчендә әлегәчә кулланышта булган сыңар җиһаз да калмаска тиеш, – диде Мәхмүдәк, – келәмнәрнең Сәмәркандта тукылганын сайлагыз.

– Баш өсте, – дип, әмир кулын күкрәгенә куйды.

Тәхет остаханәсендә дилбегәне Ягъкуб үз кулына алды. Сәнгать, мәдәният диңгезендә ул үзен иркен хис итә иде.

Әссәламегаләйкем, йә Сәитем!
Вәгаләйкемәссәлам, авыз мулла йегетем!
Һәрдаим йотлар идем
Ардаклы суына ягалай,
Ягалаган көнләрдә
Аргамакның аягын
Ефәк менән дагалай...

Ул, авыз эченнән шушы шигъри юлларны көйли-көйли арткарак чигенеп, күзләрен кыскан хәлдә, инде эшләнеп бетеп килүче тәхеткә озак кына карап торды.

Тәхет күркәм иде. Биек аркалы, нәкъ очында – ярымай. Айның асылташлары, тәрәзәдән бөркелеп кергән кояш нурларына кушылып, күктән атылган йолдызлардай җем-җем уйнаша.

Ханның урыны шактый киң, аслыгына берничә чигүле йомшак мендәр дә салынган, таянып та, кырын ятып та алырга була.

Тәхет шундый ук кыйммәтле асылташлар беркетелгән челтәрле коймачык белән уратып алынган, хан янына ансат кына үтеп кермәле түгел.

– Яңа дәүләтнең тәүге патшасына лаек тәхет, – дип нәтиҗә чыгарды Ягъкуб, – ханбикәгә багышланган кече тәхет-кәнәфи дә затлы, ләкин...

– Нәрсә ләкин, ханзадә? – дип тынгысызланды Габдулла. Чөнки тәхет өчен ул җаваплы иде.

– Үзбәк ханның тәхете көмеш аякта утырган булган, ә сезнеке – тоташ, – диде Ягъкуб, – минемчә, бу күп вакыт алмас.

– Тәкъдим урынлы, – дип җиңел сулап куйды вәкил, – кабул итәбез.

– Хуш, тагын бер мәсьәләгә генә ачыклык кертәсе калды, – диде Ягъкуб.

– Тыңлыйбыз!

– Һәр пайтәхетнең тамгасы була. Алтын Урданың ике башлы каракош иде, Казанның тамгасы бармы?

– Бар, – диде әмир, – Казанның тамгасы да ике башлы, бер башы – еланныкы, икенче башы – үгезнеке. Үзе канатлы. Исем-аты – Аждаһа.

– Сөбхәналла, Казанның тамгасы тагын да мөкәммәлрәк икән, таҗ кидерелгән.

Ханзадәләр Казаннан күтәренке күңел, изге ниятләрнең гамәлгә ашачагына тирән ышаныч хисе тулышкан бер ашкынулы халәттә кайттылар.

Олуг Мөхәммәд, канәгать булуын белдереп:

– Шундый булдыклы уллар биргән өчен, мин Ходайга һәрдаим догада, – диде. Әмма үзе ниндидер аңлаешсыз төшенкелектә иде.

Ханзадәләр моны шундук абайлап алды.

– Атаем, бер-бер хата җибәргәнбезме әллә? – дип сорады Мәхмүдәк. – Пошаманда күренәсең.

– Улым Мәхмүдәк, күңелсез хәбәр әйтеп, күрексез буласым килмәсә дә, йотып кала алмыйм, – диде Олуг Мөхәммәд, – кәләшең княгиня Анастасьяга юлбасарлар һөҗүм иткән, син җибәргән сак яугирләрен кырып бетергәннәр, каты яраланган берәве генә исән калган. Бу хәбәрне шул җиткерде, үзе дә вафат инде.

– Ә княгиня?

– Кызганыч, бик кызганыч, княгиняны талаганнар да, мәсхәрәләп, күкрәгенә хәнҗәр кадаганнар...

Мәхмүдәк карчыга ыргымы белән атасы алдына килеп тезләнде.

– Атаем, рөхсәт бир, мин ул кәбихләрне эчәгеләреннән агач ботакларына асып куям, – дип тешләрен шыгырдатты.

– Рөхсәт, – диде Олуг Мөхәммәд, – иң өлгер тупланыңны ал, шулай да сак кылан, юлбасарлар мәкерле була ул.

– Күрсәтермен мин аларга мәкер, кая керер тишек таба алмаслар.

Мәхмүдәк сүзендә торды, юлбасарлар дистә ел буе Рәзән урманнарына борын тыгарга җөрьәт итмәде.

***

Бигич бәкнең ни хәбәре, ни үзе, дигәндәй, олакты тәки. Хан көтә-көтә көтеккә әйләнде. Ник дисәң, бу гадәти багланыш кына түгел иде, яңа дәүләткә юл ачу, шуңа бәйләнешле рәвештә икътисади-сәяси вазгыятьне тәгаенләү башлангыч чорда ул алып кайткан хәбәргә бәйле иде. Әйтик, урыс дәүләте, телиме-теләмиме, Казан ханлыгын оештыру, бигрәк тә аның икътисади яктан тернәкләнүенә турыдан-туры йогынты ясаячак. Тик Шемяка белән урнаштырылган мөнәсәбәт Василий мисалында бөтенләй яраксызга әйләнергә мөмкин. Каш төзәтәм, дип, күз чыгаруың бар. Ләкин, уптым-илаһи алганда, аларның икесенә дә ышаныч аз. Бу очракта исә кайсысы бәла-казаны кимрәк китерергә мөмкин икәнлеген гөманларга гына кала. Ә гөманлау белән шөгыльләнергә чама юк, вакыт итәктән тарта. Кем белә, Шемяка бәлки илчегә кул салгандыр?

Олуг Мөхәммәд бер-ике көн көтте дә, хәбәр булмагач, Василийны чакыртып алды.

Василий, тезләнеп, аның камзул итәген үпмәк булган иде дә, ирек куймады.

– Монафикъ син, – диде кызмыйча гына, – бөек кенәзлекне сорарга килгәч тә итәгемне генә түгел, читек олтаннарымны да ялаган идең, ә нәрсә килеп чыкты?

– Мин синең алда бик гаеплемен, мөхтәрәм хан, – диде Василий, төкреген йотайота, – гаебемне кан бәрабәренә юарга да ризамын.

– Кан түгү турында түгел, солых турында, дөресрәге, сине әсирлектән азат итү шартлары турында сөйләшергә дәштердем, – диде Олуг Мөхәммәд, – мин – җиңүче, син – җиңелүче, мин – таләпче, син – үтәүче.

– Баш өсте, мөхтәрәм хан, – диде Василий турыга каткан хәлдә, ул селкенергә дә кыймыйча басып тора иде.

– Мин яңа дәүләт, Казан ханлыгы оештырам...

– Котлыйм, мөхтәрәм хан...

– Тыгылма, әйткәнне тыңлап бетер, – диде Олуг Мөхәммәд. – Син ул мәмләкәтнең чикләрен берсүзсез таныйсың һәм аңа каршы кул күтәрмәскә ант эчәсең. Бу – бер. Яңа дәүләткә алтын-көмеш белән йөз мең сум күләмдә йөкләмә түлисең. Бу – ике. Борынгы

чорлардан бирле төрки кабиләләр гомер сөргән Үкә елгасы буендагы җирләр, Мишәр шәһәре тирә-юнендәге җирләр белән идарә итү хокукын минем улым Касыйм ханзадәгә тәгаенлисең. Монысы була өч.

– Мин ханзадәгә бер зур төбәкне багышлаячагымны әйткән идем инде, мөхтәрәм хан...

– Багышлау ул – бүләк, кенәз, ә мин ул җирләрдә мөстәкыйль татар дәүләте оештыру таләбен куям. Тора-бара ул Касыйм ханлыгы исемен алыр, шәт. Казанга түләгән кебек үк, ул дәүләткә дә ясак түлисез. Аңлашылдымы?

– Аңлашылды, мөхтәрәм хан...

– Болардан тыш, биш-алты йөз укымышлы татар әһелен үзең белән Мәскәүгә алып китәсең һәм аларны дәрәҗәле дәүләт хезмәтләренә җитәкче итеп билгелисең.

Монысы ничәнче булды инде?

– Дүртенче, мөхтәрәм хан.

Олуг Мөхәммәд үзе дә арыды булса кирәк, сөлге белән йөз-башын сөрткәләп, корытып алды. Ым кагып кына, инде черек баганадай авар хәлгә җиткән Василийга да утырырга рөхсәт итте.

– Әгәр, кенәз, ризалыгыңны бирсәң, телдән әйтелгән ошбу шартларны кануни рәвештә килешү тәртибендә рәсмиләштерәбез. Ярдәмчеләребез, һәр ике яктан да, аларны җентекләп шәрехләрләр, тәңгәлләштерерләр, тәгаен хәлгә китерерләр. Өстәвенә, син тәреңне үбеп тә ант итәргә тиеш буласың. Шуннан соң, дүрт ягың кыйбла. Җә, җавабың нинди?

Василий, маңгаен учына терәп, уйланып торды да:

– Син, мөхтәрәм хан, сюзерен, мин – вассал, каршы килә алмыйм, ризамын, – диде.

– Бик хуш, әйдә, шәрабтән авыз ит, – диде Олуг Мөхәммәд, – понтифик бүләге, Рим белән безнең дуслык Алтын Урда вакытыннан килә.

Касәләрен чәкештерми генә бушатып куйдылар.

Бераз сүзсез торганнан соң, Олуг Мөхәммәд, әңгәмәне йомгаклап, әйтте:

– Сиңа бөек кенәзлеккә биргән ярлыгым көчендә кала, мин сине ошата идем бит...

Василийны, Кормыш каласына алып килеп, иреккә чыгардылар.

***

1438 елның үктәбер башында тоташтан атна буе яңгыр яуды. Юллар өзелде, аяк асты сазлы баткакка әверелде. Кешеләр, бу күңелсез кара көзнең чиге булмас ахры, дип сукрана башлаганнар иде инде. Һәм син күр дә, мин күр, җомга көнне иртән торып тышка чыксалар, хәйран калдылар. Таулар, агач-куаклар, өй түбәләре, каралты-куралар, ак шәл ябынган яшь туташлардай, ап-ак карга бөркәнеп утыралар иде.

Мәчет бакчасындагы миләшләрнең бүрек-бүрек алсу-кызыл тәлгәшләре бу шәүкәти пакьлек-яктылык кочагында оҗмах җимешләренә охшап тора иде.

Бигрәкләр дә килешә икән ак төс җиһанга.

Шушы әһле ислами манзараны илаһилык нурына төреп, изге азан яңгырады.

– Аллаһу әкбәр! Аллаһу әкбәр!

Азан тәмамлануга, мәчет эчендә Олуг Мөхәммәдне тәхеткә утырту тантанасы башланды.

Мәчетне бик матурлаганнар. Кая карама – күзләр гүзәллек, зиннәтлелек, зәвык вә купшылык белән очраша.

Дулкынландыргыч мизгелләр. Шулай булмыйча, мөстәкыйль яңа дәүләт, Казан ханлыгы оешты лабаса.

Афәрин!

Менә мөнбәр алдына мелла Габдерәхим сәед чыгып басты. Бизәкле кул таягына таянарак төшкән хәлдә дога укып, хөтбәсен башлады:

– Аллаһы Тәгаләнең рәхмәте белән, пәйгамбәребез Мөхәммәд галәйһиссәлам васыятьләренә тугры калып, Барча Казан җире халыкларының ихтыяҗы вә теләген тормышка ашыру максатларында яңа оешкан яшь мәмләкәтебезгә хан тәгаенләү – саваплы да, игелекле дә бер күркәм гамәлдер. Хакимне хөрмәт итү – Аллаһыны олылау дигән сүз ул. Чөнки хаким – Күкләр ихтыярын башкаручы зат. Бүген без, Аллаһының кушуы белән, Казан тәхетенә тамырлары шанлы чыңгызыйлар ыруыннан килүче Туйхуҗа бине Туктамыш бине Җәләлетдин бине Олуг Мөхәммәд солтанны тәгаенлибез. Ходай падишаһыбызга озын гомер бирсен, гадел вә шәрәфле гамәлләр насыйп итсен. Аның хакимлеге чорында Барча Казан җире данлы һәм мул тормыш кичерсен. Амин!

– Амин! Амин! Амин!

Олуг Мөхәммәд, ничек кенә тыныч булып күренергә тырышмасын, барыбер дулкынлануын баса алмады, тез буыннары йомшарып, Сәед каршысына авырлык белән генә килеп басты. Аннан ике-өч кенә адымда җәмәгате Дөрминә ханбикә, уллары Мәхмүдәк, Касыйм, Ягъкуб, Галимбәк әмир, Габдулла вәкил урын алды.

Шунда ук угланнар келәмгә әле генә яуган кардай ап-ак тәгыймәтне китереп җәйделәр. Ул алтын җепләр белән чигелгән, асылташлар белән бизәлгән иде.

– Барча Казан җиренә дәгъва итүче Олуг Мөхәммәд галиҗәнапларын, хан күтәрмәк йоласы буенча, тәгыймәткә бастырам, Ходай бәрәкәтле ханлык насыйп итсен!

Сәед Олуг Мөхәммәдне, кулыннан җитәкләп, киез уртасына кертеп бастырды.

Ханны күтәреп тә алдылар. Мәчет буйлап йөрткәндә тәгыймәт алтын-көмеш тәңкәләр, асылташлар белән тулды. Халык гөж килә.

– Төкле аягың белән, Олуг Мөхәммәд хан!

Тәгыймәттән төшкәч, Сәед ханга нашан тапшырды. Ул кызыл төстә иде. Ярлыкларга, аерата мөһим эш кәгазьләренә, бүгеннән башлап, Олуг Мөхәммәд ханның шушы мөһере сугылачак. Турыпочмак рәвешендәге нашанның читенә түбәндәге сүзләр теркәлгән: «Олуг Мөхәммәд хан – кодрәте солтан, гамәлләрендә һәм дини мәнфәгатьләрдә данлыклы, бөек яулап алучы, каһарман – Аллаһы Тәгалә аның мәмләкәтен гомер бакый сакласын вә падишаһлыгын күкләргә чөйсен».

Олуг Мөхәммәд Дөрминә ханбикәне урынына урнаштырды да тәхетенә килеп утырды. Нотыгы кыска һәм үтемле иде.

– Аллаһым! Синнән исәнлек-саулык, файдалы гыйлем, гүзәл һәм хәләл ризык, кабул булачак гамәл һәм эш телимен, – диде аз гына карлыга төшкән тавышын көйли-көйли. – Синең ризалыгың һәм теләгең аркасында, барча Казан җиренең шәрәфле тәхетенә утырдым. Кулыма Коръән тотып, мәмләкәтебезнең данын, кодрәтен, дәрәҗәсен саклау вә арттыру мәнфәгатьләрендә кулымнан килгәннең барысын да эшләргә ант итәм.

– Амин! ■

Безнең мирас №5 май 2018

КУЛАТКЫ УКУЛАРЫ*

Ильяс ҖИҺАНШИН: «Мәрҗани эзеннән барсак, югалмабыз!»

Бисмилләәһир-рахмәәнир-рахиим

– Дини яңарышның бер чагылышы буларак, 1980 еллар ахыры-1990 еллар башында Россия мөселманнарына дини белем алу юлларын табу максатын куйдылар. Аның берсе чит илләргә барып уку булды. Күпләр 1992 елның көзендә Төркия, Согуд Гарәбстаны кебек ислам мәмләкәтләренә белем эстәргә китте. Алар арасында динне бөтенләй ишетеп тә белмәгән, аңламаган кешеләр күп иде. Икенчесе – Татарстанда яки башка төбәкләрдә чит илләрнең ислам фондлары оештырган мәдрәсәләрдә белем алу. Кызганыч ки, 1990 нчы еллар уртасында аларның тискәре нәтиҗәсе күренде: халкыбызга чит-ят булган традицияләр тарала башлады, мөселман өммәтендә яшьләр белән өлкәннәр, әти-әни белән балалар, намаз укучы белән укымаучы, хөкүмәт белән җәмәгатьчелек арасында төрле, ә кайчакта кискен каршылыклар да килеп чыкты. Шуңа күрә үз мәдрәсәләребезне торгызу, булганнарына игътибарны арттыру зарурлыгы туды.

Ата-бабаларыбыз ничәмә-ничә еллар элек, иң авыр, изелгән вакытларында, йөрәк бәгыреннән кан саркытып, күз яшен түгә-түгә: «Йә, Раббым, балаларыбыз, оныкларыбыз, халкыбыз мондый авырлыкларны күрмәсен иде», – дип дога кылды! Шул догаларның нәтиҗәсе булып, XX йөзнең 90 нчы еллары башында диннең дәүләттә шактый зур һәм мөһим иҗтимагый институт икәне танылды. Татарстанда мөселман өммәте кабат үсешкә юл тотты, яңа мәхәлләләр барлыкка килде, мәчет-мәдрәсә биналары кайтарылды һәм яңалары төзелде. Ата-бабаларыбыз дин тыелган елларда утлы күмерне кулларында тоткандай, төшермичә, югалтмыйча безгә җиткергән исламның кадерен аңлау чорына җиттек. Традицион ислам дигән төшенчәне куллана башладык. Габденнасыйр Курсави, Шиһабетдин Мәрҗани, Каюм Насыйри, Галимҗан Баруди, Ризаэддин Фәхреддин, Әхмәдһади Максуди, Сөнгатулла Бикбулат, Хәбибулла ишан Хансәвәров, Мөхәммәдзакир ишан Камалов-Чистави, Зәйнулла ишан Расүлев кебек шәхесләрнең хезмәтләрен, мирасын, тәрҗемәи хәлләрен өйрәнә башладык.

Мәрҗани хәзрәтләре: «Өч әйбер диндә булмаса да, алар динне саклый», – дигән. Болар – милли тел, милли кием һәм милли гореф-гадәт. Мәрҗани хәзрәтләренең тормыш юлында булган вакыйгаларны укып белгәч, ул сукмактан тайпылмаска тырышабыз. «Ислам динен кабул итүгә 1000 ел» исемендәге мәдрәсәдә, татар теле, әдәбияты һәм тарихы белән бергә, барлык фәннәр дә татар телендә укытыла. Киемгә дә игътибар итә

*Журналыбызның узган санында Ульяновск өлкәсенең Иске Кулаткы районы башлыгы Эдуард Әнвәр улы Ганиев ярдәме белән Болгар шәһәрендә оештырылган XVIII Кулаткы укулары турында язган идек. Хәзер исә «Ислам динен кабул итүгә 1000 ел» исемендәге мәдрәсә ректоры Ильяс хәзрәт Җиһаншин сөйләгәннәр белән таныштырабыз.

башладык: укучыларыбыз һәм остазларыбыз элеккеге мәдрәсә шәкертләре формасында – махсус тегелгән казакидан йөри. Гореф-гадәтне исә без беркайчан да онытмадык.

Кайвакыт Мәрҗани хәзрәтләре турында төрле фикер әйтүче һәм язучылар бар. Шиһабеддин хәзрәтләре беркайчан да традициягә, гореф-гадәткә каршы килмәгән, гыйлемгә, акылга таянып эш иткән. 14-15 яшьләрендә бабасына биргән бер соравы турында менә мондый истәлек бар. «Коръәнне тәһарәтсез укырга ярый, әмма тәһарәтсез тотарга тиеш түгел. Моның хикмәте нәрсә?» – дип сораганга, бабасы Сөбхан: «Кул нәҗесләнә, авыз нәҗесләнми», – дип җавап биргән. Әмма бабасының җавабына канәгатьләнми, шул ук мәсьәләне атасыннан да сорый. Атасы, ачуланып: «Бабаң җавабына канәгать итмисең? Аның гыйлеме башкалардан ким түгел!» – дигән. Димәк, шулвакытта ук Мәрҗани башкалар алдында өстен булган. Югыйсә, Сөбхан бабасы – Кысна авылы имамы, мөгаллим. Әтисе Баһаветдин хәзрәт – Ташкичү имамы, гыйлем иясе. Ә шәкерт берсенең дә җавабыннан канәгать түгел! Аңа дәлил, төпле фикер кирәк.

Традиция, гореф-гадәтләргә килгәндә, хәтерләсәгез, шундый вакытлар булды. Каберлеккә барып дога, зиярәт кылуны тыючы, кабер ташларын куюга каршы төшүчеләр бар иде. Бу турыда кайбер хәзрәтләр вәгазь дә сөйләде, китаплар да язды. Хәзерге көндә мондый каршылыклар юк диярлек, киресенчә, элекке гореф-гадәтләребез яңара гына.

Без янәдән Мәрҗани хәзрәтләренең гамәли мисалына кайтабыз. Ул үзенең «Хаҗ сәфәре» дигән китабында менә ниләр яза. Мәккә белән Мәдинә калалары арасында Йәнбәгътә исемле шәһәр бар. Шиһабетдин хәзрәтләре хаҗ сәфәренә барган вакытында шунда туктала, **Хаҗи Хөсәен бине Йосыфның каберен сорашып эзләп таба һәм аның рухына Коръән укып, дога кыла**. Бу зат Казанның беренче мәхәллә байларыннан булып, тагын ике кешене үз акчасына хаҗга алып барганда юлда вафат булган икән.

Кайчакта: «Кабер өстендә таш булырга тиешме? Гомумән, куеп тору кирәкме? Бу гамәл дөрес буламы?» – дигән сораулар белән баш ваталар. Кабер өстенә таш кую мәсьәләсендә Мәрҗани хәзрәтләре вафатына өч ай кала язган бер хатында ошбу сүзләрне әйтә: *«Бисмилләәһир-рахмәәнир-рахиим. Газиз, кадерле вә мөхтәрәм шәкертебез Хаҗ әл-Харамәйн әш-Шәрифин мелла Гобәйдулла... Мин бик картайдым. Саулыгым да юк. Яшем җитмеш өчкә җитте. Көннән-көн зәгыйфьләнәм. Бернәрсә ашый алмыйм. Моннан ары хат яза алуым да мәгълүм түгел. Хуш, сәламәт булыгыз! Безгә хәер-дога кылыгыз!* ***Үлсәм, каберемә бер таш яздырып куй. Бик кечкенә, бер-ике кеше күтәреп китәрлек булмасын һәм рус сүзе, рус елы (милади) куелмасын»***. Зиярәт итү, дога кылу һәм кабер ташы мәсьәләсендә Мәрҗанинең гамәле безгә үрнәк була түгелме?!

Янә бер вакыйгага тукталасым килә. «Ислам динен кабул итүгә 1000 ел» исемендәге мәдрәсә Ал мәчет бинасына урнашкан. Мәрҗани хәзрәтләре «Мөстәфадел-әхбәр фи әхвали Казан вә Болгар» дигән китабында гыйбадәт йортының 1808 нче елда Муса бине Исмәгыйль бине Апанай кызы Зөбәйдә мирасы хисабына салынганлыгы турында язып калдырган. Ул мәчетнең михрабы көньяк ноктадан 5 градус һәм кыйбладан 10 градус көнчыгышка авыштырылып, ягъни ялгыш эшләнгән. 1905-1906 елларда Казан байларыннан булган Мөхәммәдсадыйк Галикәев, Шиһабетдин хәзрәтләренең кайчандыр әйткән сүзләрен истә тотып, Ал мәчетне кыйблага таба төгәл юнәлтеп, зурайтып төзетә. Менә шундый затлы, зыялы байлар Шиһабетдин хәзрәтнең йомышчылары булып, аның кирәк-ярагын, матди ихтыяҗларын һәрвакыт кайгыртып килгән. Хәтта аннан рөхсәт сорамыйча, янынннан китеп тә бармаганнар.

Мәрҗани хәзрәтләре, үләренә бер атна калгач, Садыйк әфәнде Галикәевне янына чакыртып 480 сум акча бирә һәм бу сүзләрне сөйли: *«Бу акча «Хазәмә»не бастырырга, аны яхшы итеп бастырырсыз. Төзәтергә өч шәкерткә (Габдрахман, Кәшшаф*

XVIII Кулаткы укуларында катнашучылар. 2018 ел, март

һәм Насретдинга) бирерсез. Аларга төзәткән өчен акча бирерсез. Баштан ук акчасын сөйләшеп бирегез. Басылып чыккач, фәләннәргә (егерме кеше исәпләде) бирерсез бүләк итеп бирәр нөсхә». «Вафийәтел-әсләф»нең соңгы томы турында менә ниләр ди: *«Моны Борһан хәлфәгә биреп, акламага күчертерсез. Яхшы дикъкать белән күчерсен. Ике нөсхәнең берсе монда калыр. Икенчесен, матур итеп тышлатып, хаҗга барганда алып барырсың. Истанбулда зуррак даирәләргә күрсәтерсең. Бәлки, китапны бәяләп, бастырырлар. Әгәр мөмкин булса, ул нөсхәне Мәдинәи-Мөнәвәрәдә «Гарифбәк» китапханәсенә бүләк итәрсез».* Бу васыять үтәлгәндерме, юкмы – безгә билгесез, әмма Шиһабетдин Мәрҗанинең гомере азагына кадәр бик күп мәшәкать чигеп язган китаплары татарлар арасында тиешенчә бәяләнмәве – факт.

Мәрҗани үз гомерендә өч дистәдән артык гыйльми хезмәт язып калдыра. Шулар арасыннан нибары унөче генә басылып чыга. Гарәп телендә язылган дини, тарихи, фәлсәфи кулъязма һәм басма китаплары нигездә Казан федераль университетының Н.Лобачевский исемендәге Фәнни китапханәсендә саклана. Безгә Мәрҗани хәзрәтләренең мирасын, хезмәтләрен өйрәнәсе дә өйрәнәсе әле. Аның фикерләрен искә алып, ул салган эздән барсак, беркайчан да югалмабыз, иншаллаһ. ■

Безнең мирас №5 май 2018

Урманай авылы күренеше

Халык язган китап

Эльвира Ихсанова

Авылымның тулы язмышын үз эченә алган «Бай тарихлы Урманай» дигән китап шушы көннәрдә дөнья күрде.

Соңгы елларда Азнакай районының тарихын, авылларын, аерым шәхесләрен чагылдырган шактый китаплар басылып чыкты. Без, азнакайлылар, үз төбәгебезне, аның гүзәл Ык буйларын, мәшһүр Чатыртауны, эш сөючән халкын чиксез яратабыз, күренекле шәхесләре белән горурланабыз. Әйе, халык бүгенге көн белән генә яши алмый, үткәннәрнең сабакларына, акылына һәм зирәклегенә таяна ул. Район хакимияте башлыгы Марсель Зөфәр улы Шәйдуллин бу мәсьәләгә бик игътибарлы. Бу җыентык та нәкъ менә аның тәкъдиме белән язылды. Проектны тормышка ашыруда матди ярдәм күрсәтүче шәхес «Татнефть» акционерлык җәмгыятенең генераль директоры урынбасары Азат Фердинанд улы Ягъфәров булды. Китап чыгаруны оештыруда җаваплы булган Азнакай хакимияте башлыгы урынбасары, техник фәннәр кандидаты Нәҗәт Нәгыймов белән берлектә зыялы шәхесләребездән торган редколлегия төзелде. Китапны төзүче – язучы, Татарстан Республикасының атказанган мәдәният хезмәткәре Марсель Мөхәммәтша улы Гарипов (Мирсәй Гариф), төп редакторы – шагыйрь, Татарстанның атказанган авыл хуҗалыгы хезмәткәре Илдус Сабир улы Гыйләҗев.

Җыентык 14 бүлектән тора. Андагы мәгълүматларның шактый өлеше архив, мат-

Китапны чыгаруда катнашкан редколлегия әгъзалары: Илгиз Шакирҗанов, Илзир Мәрданшин, Азат Ягъфәров, Марсель Гарипов. Басканнар (сулдан уңга): Елена Закирова, Илдус Гыйләҗев, Гөлгенә Хәйбуллина, Эльвира Ихсанова

бугат документларына таянып язылган. Китапта төрле язмалар, шулай ук истәлекләр, риваятьләр нигезендә авыл тарихы, биредә яшәүче халык язмышы, рухи байлыгы һәм аерым шәхесләре турында бәян ителә. Шундый шәхесләрнең берсенә – авылыбызның төзелешенә зур хезмәт куйган «Урманай» совхозы директоры Фердинанд Каюм улы Ягъфәровка тулы бер бүлек багышланды. Бу күркәм шәхеснең нәселе, гаиләсе, язмышы һәм, әлбәттә, аның созхоз директоры буларак эшчәнлеге яктыртылды.

Киң җәмәгатьчелекнең игътибарын авыл тарихы бүлегенә юнәлтмичә булмый. Автор-төзүче Марсель Гарипов, тарих төпкеленә төшеп, хәтта Алтын Урда чорына кадәр барып җитеп, Урманайның һәм шушы төбәкнең кайчан һәм ничек барлыкка килүе турында ышанычлы материал туплады. Язмамда төбәкне өйрәнүче Р.С.Зариповның «Азнакай-Тымытык төбәге тарихы» китабындагы түбәндәге юлларына тукталасым килә: *«Азнакай төбәгендәге җирле халык – нигездә, казан татарлары. Ләкин бу соңгы нәтиҗә түгел әле. Икенче ревизия материаллары төбәк татарларын формалаштыруда чукынмаган чуваш, мукшы, чирмеш, ар һәм типтәрләр дә катнашуын ачык күрсәтә. Авылга татарлар белән бергә чукындырудан курыккан, югарыда әйтелгән халык вәкилләре дә килеп төпләнгән. Бу авыл аксакаллары сөйләп, язып калдырган истәлекләр белән дә раслана. Күп кенә атамалар – топономикалар шул турыда сөйли. Азнакай төбәгендә бердәнбер, бүгенге көнгәчә сакланып калган чуваш авылы – Якты Күл бар. Тагын бер компонент – бу яклардан җир әләктерү өчен үзләрен «башкортлар» дип атаган типтәрләр. XVIII гасыр башында башкорт халкының (дөресрәге, рәсми кәгазьләргә үзен башкорт дип яздырган халыкның) саны, ким дигәндә, ике мәртәбә арткан. Бу нилектән шулай булган, ягъни «башкорт татары» сословиесе барлыкка килгән? Ул елларда Петр патшаның яңа указлары буенча елына җан башына 1 сум 10 тиен салым түләргә мәҗбүр ителгән татарларга дәфтәргә башкорт булып теркәлү отышлырак булган. Билгеле булганча, Уфа провинциясендә яшәгән мишәрләр бары тик 1747 елда гына (әлек кимрәк булган), анда да җан башыннан 25 тиен, типтәрләр 80 тиен (ә татарлардан ул чагында – 1 сум 70 тиен-2 сум, 1770 елларда инде 2 сум 70 тиен күләмендә) салым түләү тәртибе*

Беренче Бөтендөнья сугышының хәрби әсирләре. Икенче рәттә уңнан беренче булып утырганы – Гаффар Гайсин. 1914 ел



СВОДЪ

дѣйствующихъ постановленій, опредѣляющихъ права, обязанности и отвѣтственность запасныхъ нижнихъ чиновъ, поступившихъ въ военную службу по правиламъ устава о воинской повинности 1874 года.

I.

Общія положенія о правахъ и обязанностяхъ.

1) Состоящіе въ запасѣ нижніе чины подлежатъ дѣйствію общихъ законовъ и пользуются, на общемъ основаніи, личными и имущественными правами своего состоянія, продолжая числиться въ составѣ тѣхъ обществъ, къ которымъ принадлежали при вступленіи въ службу, а также тѣми правами, кои пріобрѣтены ими на военной службѣ, но подчиняются

Урманай авылы кешеләрендә сакланган бер документ

кертелә. Мондый бүленү һәм аеручa башкорт катлавы булып язылырга омтылу Уфа провинциясендә яшәгән халыкларга әле соңрак та өстенлекләр китерә. 1832 елда закон буенча, мәсәлән, башкортларның һәр ир-атына – 40, типтәр һәм мишәрләргә – 30, ә татар белән чувашка 15 дисәтинә генә имана җире бирелә. (Ә.Әсфәндияров. Башкорт авыллары тарихы. 1990.) XVIII гасырда татар ирләренең ни өчен «башкорт»ка әйләнүен күзаллау читен түгел».

Шушы фикерләрне дәлилләп, кабат китабыбызның төзелешенә кайтасы килә. «Бай тарихлы Урманай» җыентыгының кушымта өлешендә «Башкорт ыруы тарихы». (Юрмый. Т.21. – Уфа. НИЯЛ УНЦ РАН: Китап. 2016.) дигән китаптан «XXII Башкорт кантонының казаклар һәм урядникларның ничә яшьтә булуы, хезмәткә керү вакыты, соңгы командировка датасы, 1843 елда ничә тапкыр хезмәттә булуы исемлеге» бирелгән. Икенче исемлек – 1900 елгы (халык санын алу) перепись мәгълүматлары. Өченчесе – латин графикасында язылган 1934 елгы хуҗалык китабы. Әлбәттә, тарих галимнәре өчен бу фикерләр бик самими булып күренер. Безнең максат исә үз нәселе белән горурланучы ватанпәрвәр буын тәрбияләү, шушы исемлекләргә нигезләнеп, «Җиде бабаңны бел» дигән шигарне киләчәк буыннарның күңеленә дә салып кую иде. Җыентыкта авыл тарихы белән кызыксынучы ил картларыннан ишеткән тәгъбирләр, фаразлаулар да урын алды.

Язучы Гариф Галиев (рәсемдәге ике баланың кайсысы Гариф икәне төгәл мәгълүм түгел) әти-әнисе һәм туганнары белән. 1905 ел

Китапны эшләгәндә, топонимик атамаларының ни рәвештә барлыкка килүен дә ачыкларга тырыштык. Авылыбыздагы һәрбер оешманың тарихын, анда хезмәт куйган шәхесләрен бөртекләп барладык. Бүгенге көндә авылыбызда яшәүчеләрнең эшгамәлләре, күңел байлыклары турында да сөйләргә тырыштык. Урманай авыл советы территориясендә юкка чыккан Май заводы, Көчле Бүләк, Моратовка, Галимовка авылы тарихлары да яктыртылды.

Китапта урын алган йөзәрләгән фото тарихчылар өчен бәяләп бетергесез байлык булыр, дип уйлыйбыз. Шундый уникаль фотоларның берсе 1914 елда Алманиядә әсирлектә булучылар турында сөйли. Фотода икенче рәттә уңнан беренче булып утырган кеше – Гаффар Гайсин. Ул 1890 елда Урманай авылында туган. Хәрби хезмәткә алынгач, Беренче Бөтендөнья сугышы башлана. Барлык хәрбиләрне фронтка җибәрәләр. Гаффар (Габделгаффар) Гайсә улы дошманга әсирлеккә төшә. Мондый язмышлар турында истәлекләр һәм фотосурәтләр җыентыкта бихисап. Әлеге китаптагы һәр язмыш – татар халкы тарихының бер сәхифәсе ул. Татар әдәбияты тарихы өчен кызыклы тагын бер экспонат – танылган язучы Гариф Галиевнең әти-әнисе белән 1905 елда төшкән фотосурәте.

Авылыбыздан чыккан талант ияләре дә шактый: алда телгә алып үткән Гариф ага Галиев, Сәрия Вилданова, Илмира Сәлахова һ.б. Китапта аларга да тулы бүлек багышланган. Җыентыкның әдәби бизәлешенә баш редактор Илдус Гыйләҗев аеруча игътибар итте: һәр бүлекне төбәгебездә иҗат итүчеләрнең шигырьләре белән баетты ул. Кызганыч, бу проект легендар шәхесебезнең – могтәбәр Илдус Сабир улының актык хезмәте булды. Гомеренең соңгы көннәренә кадәр ул безнең белән очрашты, мәкаләләрне шәрехләде, иҗатта кайнады, безне төптән торып фикер йөртергә өйрәтте.

Әйе, тарихны барлаучылар – киләчәккә атлаучылар! Бүген рухи байлыкны матди мөмкинлекләргә алмаштыра барган заманда авылларыбызның эзе карталардан бөтенләй югалуы мөмкин. Ә бит кайчандыр аларга әллә кайлардан килеп нигез салучылар булган, шуннан авыл тернәкләнеп яшәп киткән. Ничәмә-ничә еллар, гасырлар дәвамында яшәп-яшьнәп килгән авылларыбызда бармак белән санарлык яшьләр һәм өлкәннәр генә кала бара. Саклыйсы, яшәтәсе иде авылларны. ■

Меңьеллык тарихлы Яуширмә

Наилә Фатыйхова-Потеева

Идел-Урал милли азатлык хәрәкәтенең бөек юлбашчысы, атаклы язучы һәм журналист Гаяз Исхакыйның туган җире Яуширмә – тамыры белән Болгар дәүләтенә тоташкан, халкы мең ел элек үк ислам динен кабул иткән борынгы татар авылы. Хәзерге Яуширмә урынына яки аның тирәсенә кешеләрнең тәүге тапкыр кайчан аяк басканлыгы турында төгәл мәгълүмат юк. Шулай да, авылның бай һәм үзенчәлекле тарихын чагылдырган документлар, әби-бабайлардан язып алган истәлекләр шактый.

КӘЛӘЙ АВЫЛЫНДА МОРАД БАБАЙ ЭЗЛӘРЕ

XVI йөзгә кадәр Яуширмәнең «Кәләй» исеме белән аталганлыгы билгеле. Авыл рус документларында Октябрь инкыйлабына чаклы «*Деревня Каляева – Малая Бахта тож*» дип теркәлгән. Аксакаллар сөйләвенә караганда, Кәләй – авылны нигезләгән кеше исеме. Мөгаен, бу кеше Кәлимулла исемле булып, аны Кәләй дип кыскартканнардыр. Күршедәге Урманасты Шонталысы авылында да «Кәләй» коесы бар.

Чирүле Шонталысында патшага хезмәт иткән Морад бабай яшәгән. Отставкага киткәндә аңа бирелгән җир күләме шактый зур була. Морад бабай, җирне үзенең биш улына бүлеп, аларны Чирүле Шонталысы, Яуширмә, Мөслим һәм Нарат Елга авылларына күчерә. Габдерәзәк исемле улы Кәләй авылына килеп төпләнә. Ул килгәндә авыл халкы берничә дистәдән артмый.

Морад – тугызынчы буын бабабыз. Аның нәселе 1750 елларда бик ишәеп китә. Яуширмә һәм алда телгә алынган авылларның халкы нигездә шул токымнан. Бу нәсел кешеләре киң җилкәле, таза гәүдәле. Борынгыларның сөйләвенә караганда, Морад

бабай Чирүле Шонталысында җирләнгән. Авылдагы «Аксакал кизләве»нең исеме дә Морад бабай хөрмәтенә аталган.

Яуширмәнең төньягындагы кечкенә генә күл буена Тәтеш өязе Тархан авылыннан тагын бер нәсел килеп урнаша. Күчеп килүче Тархановларның борынгы бабасы була. Сембер ягыннан Гыйният Йосыпов, Әхмәт Вәлиев, Гали Вәлиев, Хафиз Исмагыйлевләрнең бабалары да килеп төпләнә. Бишенче нәсел Зөя өязенең Тау Иле (Әрә елгасы буе), Бишбатман, Акъегет авылларыннан килә. Аларның башында Арыслан бабай торган. Гариф Садыйков, Вәлиәхмәт Мөхтәсимовлар – аның токымыннан. Нәфис сүз остасы, халкыбызның танылган артисты Фәйзи Йосыпов та шул нәселдән.

Авылның көньяк-көнчыгыш өлешендә, елганың көнчыгыш ярындагы 10-15 йортта руслар яшәгән. Татарлар руслар белән гел ызгышып торган, еш кына зыян салу очраклары да булган: дуңгыз, казларын үтергәннәр, хәтта йортларына ут төртеп тә киткәннәр. Ахыр чиктә руслар җәбер-золымга түзә алмаган, үз җирләрен ташлап, Рус Майнасы авылына күчеп китәргә мәҗбүр булган. Авыл халкы исә руслар яшәгән җирне әле дә Майна тау башы дип йөртә. Рус Майнасы картлары бабаларының кайчандыр Яуширмәдән килеп нигез корганын әле дә яхшы хәтерли. Авылда берничә чуаш гаиләсе дә яшәгән, хәзер инде алар татарлашкан.

Олы яшьтәгеләрнең сөйләвенә колак салсак, Котлы-Кәләй авылы кешеләренең күбесе, чукындырудан куркып, урманда, су буйларында, камыш араларында куыш корып яшәгән. Куышны «ширмә» дип атаганнар. Бу – яудан, дошманнан качу ширмәсе. Шуннан «Яуширмә» сүзе килеп чыгып, авылның исеменә әйләнеп киткән, имеш. Торабара Кәләй исеме онытылып, авыл рәсми рәвештә Яуширмә дип атала башлаган. Әмма: *«Атаманы болай аңлату җиңел юл белән котылу, дип уйларга кирәк. Ул чын мәгънәсендә «халык этимологиясе»нә бик нык охшаган. Татарстан җирендә ширмә сүзе белән шактый атамалар сакланган. Орымширмә һәм Икширмә авыллары... Удмурт җөмһүриятендә Гөлширмә исемендә су һәм авыл бар. Ширмә сүзенең су-елга белән бәйләнештә булып, җырма-җырмак сүзенә барып тоташуы бик ихтимал»*, – дип саный Фирдәвес Гарипова.

Авылның русча исеме – Кутлушкино. Бу исем Котлы бабай – Котлы Шәйхетдин белән бәйле. Якын-тирәдәгеләр «Котлы»ны «Котлушка» дип йөрткән, ахыр чиктә ул Кутлушкинога әверелә. Авылыбыз янында кеше исеменнән ясалган Гаделшә (Гаделшаһ), Шахмай (Шәехмамай) һәм Мөслим атамалы авыллар бар. Алар русча Адельшино, Шахмайкино, Муслюмкино дип атала.

Равил Юнусов бабайлар сөйләп калдырган менә мондый мәгълүматны да җиткерә: *«Авылның төп урыны – Ханнар буасы тирәсендә. Тормыш шуннан башланган. Без яшәгән авыл – яңа авыл, аның баштагы исеме **Яшьтирмә** булган. Тирмә – йорт дигән сүз. Башка бүленеп чыгып, яңа тормыш төзелгәнгә шундый исем алган безнең авыл»*.

ХАННАР БУАСЫ ЯКИ ЙӨЗ ЧИШМӘНЕҢ СЕРЕ НӘРСӘДӘ?

Авылдан ике чакрым чамасы ераклыкта, Кырмавыклы елга (Кыр инеше) янында Ханнар буасы – Йөз чишмә дигән бик матур урын бар. Анда үзенең тәмле суы белән аерылып торган йөз чишмә аккан. Соңрак, бу чишмәләрнең агымын бергә кушып, буа ясаганнар. XIII йөздә бирегә хан токымыннан булган кешеләр килеп урнашкан. Аның төньяк өлешендәге атауда чүлмәк ватыклары, таш кисәкләре, хайван сөякләре бик күп табыла. Күлнең югары өлешеннән көнбатышта биек урын бар. Аңа менеп, күп авылларны күзәтергә мөмкин. Ике урында озынча, зур баз бар. Азлан кырындагы тигезлектә кеше кулы белән өелгән түгәрәк калкулык беленә. Моны «Мар калкулыгы» диләр. Ул күзәтү урыны булган, дип уйланыла. Хәзер исә калкулык елдан-ел тигезләнә бара. Картлар бу тирәне «Яуш мазары» («Сугыш каберлеге») диләр иде.

«Ханнар буасы» дигән җирне сөргәндә ук һәм сөңге очлары, тутыгып беткән кылычлар табылган. Тракторчылар, сабан артыннан кеше сөякләре дә шактый гына чәчелеп кала, дип сөйли иде. Сугыш вакытында булса кирәк, аларны тирәнгә күмеп тә тормаганнар. Бу урында аерым бер кабилә яки ханның биләмәсе булган, дип фикер йөртергә мөмкин. Алар, башка кавем-кабиләләрдән саклану өчен, күзәтү урыны төзегәннәрдер.

«Ханнар буасы» атамасы булуы сәбәпле, Котлы-Кәләй авылына Морад бабай улы Габдерәзәк килгәнче үк, нугай морза яки ханнары нигез салмадымы икән, дигән сорау туа. Күрәсең, шушы вакыйгаларның истәлеге булып, әлеге топоним халык күңелендә сакланып калган.

КОТЛЫ – ЯУШИРМӘГӘ НИГЕЗ САЛУЧЫ

XIII йөздә, хан кысрыклавыннан качып, Котлы Шәйхетдин исемле аучы һәм аның уртанчы энесе Кәләй үзенең кабиләсе белән хәзерге Яуширмә җиренә килеп урнашкан. Котлы авылының тирә-ягында урман, кечкенә елга һәм күлләр, камышлыклар булган.

Котлының хуҗалыгы – хәзерге авылның уртасыннан агучы инеш буенда урнашкан. Ул җирдә күп еллар медпункт һәм Галләм бабайның бакча артыннан алып, Хөснетдинов Рафиклар алдына чаклы бушлык иде. Котлы – бик кодрәтле һәм дөреслекне яклый торган кеше. Шуңа күрә аны тирә-якта яшәүче халык хөрмәт иткән, аңа киңәшкә йөргән. Риваятьләргә караганда, Котлы кабиләсе, ханнарны тар-мар итеп, җирләреннән куып җибәрүгә ирешә. Күп еллардан соң хан Котлыны үзенә алдыра, шул китүдән ул кире әйләнеп кайтмый. Кабилә башлыгы булып энесе Кәли-Кәләй кала. Хәзер дә авыл халкының бер өлеше Котлы-Кәләй нәселеннән булырга тиеш. Шуңа күрә, авыл халкы бәйсез һәм ирекле булып яшәргә тырыша.

НИЧӘ ЯШЬ СИҢА, ЯУШИРМӘ?

Мин үскән вакытта авылыбызның мулласы Фәйзерахман бабай әтием, ул елларда авыл советы рәисе булып эшләгән Шәрәфетдин улы Сәгъди янына еш килә иде. Бервакыт хат тотып: «Мин сиңа Гаяз Исхакыйдан сәлам җиткерергә кердем», – ди. Шуннан соң тагын ике мәртәбә Гаяз Исхакыйның сәламен әтигә китергәнен хәтерлим. Алар сөйләшкәндә мине үз яннарыннан куып җибәрәләр, шулай да күп сүзләре колагыма кереп, хәтергә уелып кала торган иде. Бервакыт мулла бабай безгә гарәпчә язылган дәфтәр тотып керде. Ул елъязма яки ниндидер тарихи китапчык иде, ахрысы. Анда авылыбызга моннан 650 ел элек нигез салынган, дип язылган, ә ул вакытлардан соң инде 60 еллап вакыт үтте. Бу чыганакка нигезләнсәк, Яуширмәгә хәзер 700-750 еллар бар. Димәк, Котлы-Кәләй авылының XII-XIII йөздә оешуы хак. Мин ул дәфтәрне эзләп карадым, кызганыч, таба алмадым.

ЯУШИР СУЫ БУЕНДА ИСЛАМ ДИНЕН КАБУЛ ИТҮ

Тарихчы Равил Фәхретдинов «Мондадыр безнең бабайлар» исемле китабында: *«Ибне Фадлан Алмас патша ставкасында июнь урталарына кадәр тора. Шуннан соң гарәп илчеләре Алмас һәм аның яраннары белән бергә* ***Җаушир елгасы*** *буена күчеп китәләр. Патша әмере буенча анда барлык болгар кабиләләре дә, мәсәлән, болгарларның үзләреннән башка суар, эскил һ.б. кабиләләр җыелып, бөтен ил белән ислам кабул итәләр. Ике айга сузылган барлык эшләр дә тәмам булгач, Ибне Фадлан һәм илчелек Идел буйлап, Хәзәр аша кире Багдадка кайтып китә»*, – дип язган.

Дин кабул итү өчен гадәти, кешеләр яшәгән урын кулай түгел, ә ару су, чиста урын кирәк булган. Мәкаләбездә әйтеп үтелгән «Ханнар буасы» – «Йөз чишмә», хәзерге Яушир-Җаушир суы мөэминнәрне шул максат белән үзенә тарткан булса кирәк.

ХАННАР БУАСЫНДАГЫ БОРЫНГЫ ТАБЫЛДЫК

Әлеге тарихи буа мине дә үзенә җәлеп итте. 2006 елның җәендә без биш бала, гаиләләребез белән туган йортта җыелып, Корьән мәҗлесе уздыргач, бала-чаганы алып, Ханнар буасына барып кайттык. Шуннан соң бу гамәл безнең гаилә традициясенә әйләнде. Биредә бик тыныч, энергетика аеруча яхшы, дөньяңны онытып, сихри рәхәтлектә каласың. Әстерханда Итил, Алтын Урда археологиясе эшләрендә катнашкан кеше буларак, мин дә Ханнар буасы тирәсен бераз казып карарга булдым һәм 30 см тирәнлектә металлдан эшләнгән каз аягы формасындагы табылдыкка юлыктым. Соңрак әлеге табышымның бизәнү әйбере, «гусиные лапки – шумящие подвезки, обереги» дип аталганын белдем. Аны VIII-IX гасырларда болгарлар, борынгы төрки бабаларыбыз ислам динен кабул иткәнче кулланган. Моңа нигезләнеп, Яуширмә – мең елдан артык тарихлы борынгы болгар-мишәр авылы, дип нәтиҗә ясарга тулы хакыбыз бар.

НЫК ИМАНЛЫ КОТЛЫ-КӘЛӘЙ ХАЛКЫ

Котлы-Кәләй халкының бер өлешен Актауга алып барып чукындырганнар. Чукынганнарның йорт-җире Майна тау башында урнашкан. Авыл халкы аларны «мокыт», «мөртәт», «зобани» һәм, әлбәттә, «керәшен» дип атаган. Керәшеннәр иконатәреләрне христиан бәйрәмнәрендә генә сәке, идән асларыннан чыгарып, поп киткәч тә яшереп куя торган булган. Аларга мәчеткә керү тыелган, мулла никах һәм җеназа укымаган. Әгәр укыса, имамга указы алыну куркынычы янаган. Керәшеннәрне татар-мөселман зиратына да җирләмәгәннәр. Алар, мөселманнар белән бер авылда яшәргә авыр булганлыктан, яңадан асыл иманга кире кайткан, әмма авылдашлары хәтеренә «чукынган төп» дип мәңгелеккә уелган. Озак еллар дәвамында бу нәсел халкына кыз да бирмәгәннәр. Шундый берничә «төп»не олы яшьтәгеләр әле дә хәтерли. 1906 елдан гына аларны мөселман зиратына җирли башлыйлар.

Чукынганнар авылның төньягында, Бахта елгасының көнчыгышында, аръякта, Гәрәев Сәгыйр абзый хуҗалыгы алдындагы ачыклыкта җирләнгән. Халык теленә «мокытлар», «мөртәтләр», «зобанилар» зираты дип кереп калган бу урын кадер-хөрмәтсез булып, аның ян-ягы да киртә белән тотылмаган. Җирдән бераз калкып торган кабер урыннарын әле дә таныргa була. Кабернең олы кешенеке яисә баланыкымы икәне дә аерыла. Әнием, почта өләшкәндә, кабер өстенә басмыйм инде, дип, шул тирәне гел әйләнеп, ерактанрак уза иде.

ЗӨЛӘЙХА КАБЕРЕ

Бу кабернең кайда булганын төгәл беркем дә әйтә алмый. Чукындыру чорына бәйле бер вакыйга турында Миңнурый Абзалова менә нәрсә сөйләгән: *«Яуширмә кызын, зар елатып, тирә-яктагы рус авылына кияүгә бирәләр. Ул зур авырлыклар, әр-хур күреп, туган туфрагына кайтып егыла. Әмма, чукындырылган булганга, авыл аны күңеле белән кабул итми. Үлгәч, мөселман зиратына күмдермиләр. Ялгызын кырга, нindидер юл буена җирлиләр»*. Ул кабер турында элек авыл карт-карчыклары еш телгә ала иде. Олы яшьтәгеләр чукындырылган кызны Касыйм Әхмәтҗановлар нәселеннән, кушаматлары да аларның керәшен иде, диләр. Г.Исхакый «Зөләйха» пьесасына төп геройны шушы вакыйгадан алган. Дөрес, тирә-як авылларда да Зөләйха кебек чукындырылып, көчләп руска кияүгә бирелгән хатын-кызлар булган.

БАХТА – ЯТ СҮЗ

Авылны икегә бүлеп агучы Яушир суы кайчан «Кече Бахта»га әйләнгән соң? Олы яшьтәгеләрдән бу сүзне бер генә мәртәбә дә ишеткәнем булмады. Бахта чукындыру шаукымы белән бәйле булса кирәк. Авыл тирәсендә яшәүче халык ислам динен кабул иткән чорда су –Яушир дип, XVI-XVIII гасырлардан соң, аерым кешеләр чукындырылгач, Кече Бахта суы дип атала башлый. Әмма Кече Бахта сүзе, елга исеме буларак та, авыл исеме буларак та халык күңеленә үтеп керә алмый. Алар авылны элеккечә үз исеме – Яуширмә, елганы Яушир суы дип йөрткән. Дәүләт кәгазьләрендә исә авыл – «Кече Бахта тож», авыл суы – «Кече Бахта елгасы» дип теркәлә башлаган. Кайчандыр борынгы бабаларыбызның ислам динен кабул итү урыны белән бәйле су да, көчләп чукындыру вакытында «изгеләштерелгән» һәм, әлбәттә, исеме алмаштырылган булырга бик мөмкин. Яуширмәдәге керәшеннәр мөселманлыкка кире кайткач, Кече Бахта сүзе бөтенләй халык теленнән төшеп кала.

БЕЗНЕҢ НӘСЕЛ – МОРАД БАБАЙ ДӘВАМЧЫЛАРЫ

Г.Исхакый язуынча, Морад бабай нәселе –Кырымнан, гәрәйләрдән. Мөхтәрәм аксакалның исеме, рухы авылдашларым күңелендә, буыннан-буынга күчеп, мәңге саклана. Авыл картлары XX гасырның 70 нче елларына кадәр дини бәйрәмнәрдә «Морад бабай рухына» дип кырга чыга, аның рухына Коръән укый торган иде. Бабам да безне үз янына җыеп, нәселебез башында Морад бабай торганы, аның Кырым, гәрәйләр нәселеннән икәне хакында кат-кат сөйләде. Үзенең беренче булып туган ир оныгына, безнең энебезгә аның хөрмәтенә Морад исемен кушты.

Сугышка кадәр бабам, әти белән Урманасты Шонталысыннан кайтканда, Чирүле Шонталысында туктап, Морад бабай кабере янында, аның рухына багышлап Корьән укыган, юл буенда үскән агачларны күрсәтеп: «Болар Морад бабай наратлары», – дип сөйләгән. Сугыштан соң әти үзе дә Чирүле Шонталысы зиратына барып, Морад бабай каберен эзләп карый, әмма таба алмый.

***

Авыл тарихындагы ак тапларның серен ачу өчен, Яушир суы буенда археологик казу эшләре оештырырга, сакланып калган архив документларын җентекләп өйрәнергә кирәк. Кызганыч, авылыбыз туфрагына хәзерге көнгә кадәр бер генә археологның да көрәге кермәгән. ■

Безнең мирас №5 май 2018

«НИМЕСЧӘ АШ»

(Бабам Габдулла Сәлаховның «фильтрацион эш»е)

Эльмира Сәлахова

Әби кунакка киткән вакытта бабам «нимесчә аш» пешерә, без – бер ишегалдында гына яшәгән оныклары – шуны ашарга җыела торган идек. Бигрәк тәмле иде ул. Бабай пешергәнгәме, әллә инде исеме безгә таныш түгел, «нимесчә» булгангамы? Белмим, күп еллар узса да, аның тәме әле дә хәтердә, бер тәлинкә генә булса да хәзер бабай пешергән шул ашны ашыйсы иде! Бәрәңгене бармак башы кадәр генә итеп, шакмаклап турап пешерелгән шулпа иде ул. Без – кечкенә балалар ул ашның ни өчен «нимесчә» аталуын белмәдек, сорасак та, бабам җавапсыз калды. Ул бик аз сүзле, гаять тә йомшак күңелле, эчкерсез, ихлас, тыйнак һәм шул ук

вакытта горур кеше булды. Аның язмышы турында үзеннән берни дә ишетмәдек диярлек, ләкин әби, безне бергә туплап, башыннан кичкәннәрне сөйли, аның янына чәй эчәргә кергәндә яисә төн кунарга калганда хикәятләр тыңлый идек. Сугыш башланып, беренче көннәрдән үк бабай фронтка алынганда минем әтигә нибары ике яшь була. Бу елларны хәтергә алганда, әби: «Сугыш безнең өчен җиде ел барды», – дия торган иде. Мәктәптә укыганда без сугышның җиде ел ук бармаганын белеп, әби ни өчен шулай әйткәнен аңлап та бетермәдек.

1945 елның ягымлы язы халыкка җан әрнүләре аша көтеп алынган шатлыклы хәбәр алып килә: исәннәр авылга кайта башлый, ә кем өчендер кара көннәр дәвам итә. Барысы да үзләренекен өмет белән көтә. Шул авыр көннәрдә авылга багучы килә. Ирләрен, әтиләрен көткән хатын-кызлар, шул исәптән әбием дә, барлы-юклы нигъмәтен алып, яхшы хәбәр өмет итеп, багучыга бара. Әмма багучы аның күңеленә хуш килерлек сүз әйтми. Әби: «Мин синнән шуны ишетергә килдемме?» – ди дә борылып китеп бара, ләкин багучы: «Кайта ул, кайта!» – дип кала. Шулай итеп, әбием бабайны җиде ел көтә. «Бабаң пленга эләккән, сугыштан соң кайтармаганнар, шахтага җибәргәннәр», – дип сөйли иде әби.

Ватан сугышы елларында 4,5 миллион совет солдаты әсирлеккә төшә, хәбәрсез югала. 1941 елның июль урталарына ук Советлар Союзы миллионга якын сугышчысын югалта. Ноябрь аена 724 мең солдат әсирлеккә төшә, ә инде 1942 елның февраленә әсирлеккә эләккән солдатларның саны 3 миллион 600 мең кешегә җитә, шуларның 2 миллионы фашистлар әсирлегендә үлә. Лагерь аша узучыларның 2,2 проценты татарлар була. Әсирлек хәлләре, анда эләккәннәрнең батырлыгы шактый өйрәнелде, күп кенә фундаменталь фәнни хезмәтләр дөнья күрде. Җәлилчеләр турында горурланып сөйлибез, киләчәк буынга гыйбрәт итәбез.

Сугышның, әсирлекнең башка ягы да бар бит әле. Кемнәрдер, фашист лагерьларыннан исән чыгып та, әсирлектә булганнары өчен, үз Ватанында җәберләнәчәкләрен белеп, читтә яшәп калуны кирәк таба. Безнең аларны гаепләргә, аларга тел тидерергә хакыбыз юк. Әсирләрнең күбесе үлем газабын үтеп, үз җиренә кайткач кимсетелә, хур ителә һәм төрлечә җәберләнә. Кемнәрдер кайтып җитмәс борын Сталин лагерьларына җибәрелә, ә «бәхетлерәкләре» «үз гаепләрен» завод-шахталарда, авыр сәнәгать предприятиеләрендә «юа». Әсирләр, хакимиятнең җәберен даими тоеп тору өстенә, авылдашларының да, кычкырып әйтмәсәләр дә, кырын карашын сизеп-белеп яшәгән.

Ил өстенә ябырылган фашист гаскәрләрен җиңү көне безнең өчен һәрвакыт изге бәйрәм булып калачак. Без – мәктәп балалары бу бәйрәмгә бик тырышып әзерләнә идек: яфрак яра башлаган агач ботагын алып, шуңа кәгазьдән үзебез ясаган чәчәкләрне беркетеп куябыз да аны төсле шарлар белән бизәп, бәйрәм парадына күтәреп чыга идек. Һәйкәл янында сугыш кырында ятып калганнарны искә алу, аларның батырлыклары турында ишетү, ветераннарның гыйбрәтле сүзләре – балачак хатирәсе булып күңелдә уелып калган. Парад беткәннән соң, тәмле күчтәнәчләрен төяп, сугышта бер аягын калдырып кайткан Яхъя бабам – әнинең этисе Буа шәһәреннән «Запорожец» машинасы белән килеп җитә иде. Аны көтеп, шулпа, бәлешләр пешә – Җиңү көне бәйрәмнәрнең дә бәйрәменә әйләнә.

Габдулла бабай бу көнне гадәттәгечә мәчеткә китә. Бәйрәм чараларына, белмим, чакыралар идеме икән аны, әллә чакырып та үзе бармадымы? Ул табигате белән ябык кеше иде. Рәхмәт, ветераннарга тиешле азык-төлек салынган бүләк пакетын бирделәр. Без моны бик төгәл хәтерлибез, чөнки бу күчтәнәчләр турыдан-туры безгә күчә торган иде.

Ике бабам һәм фронтовик авылдашларым мисалында ил өстенә килгән фашист яуларыннан Ватанын сакларга чыгып китеп, кан-яшь, мең газап белән Җиңү көнен

1942 елның февраленә әсирлеккә эләккән солдатларның саны 3 миллион 600 мең кешегә җитә, шуларның 2 миллионы фашистлар әсирлегендә үлә. Лагерь аша узучыларның 2,2 проценты татарлар була.

якынайткан кешеләрнең язмышын, шатлык-кайгысын күреп үстек. Барысының да максаты бер иде: илне яклау, саклау һәм дә исән-имин туган туфрагына, гаиләсе, туганнары янына әйләнеп кайту.

Автоматны беренче тапкыр тоткан япь-яшь авыл малае яисә гомере буе җир эшкәрткән, сука-сабан белән генә эшләгән агай сугышның алгы сызыгына куела. Әсирлектән исән кайткан кешеләрнең сөйләве буенча, аларның күбесенә агач мылтыклар гына тоттырганнар. Сугышның беренче көннәрендә үк илнең үзәгенә зур тизлек белән якынайган фашистларга каршы тору өчен бары бер киртә – совет солдаты була. Бик күп солдат кырыла, әсир төшә, алар моны үзләре дә белми кала. Минем бабам да Мәскәүгә якынлашып килгән фашист гаскәрләренә каршы яуда 1941 елның 17 октябрендә Малый Ярославец янындагы бәрелештә алгы сафтагы солдатлар белән ут дәҗҗалына эләгә. Яраланып, Совет гаскәрләре чигенгәннән соң, яу кырында ятып кала. Немецлар аларны җыеп, Смоленски өлкәсендәге әсирләр лагерена җибәрә. Анда бабам 1943 елның сентябренә кадәр тора, җир казу, юл төзәтү кебек эшләрне башкара. Соңрак аны да башка әсирләр белән бергә Гомель шәһәрендәге лагерьга күчерәләр. Андагы газаплары 1944 елның мартына кадәр дәвам итә. Лагерьда күргән авырлыклар турында бабай сөйләмәсә дә, аның кайбер гамәлләрендә, сәламәтлегендә яра-сызланулары сизелә иде.

Бабайның башыннан үткәннәре, күргән газаплары турында сөйләмичә калганнары архив документлары ярдәмендә ачыкланды. Әсирлектә булган кешеләрдән сорау алу, алга таба күзәтеп тору документлары саклана икән бит. Аларны «фильтрацион эшләр» дип атыйлар. Кызганыч ки, бу төр чыганаклар тарихчылар өчен хәзерге көндә дә ябык, әмма мин 2005 елда, оныгы буларак, бабам турында мәгълүмат тупланган документны кулыма алып, андагы һәр хәрефне йөрәгем аша уздырып, күз яшемә буылып укыган идем. Бабайның гаиләдә беребез дә белмәгән тәрҗемәи хәлен сөйләргә ашкынып авылга кайтканда, туксан яшьлек әбиемнең фани дөньяда соңгы көннәре иде. Әмма мин бу турыда сөйләргә өлгердем, ул тыңлады.

Бабайны әсирләр белән 1944 елның март аенда Германиягә алып киткәннәр икән. Анда ул Карл Шмидт дигән немецка хезмәткә бирелеп, Америка гаскәрләре азат иткәнче, 1945 елның апреленә кадәр шунда көн күрә. Менә кайдан килә икән ул «нимесчә аш»?! Гомере буе җир эшендә булган авыл кешесе өчен немец җирендә бил бөгү сугышта, лагерьда үткән газаплы елларга караганда бәлки җиңелрәк тә булгандыр, монда аны ач-ялангач та итмәгәннәрдер. Балачакта бабай берәр эш башкарганда, аш вакыты җиткәч, көрәкләрен ташлап, немецларның төп-төгәл вакытта ашаулары турында искә ала иде. Ул аларның төгәллегенә ихтирам белдерде.

Әсирлектә булган кешеләрне Ватанга җиңел генә кабул итмәгәннәр, аларны энә күзе аша уздырып, төрле сорау алулар, өсләреннән күзәтүләр белән җәфалаганнар. Бабайга ачылган «дело»дагы анкетада кая китәргә телисез, дигән сорауга ул: «Авылга – Буа районы Яңа Чәчкап авылына», – дип җавап биргән. Монда аны кечкенә баласы, әтиәнисе, туганнары көткән, ләкин ул сорау алганда баласы белән хатыны турында әйтми. Бу үзенә күрә бер саклык чарасы булмадымы икән? Әлбәттә, бабамның авылга кайтырга теләве беркемне дә кызыксындырмый, әсирлектә булуына җәза итеп, аны шахтага күмер чабарга билгелиләр. Тоткын икәнен җир астында бил бөккәндә дә онытмыйлар, даими күзәтү астында тоталар. Тәртибе турында җирле чиновник тиешле органнарга

Тоткын икәнен җир астында бил бөккәндә дә онытмыйлар, даими күзәтү астында тоталар. Аның тәртибе турында җирле чиновник тиешле органнарга хәбәр итеп торырга тиеш булган.

хәбәр итеп торырга тиеш булган. Аңа ачылган «дело»да болай дип язылган (төгәллекне бозудан куркып, текстны урыс телендә, алар язганча бирәм): *«Салахов проводит разложенческую агитацию среди рабочих на шахте и в общежитии по месту своего настоящего местожительства. Восхваляет жизнь в немецком плену и на американской территории, при этом высказывает недовольство на жизнь в районах Советского Союза. Кроме того, Салахов проводит проамериканскую агитацию среди рабочих, при этом заявляет, что Советский Союз готовится к войне, одновременно восхваляет военную мощь американцев и англичан, а также их технику, при этом недооценивает и компрометирует мощь Красной Армии»*.

Әлеге хәлләрне документ аша гына өйрәнүче тарихчы гына булсам, бәлки монда язылганнарга ышаныр идем. Әмма бу очракта туганнан бирле бабай белән бергә яшәгән онык буларак, монда гап-гади кешегә, Ватанны ихластан сакларга киткән солдатка оятсызларча яла ягу, аның язмышын җимерү өчен әшәке алымнарның кулланылуы турында әйтә алам. Авылның 3 класслы башлангыч мәктәбен тәмамлаган, ана теленнән башка телне белмәгән (анкетада шулай язылган) гади авыл кешесе, әле җитмәсә, табигате белән ябык, аз сүзле татар мондый агитацияне ничек алып барды икән дә, сәяси мәсьәләләрдә ничек фикер йөртте икән? Сугышка кадәр үк Свердловск һәм Мәскәү өлкәсендәге сәнәгать оешмаларында авыр хезмәттә эшләп алган бабай урыс телен бер дә белми калмагандыр, әмма аның мондый гаеп тагарлык агитация эшләре алып баруы мөмкин түгел. Биредә бер минем бабам турында гына сүз бармый, әсирлектә булган, Америка гаскәрләре тарафыннан азат ителгәннәрнең барысына да ягыла торган бертөрле, калыпка салынган гаепләү гыйбарәсе бу.

Шахта газапларын үтеп, туган җиренә кайткач та авылдашларының кырын карашын тою гына җитмәгән, әле аның өстеннән күзәтеп тә торганнар икән! Бабай моны үзе сизгәндерме, юктырмы, белмим. Бәлки сорау алырга да алып киткәләгәннәрдер. 1951 елны «дело»сына кызыл карандаш белән *«Салахов настроен проамерикански и явно пораженчески. Проверьте через агентуру, как он ведет себя и как работает на колхозном производстве»*, – дип язып куйганнар. Бары тик 1958 елда гына бабайга ачылган «дело» ябыла. Фильтрацияне узган кеше буларак, аны исәптән төшерәләр.

Бабамның сугыштан соңгы язмышын болай тәфсилләп язуым юкка гына түгел. Аның кебекләр илдә бик күп була. Бу – бабайлар узган язмыш сынавының бер мисалы. Күпләр бабаларының, әтиләренең әсирлектә булганын белсә дә, минем кебек үк, аның детален, тулы картинасын белми, чөнки алар дәшмәде, сөйләмәде, авыз ачарга да шүрләде. Кемнәрдер, вазгыять йомшый төшкәч, якыннарына күңел төпкелендә яшереп кенә саклаган кайбер нәрсәләрне әйтте, ләкин барысын да ачып салмады, чөнки алар куркытылган, өркетелгән иде. Бәлки инде әсирлек турында уйларга, искә төшерергә дә тырышмаганнардыр. Хәтта балаларын да «сатлыкҗан» дигән хаксыз тамга рәнҗетте. Күпләр кешеләрдән алу мөмкин булмаган җылылыкны, аңлауны, күңел тынычлыгын, диннең тыелган чоры булуына да карамастан, догада, гыйбадәттә тапты. Аларны шул яшәтте, авыр яраларын Аллаһка итагать кылу төзәтте. ■

РУСИЯ МӘМЛӘКӘТЕНДӘ АУТОДАФЕ

Ринат Фәхретдинов

Аутодафе (латинчадан – actus fidei – инану акты), киң таралган мәгънәсе буенча, XIII-XVIII гасырларда Аурупа илләренең (күбесенчә Испания һәм Португалиядә) инквизиция судында гаепле дип табылган кешеләрне – еретикларны тере килеш учакта яндыру процессын аңлата. Тарихчылар әйтүенчә, урта гасырларда Испаниядә генә аутодафе аркасында 30 меңнән артык кеше тере килеш учакта яндырылган. Аутодафе җәзасыннан һәлак булучылар арасында иң танылганы – галим һәм философ Джордано Бруно. Аны 1600 елның 17 февралендә Рим шәһәрендә яндыралар.

Русиядәге аутодафены, ул Испания һәм Португалия илләрендәге кебек киң колач алмаса да, бөтенләй инкарь итәргә ярамый.

Русия күптөрле дини дәүләт булса да, илдә православие юнәлеше хакимлек иткән. Юридик яктан бу хакимлек патша Алексей Михайлович вакытында 1649 елда кабул ителгән Соборное Уложениенең I нче бүлегендәге 1 нче маддәсендә чагылыш таба. Әйтик, әгәр берәрсе христиан динен мәсхәрәләсә, «...того богохульника обличив казнити, сжечь». (Памятники русского права. Вып. VI.М. 1957, 22 нче бит.) Яндыру җәзасы православие күзлегеннән еретик дип табылган кешеләргә дә кагылган. Моңа дәлил итеп раскольниклар хәрәкәтендә катнашучыларның язмышын китерергә мөмкин. Раскольниклык – XVII гасырның икенче яртысында барлыкка килгән дини юнәлеш. Православие белән раскольниклар арсында искитәрлек аерма булмаган. Аларны дини йолаларны үтәгәндәге берничә үзенчәлекнең үзгә булуы гына аерып торган. Мәсәлән, раскольниклар чукынганда ике бармак белән, ә рәсми православиедә булучылар өч бармак белән чукынган, «аллилуя» сүзен беренчеләре – ике тапкыр, ә күпчелек тарафдарлары өч мәртәбә кабатлаган һ.б. Ике дини юнәлеш арасында идеологик аермалар булмаса да, рәсми чиркәү раскольникларны көчле эзәрлекләүләргә дучар итә һәм аларның җитәкчеләре – протопоп Аввакум (Аввакум Петров, 1620-1682) 1681 елның 1 апрелендә, берничә актив иярчене белән бергә, махсус өелгән бурада яндырыла. Җитәкчеләрен шулай җәзалауга җавап итеп, Аввакум тарафдарлары үз-үзләрен массакүләм яндыра башлый. Тарихчылар исәпләвенчә, шул заманда егерме меңгә якын кеше үз-үзен яндырган.

Соборное Уложениедәге XXII бүлекнең 24 нче маддәсендә православие диненнән «бусурман» диненә, ягъни башка, «дөрес булмаган дингә» берәрсе үгетләп күчерсә, «...того бусурмана по сыску казнить, сжечь огнем» (Памятники русского права. Вып.VI.М. 1957, 434 бит). Бу маддә буенча 1738 елда рус флотының капитан-лейтенанты Возницынны һәм яһүди Борохны патшабикә Анна Иоановна указы буенча учакта яндыралар (ПСЗ РИ, Т.Х, №7612). Әйтергә кирәк, 1738 ел Русия тарихында дини эзәрлекләү буенча үзенчәлекле урын алып тора. Шул ук елда башкорт милләтеннән булган Тойгелде Җүләковны Екатеринбург шәһәрендә учакта яндыралар. Аның «гаебе» – мөселман диненнән христиан диненә күчкәннән соң, киредән исламга кайтып, дини йолаларны үти башлау. Гаҗәп ки, коточкыч җәзаны үтәүгә императрица Анна Иоановна исеменнән боерык бирүче, урысча әйткәндә, инициаторы булып алдынгы карашлы, укымышлы, талантлы дәүләт эшлеклесе, булачак атаклы тарихчы, Оренбург экспедициясе начальнигы Василий Никитич Та-

Протопоп Аввакум (Аввакум Петров, 1620-1682)



Мадрид мәйданында аутодафе. Франсиско Ризи. 1683

тищев тора. Тойгелде Жүләковны утта яндырыр алдыннан тау канцеляриясенең указы укыла. Указда аның чукынганнан соң, имеш, «богомерзкое преступление» ясап, «на свои блевотины возвратился», ягъни ислам диненә күчкәнлеге турында әйтелә (Бу турыда тулырак мәгълүмат: Н.К.Чупин. Сожжение на костре в Екатеринбурге в 1738 году (Из дел в Екатеринбургского горного архива) Русская старина т.XXIII. СПб.,1878 г.,309-313 битләр). Әлбәттә, ислам диненнән православиегә, ә соңыннан кабат мөселманлыкка күчүнең төп җәзасы аутодафе гына булмаган. Мәсәлән, чыгышы белән татар милләтеннән булган Табынлы казагы Роман Исаев хатыны белән христиан динен кабул иткән һәм, Уфа өязенә качып китеп, киредән ислам динен тота башлаган. Хөкүмәтнең карары белән ул 1740 елда, башка чукындырылганнарны өркетер өчен, үлем җәзасына хөкем ителә (ПСЗ РИ Т.XI, №8125).

Аутодафе. Михаил Зичи. 1868

Җәмгыятьтә толерантлык идеяләре тамыр җәйсен өчен, Русия дәүләтенә, Аурупа илләре кебек үк, озак һәм катлаулы тарихи юл узарга туры килә. Бу юлның чын мәгънәсендә катлаулы булуына Русиядәге аутодафе очраклары ныклы дәлил. ■

МАРГАРЕТ ХАНЫМ

Себастьян Цвиклински*

Узган 2017 елның 25 июлендә мәшһүр алман тюркологы, татар халкын бик тә якын күргән һәм хөрмәт иткән мөхтәрәм галим Маргарет Эрсен-Раш вафат булды. Аның Германиядә озак еллар татар, башкорт һәм төрек телләрен укытуда кылган игелекле эшен белгертү өчен, истәлекләремне сез укучыларым белән дә уртаклашмакчы булам.



Маргарет Эрсен-Раш һәм Илдар Харисов



Маргарет Эрсен-Рашның татар теле дәреслеге. 2009 ел

1941 елның 16 декабрендә Лейпциг каласында туып Франкфуртта үскән Маргарет ханым 1960 нчы елларда төрекләр белән таныша. Университетта төрекчә өйрәнгәннән соң, белемен Төркиядә һәм үзе яшәгән шәһәр төрекләре белән аралашып камилләштерә. Төрек егетенә кияүгә чыга, төрле уку йортларында һәм 1980 нче еллардан башлап Франкфурт университетының тюркология институтында төрекчә укыта. Шул ук елларда әзәри телен өйрәнә, ә Идел буендагы төрки телләр белән танышуы очраклы гына була. Тюркология буенча оештырылган конференциядә Маргарет Эрсен-Раш күренекле татар тарихчысы Миркасыйм Госманов, татар теле галиме Флера Сафиуллина, башкорт телчеләре Фирдәвес Хисаметдинова һәм Зиннур Ураксин белән күрешә. Шушы мөхтәрәм галимнәрнең тәэсирендә татар һәм башкорт дөньясы турында киңрәк белә, ике телне дә үзлегеннән өйрәнә башлый.

Алман галиме белән Миркасыйм әфәнде үзара хатларны, иске татар теле госманлы теленә бик якын булу сәбәпле, кириллда түгел, ә гарәп графикасында язышкан. 1991 елда беренче тапкыр төрекчә укытырга Казанга килгән Маргарет ханым Флера Сафиуллина оештырган курсларда укый, телне бик тиз арада үзләштереп, Берлин ирекле университетының 1991 елда ачылган Тюркология институтында татар телен укыта башлый.

*Себастьян Цвиклински – Берлин ирекле университетының Тюркология институты мөгаллиме, тарих фәннәре докторы, Германия.

1990 нчы еллар башы... Төрек телен өйрәнер өчен мин дә әлеге институтка тәүге тапкыр аяк бастым. Ни гаҗәп, анда төрекчә белергә теләүче алманнар күп, барлыгы 36 студент идек. Укытучыбыз – Маргарет Эрсен-Раш, тюрколог, төрек теленең дидактикасы буенча Германиядә иң мәртәбәле белгечләрнең берсе. 1980 елларда төрек теле китабын язган мөхтәрәм галимә дәресләрен коммуникатив рәвештә алып барды. Нәтиҗә озак көттермәде: без – алманнар бер-ике семестр эчендә төрекчә иркен сөйләшә башладык.

Маргарет ханымның татар һәм башкортлар белән тыгыз элемтәдә яшәгәнлеге безгә мәгълүм түгел иде. Берникадәр вакыттан соң, укытучыбыз безне татар һәм башкорт телләре буенча интенсив курста укырга чакырды. Бу телләрдә сөйләшүче халыкның кем икәнен дә белми идем, әмма дәресләрне Татарстан һәм Башкортстаннан килгән мөгаллимнәр алып баруын да белгәч, кызыксынуым тагын да артты. Шулай итеп, миңа да атаклы галимә Флера Садрый кызы Сафиуллина алып барган курсларда укырга насыйп булды. Бу дәресләр күңелемә шулкадәр хуш килде ки, соңрак, Рәсәйдәге төрки халыкларны тирәнрәк аңлар өчен, тюркология юнәлешендә укырга, белемемне тирәнәйтергә карар иттем.

1994 елда мин беренче тапкыр Казанга килгәндә Маргарет ханым да шунда иде. Алман кешесенең татарлар белән иркен сөйләшә алуын белгәч, бу телгә булган мәхәббәтем тагын да артты. Берлинга кайткач, Маргарет ханым оештырган татар һәм башкорт телләре дәресләрендә укуымны дәвам иттем. Ул татар һәм башкорт галимнәре белән дуслашып, хатлар язышты, алар белән элемтә дә урнаштырды. Шул елларда Берлинга Татарстаннан күренекле әдәбиятчы Тәлгат Галиуллин, атаклы тарихчылар Альта Мәхмүтова, Миркасыйм Госманов һәм Искәндәр Гыйләҗев, тел галимнәре Әлфия Юсупова һәм Флера Сафиуллиналар да килде.

Маргарет ханым, алманнар өчен яңа дәреслекләр кирәклеген аңлап, татар мөгаллимнәре белән бу эшкә алынды. Илдар Харисов һәм Илмира Мифтахова кебек Берлин ирекле университетында укыган татарлар аңа бу эштә төп ярдәмче булды.

Мин 1999-2001 елларда Тюркология институтында татар телен укыттым, аннары Илдар әфәнде белән Эльмира ханым бу эшне дәвам итте. Без һәммәбез дә Маргарет ханым язган дидактик материалларны кулландык. Ниһаять, 2009 елда Маргарет ханымның без еллар буе кулланган татар теле дәресе материаллары китап булып басылып чыкты. Шул ук елларда Маргарет ханым төрек һәм башкорт телләре өчен дә заманча дәреслекләр язган иде, алары да укучыларга таралды. Шуны да әйтергә кирәк: галимәнең дәреслекләре Германиядә генә түгел, гомумән, Көнбатыш Европада бу телләр өчен беренче уку әсбаплары булды. Хәзер дә аның татар теле китабы Германиянең Берлин һәм Гиссен университетларындагы тюркология институтларында, Чехия университетларының берсендә кулланыла.

Маргарет ханым 2000 елларда яңадән Франкфурт университетына кайтты, лаеклы ялга чыкканчы татар һәм төрек телләрен укытты. Яңа дәреслекләр язарга да омтылып карады, кызганыч ки, авыруы сәбәпле, бу эшне туктатырга мәҗбүр булды.

Маргарет Эрсен-Рашның Германия тюркологиясе үсешенә керткән өлеше гаять зур. Нәкъ менә аның йогынтысында алманнар төрекчәне камил үзләштерде, теләгәннәре татар һәм башкорт телләрен дә өйрәнде. Үзем дә магистрлык һем докторлык диссертацияләремне татарлар турында яздым. Хәзерге вакытта да әлеге тырыш, эшчән милләтнең тарихын, мәдәниятен, телен өйрәнүемне дәвам итәм, Казан каласында еш булам, татар, башкорт дусларым белән аларның туган телендә сөйләшәм һәм язам. Боларның барысы өчен дә мин остазыма – күренекле алман тюркологы Маргарет ханым Эрсен-Рашка рәхмәтле. ■

Безнең мирас №5 май 2018

Бәйрәм көн. Вахит Галиев баянчы егет янәшәсендә

БЕЗНЕҢ ЗАМАН КАҺАРМАНЫ

Рабит Батулла

ТӘВӘККӘЛ ВАХИТ

Райбашкарма рәисе Габделхак абый, Вахитның хәлен аңлап, өй салырга утыз биш фесметр агач язып бирә. Армия сафларыннан кайткан запастагы офицерга өй салырга агач кирәк, дип, тиешле урыннарда аңлаткан. Биш мең сум ссуда да бирегез, дигән. Ссуда алырга килгәч, Вахитка әйтәләр:

– Ссуданы өеңне салгач кына бирәбез! – диләр.

«Тәвәккәл таш ярыр», дигән әйтем Вахит Галиевкә карата гына чыгарылган кебек. Вахит тота да булмаган өенә «документлар» алып килә. Нәчәлник йомышчысына әмер бирә:

– Бар! Галиевнең яңа җиткезгән өенә акт язып кайтыгыз! – ди.

Нишләргә? Ә йорт юк!

Вахитның күршесендә өр-яңа йорт балкып тора, агентны Вахит шушы йортка алып керә. Агент – урыс кешесе, татарча аңламый, хуҗабикәгә – Сабирҗан хатыны Зәйтүнәгә Вахит болай дип әйтә:

– Бар, Зәйтүнә, син Наилә янына чык, каян булса да, ничек булса да бер ярты табып алып кайт, калганын үзем аңлатырмын!

Дәвамы. Башы журналның 3 нче (2018) санында.

Ярты да кайта, акт та төзелә, шәп булды, агачны да кистерделәр. Агачны урманнан чыгарырга колхоз рәисе Зәйнул ат бирми. Һаман этләшә, аяк чала Зәйнулла Шәйхуллыч. Ат бирмәгәч, Вахит, башка бер бригадирдан ат белән озын арба алып, өйлек агачны берүзе ташып бетерә.

Шулай итеп, тәвәккәл Вахит үз йортын салып керә, эшләре рәтләнә бара. Ләкин, теге «гаебе» аркасында, аңа такта эшен ташларга туры килә.

КИБЕТЧЕ

Көннәрдән беркөнне Вахит, урам буйлап, өй борынча халыктан сөт җыя башлый. Сөт җыеп арганнан соң, кибетче булып китә бу. Кибетче булып эшләгәндә дә янәшә-тирәдәге авыллар Вахит кибетенә килә. Вахит Кукмарадан ат белән товар ташый. Бервакыт ат чанасына алты центнер товар төйи бу, ат тарта алмый, атны ял иттерер өчен, ярты юлда танышларына кереп куна Вахит.

Вахит ага сөйли:

– Ул вакытта кибетләрдә шикәр юк, урман промбазасында шикәр бар, тегеләр белән сөйләштем дә, алып кайтып бара торган шикәрләрен минем кибеткә бушаттылар. Шикәрне сатып, акчасын аларга бирдем. Тирә-якка дан таралды, Комазан кибетендә бөтен әйбер бар, диләр. Күрше авыл кешеләре Райсоюз рәисе Салих Вафинга зарлана икән: башка авыл кибетләрендә берни дә юк, ә Комазанда бөтен нәрсә дә бар. Нигә ул алай?

Вафин аларга әйтә:

– Сез Вахит Галиев кебек эшләгез, сездә дә булыр! – ди. – Ишектән кусаң, тәрзәдән керә ул, ләкин халыкка кирәк товарларын алмый калмый!

КЛУБ МӨДИРЕ

Вахит Галиев тире җыючы булып эшләгән чагында мәдәният хезмәкәрләрен кыскарта башлыйлар. Клуб мөдирләрен куып чыгаралар. Клубта эшләргә кеше калмый. Вахитның моңа бик эче поша. Бермәлне клуб эшен дә үз өстенә ала ул. Тире җыючылыкның җаен алгач, нахак штрафларыннан котылып, кесәсендә акча пәйда була. Клубка бильярд, штанга кайтарталар. Нәтиҗәдә, яшьләр клубка тартыла башлый.

Киләчәктә атаклы рәссам булачак Илдар Хановның ул вакытта рәссамлыкка укый торган чагы гына була. Илдар – Иске Комазан кешесе Мәснәви абзыйның улы. Вахит Галиев шушы яшь егетне клуб бизәргә ризалата. Утыз-кырык метр бәз алып кайта. Шофёрының хатыны – тегүче. Вахит бу бәзне шофёрының хатынына тектерә, пәрдәләр, ян пәрдәләр барлыкка килә. Яшь рәссам Иллар Ханов бик рәхәтләнеп бу эшкә алына, бер тиен акча сорамыйча, клубны танымаслык итеп бизәп куя: клуб спорт, уеннар, репетицияләр белән гөрләп тора башлый...

Бермәлне Иске Комазан авылында матай күбәя. Чатыр-чотыр чаба малайлар: кызлар янына да матайда җилдерәләр, болай да узышалар, ә йөртергә рөхсәтнамәләре юк. Матайга атланып олы юлга чыксалар, милиция куа, тотса, штраф сала яки матайларын алып кала. Шуңа күрә егетләр Мамадышка барып укый алмыйлар. Вахит, ДОСААФ белән сөйләшеп, Комазан клубы каршында машина йөртергә өйрәтү мәктәбе ачып җибәрә: кем шофёрлыкка, кем «матайлык»ка укый. Эш гөрли Комазанда. Вахит үзенең «Иж-49» матаен да клубка уку әсбабы итеп куя.

Вахит драмколлективны мәктәпкә тапшыра, хорны исә клубта калдыра, авылда 100 кеше хорга йөри башлый. Репертуар әзерләп, Иске Комазан хоры Мамадышка концерт куярга китә. Хорның җитәкчкесе – Вахит Галиев.

– Бу кадәр кешесе булган хор белән адәм мәсхәрәсенә калмасагыз ярар иде! – дип шаярталар күргән-белгәннәр.

Юк! Иске Комазанның 100 кешелек хоры хурлыкка калмый, шөкер! Аның шулай булачагын Вахит Галиев чамалый иде инде. Бу хор белән алар тирә-якны әйләнеп-йөреп чыга, хор алган бүләкләр, мактау кәгазьләренең чуты-кырые булмый. Бу – үзенә күрә бер могҗиза. Вахит клуб белән идарә итүне яшьләрнең үзләренә тапшыра. Яшьләр клубны ача, үзләре тәртип саклый, үзләре җыештырып, клубны ябып, кайтып китә. Тәртип! Иске Комазандагы бу могҗизаларны – машина йөртергә өйрәтү мәктәбе, штанга күтәрү ярышлары, шахмат, хор, драма коллективларының гөрләве турында ишетеп, бер газетадан хәбәрче килә. Вахит ул чакта авылда булмый.

– Клуб мөдиресезне күрәсе иде, – ди хәбәрче.

– Безнең клубның мөдире юк! – диләр.

– Ничек юк! – дип гаҗәпләнә хәбәрче.

– Шулай, яшьләр хуҗа клубка, – ди авыл кешеләре.

Аптыраган-йөдәгән журналист, Мәдәният министрлыгына кереп, бу турыда сөйли. Шуннан соң, Вахит Галиевне Республика күләмендәге мәдәният хезмәткәрләре җыенына чакыралар. Клубка кирәк-ярак алырга, дип кесәсенә акча тутырып, Вахит әлеге конференциягә китә. Бу җыен Галимнәр йортында була. Клуб өчен кирәк-ярак алып, килеп керә Вахит Галиев, өстендә – телогрейка. Конференциягә килгән галстуклы хезмәткәрләр, телогрейка кигән бу мужикка игътибар да итмичә, Иске Комазан клубының эше турында ду килеп сөйләшә бирә. Вахит аганың үз сүзләре белән әйткәндәй:

– Иске Комазан клубы, коммунизмга менеп, аягын селкеп утыра малай!

Икенче көнне Вахит Галиевкә сүз бирә җыелыш рәисе:

– Слово даётся герою нашей конференции! Иске Комазан авылы клубы мөдире Вахит Вәлиевич Галиевкә сүз бирелә!

– Мин – клуб мөдире түгел, мин – тире җыючы гына, бу эшкә җәмәгать тәртибендә генә алындым, – ди Вахит, сәхнәгә менгәч.

Аның бу сүзен кайнар алкышлар белән каршы алалар.

Конференциядән соң, Вахит Галиевне өлкә комитетының киңәйтелгән пленумына чакыралар. Мәдәният өлкәсендә аеруча әһәмиятле хезмәтләре өчен, Вахит Вәли улы Галиевне өлкә комитетының Мактау кәгазе белән бүләклиләр. Аны Фикрәт Табиев үзе тапшыра. Ниһаять, Мамадыш башлыклары да хәзер Вахит Галиевне таный башлый.

НЕФТЬ НӘЧӘЛНИГЕ

Ләкин Вахит Галиевне үзгәрешләр көтә: аны Нефтебаза директоры итеп куялар. Нефтебазада да төрле хәлләр була инде.

Вахит ага болай сөйли:

– Әхмәтов дигән бер райком җитәкчесе бар иде. Бу мине чакыртып алды да, аты-юлы белән кычкыра башлады... Башкортстаннан мин ягулык алам, аларның ягулыгы сыйфатлы була. Алган ягулыкны колхозлар да файдалана. Әхмәтов ягулык белән тәэмин иткәнем өчен рәхмәт әйтергә чакырган, дисәм: «Нигә минем белән киңәш итмәдең?» – дип акыра бу.

Чыктым да киттем, коридорда, шушы шигырьне яздым да, яңадан Әхмәтов янына кердем:

Өстәл төймә, хуҗам, куркытам, дип,
Үткән минем куркыр сәгатьләр;

Чикләнмәгән власть сизү генә
Биреп тора инде сезгә сәләтләр.

Минем әти кырык алты яшьтә
Дөнья куйган ярдәм күрмичә,
Ә мин сезне озак газаплармын
Йөз яшьтә дә әле үлмичә!

Кычкырып укыдым да шигырьне, өстәленә ташлап, тагын чыгып киттем.

Вахит Галиев (уртада), энесе Миңгол (иң артта) һәм башка туганнары белән

Ну, ул Әхмәтовны дөбершатыр китереп кудык без. Президиум җыеп, тавышка куеп кудык. Клубтагы хезмәтем өчен, миңа атказанган исеме бирергә кәгазьлар әзерләгәннәр иде, аларны Әхмәтов куштаннары архивка ук озаткан... Комазан зиратын тимердән үрелгән челтәр белән әйләндердем, мәчет салдырдым, ул мәчетне хәзер «Вахит мәчете» дип йөртәләр. Мәчеткә мулла таптым, аңа йорт җиткездем. Халык театры гөрләп эшли, мин баш рольләрдә уйныйм. Түрәләр алышынгач, миңа «Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре» исемен бирделәр.

Райком секретаре Каюмов сүзен тыңлап, Якегә киттем. Уңышны шәп кенә җыеп алдык, минем абруй тагын да арта төште. Каюмов:

– Зинһар, Яке хуҗалыгын үз өстеңә ал, Вахит Вәлиевич! – ди.

– Юк, Мөнир туган, минем гаиләм бик ишле, урыннан-урынга күченеп йөри алмыйм, мине якын урынга куйсагыз, барам, бу урынга кыстасагыз, бармыйм! – дип җавап бирдем. – Әнә, үсәргә теләүче яшьләр бик күп бит. Мәктәп директоры, парторг та ул – Вильдановның үсәсе килә, ничек үсәргә белми эзләнеп йөри. Шуны куегыз. Вильдановны Якегә рәис итеп китереп куйдылар. Ләкин Вильдановның торыр урыны юк. Минем исә бер әбидә фатирда торган чагым. Әби, Вильданов бик һәйбәт кеше, ул вакытлыча гына шушында торып торсын әле, дидем. Килеп төште бу. Аңа иң яхшы бүлмәне бирдек. Икенче көнне үк нәчәлник булып утыра бу. Иртүк тора да, шофёрын чакыртып ала, ашый-эчә дә каядыр чыгып чаба. Түлке эш белән түгел. Көн саен шулай. Кайда йөри бу кеше? «Мин барында әзрәк власка кереп кал, өйрән. Нигә файдасызга чапкынлыйсың?» – дим тегеңә.

– Мин өйдә утырсам, фәләнемне эшләрсезмени? – дип әйтеп куймасынмы бу!

Нәчәлник булырга бик хыялланган икән. Юк, бу Вильдановтан да рәт чыкмады. Якедәге урып-җыюны төгәлләдем дә Комазаныма кайтып киттем. Озакламый Вильдановны тәгәрәттеләр. Ә мине Уразбахтыга кодаладылар.

Дәвамы бар ■

КАЗАКЪ ХАЛКЫНЫҢ МӘШҺҮР УЛЫ

Сәхифәне Ләбиб Лерон алып бара.

Казакъ шагыйре, мәгърифәтче, җәмәгать эшлеклесе, композитор, казакъ язма әдәбиятына нигез салучы Абай (чын исеме – Ибраһим) Кунанбаев 1845 елның 29 июлендә (10 август) бай Кунанбай Үскәнбаев гаиләсендә туа. Абай – әдипнең әбисе Тукбала (кияүгә чыккач – Зөрә) кушкан икенче исеме-кушаматы: абайла, сак бул, дигән мәгънәне белдерә.

Башлангыч белемне ул Семипалатинскида Әхмәтриза мулла мәдрәсәсендә ала. Шул ук вакытта рус мәктәбенә дә йөреп укый.

Абайның дөньяга карашы формалашуда Фирдәүси, Галишер Нәвои, Низами, Физули һәм Әбүгалисина кебек дөнья мәшһүрләренең йогынтысы зур була.

Абай, шигырьләр язу белән беррәттән, И.Крылов, М.Лермонтов, А.Пушкин, И.Гёте һәм Д.Байрон кебек бөек шагыйрьләрнең әсәрләрен дә тәрҗемә итә.

Күренекле казакъ шагыйре, тарихчы һәм композитор Шәкәрим Кодайбирдиев (Ходайбирдиев, 1858-1931) – Абайның әтисе ягыннан туганы.

Абай үз гомерендә 170ләп шигырь яза. Аның башка телдән 76 әсәр тәрҗемә итүе мәгълүм. Шагыйрь көйләр дә чыгарган. Шуңа бер мисал – «Күземнең карасы». Аңлашылганча, әдип әлге атаклы шигыренә көйне дә үзе язган.

Этнограф, журналист һәм җәмәгать эшлеклесе Галихан Бөкейханов (1866-1937) – Абайның беренче биографы. Ул мәшһүр әдипнең вафаты уңаеннан 1905 елда «Семипалат кәгазе» газетасында «Абай (Ибраһим) Кунанбаев» дигән әтрафлы мәкаләсен бастыра.

Абайның дүрт улы булганлыгы мәгълүм.

Олы улы Акылбай Абайга унҗиде яшь булганда дөньяга килә. Аны Абайның кече хатыны Нурган тәрбия кыла.

Икенче улы Габдрахман (Абай аны «Габиш» дип йөрткән) 1868 елда туа.1895 елда туберкулездан үлә.

Өченче улы Мәгәүия (Мәгәш, 1870-1904), Семипалатта укыгач, авылга кайта. Атасының катгый үтенечен истә тотып, поэмалар яза. Гомеренең соңгы елларында казый була.

Дүртенче улы Түрәгол (1875-1934) шагыйрь һәм язучы була. Аның Д.Лондон, М.Горький, Б.Прус әсәрләрен тәрҗемә иткәнлеге билгеле.

Абай Кунанбаев 1904 елның 23 июнендә (6 июль) 58 яшендә Җидебайда вафат була.



Абай Кунанбаевның 1909 елда дөнья күргән китабы

Абай Кунанбаев шигырьләре

ҖИЛСЕЗ ТӨНДӘ ЯКТЫ АЙ

Җилсез төндә якты ай.
Һава тәмам сүрелде.
Айның алтын шәүләсе
Су өстендә дерелди.

Әйтерсең лә агачлар
Рәхәтлеккә тиенгән.
Бар табигать төнката
Ямь-яшелдән киенгән.

Эт тавышы таулардан
Кайтаваз булып кайта.
Ике гашыйк шул төндә
Күрештек без аулакта.

Ояласың, янасың,
Яшерәсең карашың.
Әле балкып аласың,
Әле шүрләп каласың.

Көтмәгәндә син шулчак
Битемнән үбеп алдың.
Йөрәгең дөп-дөп типте...
Мин сүзсез-телсез калдым.

КҮЗЕМНЕҢ КАРАСЫ

Күземнең карасы,
Йөрәгем парәсе.
Төзәлми һич кенә
Мәхәббәт ярасы.

Казакъның даласы,
Син – шуның баласы.
Яндыра, көйдерә
Серле күз карашың.

Гел сине уйлыймын,
Моңланып җырлыймын.
Агызып күз яшен,
Сагыштан җылыймын.

Өзәсең үзәгем,
Гел яшьле күзләрем...
Бу хәтле сагышка
Йөрәгем түзәрме?

***Л.Лерон** тәрҗемәсе* ■

ИСЛАМ ДӨНЬЯСЫ

Габдерәшит Ибраһимов

Иркутск. XIX гасыр

ИРКУТСК

Бу шәһәр элегрәк Себернең зур сәүдә үзәге булган. Себер тимер юлы төзелгәнгә кадәр, кышкы зәмһәрир суыкларында да Русиянең эчке төбәкләреннән, Көнбатыш Себердән, Кытайдан һәм Монголиядән бирегә күпләп сәүдәгәрләр килә һәм зур сәүдәләр алып бара торган булганнар.

Бүгенге көндә Иркутск тагын да төзегрәк шәһәр булса да, сәүдә ягыннан элеккеге әһәмияте калмаган. Чөнки элек биредә Мәскәү һәм Русия маллары китереп сатылган, Кытай товарлары да булган. Хәзер исә, тимер юл булганга, Мәскәү маллары Пекингә кадәр китә, Кытай маллары исә Петербургка хәтле килә. Шул сәбәпле Иркутск базары сәүдә үзәге булу ягыннан тынып калган һәм, гомумән, бөтен Себер базары һаман да артка чигенә бара.

ИКЕ КАҺАРМАН

Иркутск шәһәрендә мине кунак иткән дустым Шәйхулла әфәнде белән аның

*Дәвамы. Башы журналның 1 нче (2017) санында.

абыйсы Заһидулла әфәнде турында бераз мәгълүмат бирергә телим[1].

Үзләрен үзләре кеше иткән бу ике каһарманның укып белем ала алмаулары, гади ата балалары булганнарына күрә, гаеп ителмәс, дип уйлыйм. Тик боларның икесе дә – бик тырыш, җитди һәм саф күңелле кешеләр, чын-чынлап каһарманнар.

Туган җирләре – Казан губернасындагы, Цивиль өязенең Акъегет авылы *(хәзер Яшел Үзән районына керә. –* ***А.Р.****)*. Башта Заһидулла әфәнде, яшь чагында туган җирен калдырып, Ерак Көнчыгышка киткән. Моннан 40-50 еллар элек Яфа лимоннарын Иркутскида берсен 12 тиенгә кадәр саткан кеше бу! Аннары ул Иркутскида урнашып калган. Соңрак Шәйхулла әфәнде дә абыйсына ияргән. Эшкә беренче башлап Заһидулла әфәнде тотынган булса да, бүгенге көндә бөтен Себер сәүдәсен үз кулына алып, Себер якларында яшәп калган кеше – Шәйхулла әфәнде.

Бу ике тырыш затның берсе – Себердә, икенчесе исә үз туган җирендә милләт балаларына һәм ислам диненә хезмәт итүне үз өсләренә алганнар. Укымышсызлыклары сәбәпле үзләре күргән авырлыкларны яшь буын күрмәсен, дигәннәр. Алар кичергән кыенлыклар яшь буында да кабатлана калса, моны вөҗданнары кабул итмәячәген аңлаганнар. Һәр икесе дә үзләре яшәгән җирдә мәктәпләр ачу, мәчетләр төзү өчен байлыкларыннан бик зур өлеш чыгарганнар, йөзләрчә-меңнәрчә мөселман баласын – күпме үксез, күпме ятим бар – һәммәсен бер урынга җыеп, чыгымнарын үз кесәләреннән түләп, бу балаларны укытканнар, тәрбияләгәннәр һәм әле дә шушы эшне дәвам итәләр. Бүген кая гына барсаң да, Шәйхулла әфәнде мәктәп-мәдрәсәсе бар, Заһидулла әфәнде мәчете бар. Бүгенге көндә Иркутск шәһәрендә эшләп торган изге мәчетне төзү һәм ачу, мәсәлән, якынча 30 000 сумга төшкән. Иркутскидагы ир балалар мәктәбендә 40-50 тирәсе мөселман баласы укыса, кыз балалар мәктәбендә укучыларның саны 70кә җитә. Сабый яшьтәге кыз балалар да бар, күбесе ятим, үксез. Боларның бөтен чыгымнарын Шәйхулла әфәнде үз кесәсеннән түли, белем-тәрбия алулары өчен бик күп акча тота.

Бүгенге көндә Шәйхулла әфәнде Себердә шундый дан казанган ки, бөтен себер татарлары бу елларда туган ир балаларына, бәхетле исем булсын, дип, Шәйхулла исеме кушалар. Бу шәхеснең танылганлыгы бары тик татарлар белән генә дә чикләнми, руслар, яхүдләр, бурятлар, якутлар да бу кешегә изге кешегә караган кебек карыйлар. Иркутск шәһәрендә ничә банк филиалы булса, ул шуларның һәммәсенең дә әгъзасы, күпме хәер җәмгыяте булса – бөтенесендә әгъза, Ислам хәер җәмгыятенең исә рәисе булып тора.

Заһидулла әфәнде исә, үз туган җирендә нәкъ шулай ук данлыклы, ул да нәкъ шундый ук хезмәт күрсәтә. Бу ике каһарман яшь буынга шундый нәсыйхәт бирә: «Безнең кебек җаһил калмагыз!». Мин биредә алар турында бик аз гына яздым. Әгәр аларның тәрҗемәи хәлләрен язарга уйласаң, бер китап булыр иде.

РУХАНИ БЕЛӘН ӘҢГӘМӘ

Мин биредә шәһәрнең алдынгы кешеләре һәм әдипләреннән берничә кеше белән таныштым. Танылган православие рухание Иннокентий Подгорбунский[2] җәнаплары да шуларның берсе. Бу зат белән күп тапкыр күрешеп сөйләштем һәм Монголия турында аннан шактый мәгълүмат алдым.

Иннокентий җәнаплары, дин әһеле булу белән бергә, олы әдип тә. Инглизчә, французча, алманчадан тыш, монголча да

[1] Бу шәхесләр турында түбәндәге чыганаклардан өстәмә мәгълүмат алырга мөмкин: Тимершин И. Акъегет авылы тарихы сәхифәләре. – Казан, 2001. – 164 б.; Айзат Шәймәрдән. Татар миллионеры Шәфигуллин// Безнең гәҗит. 2011, №8 (2 март) (тәрҗ. иск.).

бик яхшы белә, бераз татарча да аңлый. Диннән күбрәк әдәбиятка хезмәт итүче бу шәхес рухка караганда матдәне күбрәк хөрмәт итә. Моннан өч-дүрт ел элек ул «Русча-монголча сүзлек» төзегән һәм бастырып чыгарган[2].

Бу затның фикеренә күрә, дөньяда милләтләрнең тынычлыгын качырачак бернәрсә булса, бу – христианлык камчысы, христиан дин галимнәренең үзләре хөрмәт итмәгән нәрсәне башкаларга тәкъдим итүләре.

Подгорбунский Монголия турында шуларны сөйләде: «Монголлар христианлыкны кабул итү белән юкка чыга барачаклар, чөнки бүгенге христианлык, дин исемен кулланып, монголлар арасында әхлак бозыклыгы орлыгын чәчә. Миссионерлар, халыкны мәгълүмат белән күндерә алмаганга, теләсә нинди начарлык китереп чыгуга сәбәп булалар. Монголларны да, маньчжурларны да, эчәргә өйрәтеп, бәлагә төшерделәр. Бүген бөтен Монголиядә әхлак бозыклыгы зур тизлек белән арта бара. Моның нәтиҗәсендә бурятлар, якутлар, Минусия татарларының нәселләре корый бара. Бу җирләрдә генә түгел, хәтта төньякка таба да, иштәкләр, самоедлар да, безнең руслар белән элемтәгә кергәннән соң, юкка чыга башлауга дучар ителгәннәр.

Нинди генә дин турында сүз барса да, кешеләрнең дингә булган ихтыяҗлары күркәм әхлак өчендер. Югыйсә, әхлак бозыклыгы белән дин бервакытта да берләшә алмаячак».

Подгорбунский җәнаплары – Монголия турында гаять күп мәгълүмат туплаган белгеч. Бу илне адым-адым гизгән, һәр җәһәттән бик җентекләп күздән кичергән, ул гына да түгел, әдәбиятыннан да мәгълүматлы. Шуңа

И.А. Подгорбунский

күрә әлеге шәхеснең белеме бик киң, үзе күпме генә дин кешесе булса да, үтә фанат булмаганга, ул сөйләгән сүзләрнең дөреслеккә туры килүендә шик юк.

Подгорбунский җәнапларының фикеренчә, лама мәзһәбендә әхлак тәрбиясе күпкә тәртипле, табигатькә күбрәк ярашлы, тик ламаларның үлеләрен җирләмичә, утта да яндырмыйча, турыдан-туры далага атулары һәм җәсәднең, ерткыч җанварлар күреп ала алмаган очракта, юл өстендә айларча өстерәлүе әхлакка бик начар йогынты ясый. Гомуми саулыкка зарар китерү ихтималы да бар.

Шулай булса да лама мәзһәбендә ялган, золым, коллар хокукын, хайваннар хокукын бозу һәм җан ияләрен юк итү катгый рәвештә хәрәм санала. Иннокентий Подгорбунский боларны мәзһәпнең яхшы яклары дип саный, тик ирләр җенес әгъзасын «бар итүче» сыйфатында кабул күрүне дин исеменнән әмер итүнең урынсыз булуын бик әрнеп белдерде.

[2] Подгорбунский Иннокентий Александрович (1862-1913) – дин әһеле, педагог, галим, туган якны өйрәнү белгече, фотограф. Казанда Духовная семинария бетергәннән соң, Иркутскидагы Духовная семинариягә укытучы итеп җибәрелә.

[3] Будда дине һәм шаманизм белгече И.А.Подгорбунскийның «Русско-монголо-бурятский словарь» исемле сүзлеге турында сүз бара. Гомеренең соңгы елларында күбесенчә монгол һәм бурят телләрен өйрәнү белән шөгыльләнгән галим бу сүзлекне төзеп, 1908 елда бастыра (тәрҗ. иск.).

[4] Шостакович Владимир Болеславович (1870-1942) – геофизик, Иркутск магнитлы метеорология обсерваториясенең директоры, Иркутск дәүләт университеты профессоры (тәрҗ. иск).

Иркутск обсерваториясе

РАСАТХАНӘ, ЯГЪНИ ОБСЕРВАТОРИЯ

Мин аннан соң Иркутск расатханәсен барып карадым. Биредә искә алып үтәрлек берни булмаса да, расатханәнең нәкъ менә Иркутск шәһәрендә булуы үзе билгеләп үтүгә лаеклы. Бигрәк тә без – мөселманнар өчен бу югары белем үз малыбыз дәрәҗәсендә була торып, бүген Иркутскида бар, ә менә Палестинада юк. Кызганыч, димичә, ни дисең?! Мондый югары белемнәрне күргән саен, мирасын югалткан үксез кебек елаудан башка бер чарабыз да юк.

Расатханә мөдире Шостакович[4] белән күрешеп сөйләштем, бераз фикер алыштык. Хөкүмәтнең басым ясавы аркасында расатханәләрнең зыян күрүе турында әйтте.

БУРЯТ НӘСЕЛЛӘРЕНЕҢ КОРЫЙ БАШЛАВЫ, ХАЛЫКНЫҢ ЮККА ЧЫГА БАРУЫ ҺӘМ МОНЫҢ СӘБӘПЛӘРЕ

Бурят халкының алдынгыларыннан доктор Турабачев белән күрешеп сөйләштем. Бу кеше милләте буенча бурят булса да, балачагында чукындырылган, аннары Петербург университетын тәмамлаган доктор. Бурят халкының язмышы турында бик нык уйлана торган бу кеше, сөйләшү арасында болай диде:

– Болай барса, безнең бурятлар тәмам юкка чыгачак, көн үткән саен нәселнәсәбебез югала, моны туктату өчен бер чара табарга телим, булмый.

– Доктор булуыгызның файдасын кайчан күрә башларсыз икән соң?

– Минем доктор булуымның бу авыруга бернинди файдасы да тимәячәк. Ә менә рухларны дәвалау ысулына мөрәҗәгать итәргә мәҗбүр булырбыз, ахры.

– Безнең татарларда борынгылар моны күп тапкырлар сынаганнар: бер ыруда нәсел өзелә башладымы, башка ыру белән кан катыштырганнар, өйләнешкәннәр. Сез дә моны сынап карагыз.

– Әйе, бу фикер минем күңелгә ятышлы. Бу чынлап та яхшы ысул булыр, дип уйлыйм. Башка чара уйлап торасы да юк. Әмма кем белән өйләнешергә соң? Менә бу читен мәсьәлә.

– Руслар белән өйләнешүне сынап карагыз.

– Нәселемнең бөтенләй юкка чыгачагын аермачык белгән очракта да руслар белән өйләнешүне кабул итә алмаячакмын.

– Инде христианлыкны кабул иткәнсез, өйләнешүне кабул итү җиңелрәк түгелмени?

– Мин христианлыкны кабул итмәгәнмен, мине кабул иттергәннәр. Мондый хәлдән соң, әлбәттә, җиңел түгел.

– Японнар белән мөнәсәбәт корырга тырышып карагыз. Тарихи динегез буенча да якынлыгыгыз бар. Бурятлар да бу фикерне хупларлар, дип уйлыйм.

– Ах, бу насыйп булса, моңа, шөбһәсез, бөтен бурят халкы кушылачак. Тик бу, хәтта хөкүмәт каршы чыкмаса да, авыр мәсьәлә.

– Алайса, японнар да кабул итсә, дип әйтергә кирәк.

ИРКУТСК АВЫЛЛАРЫ

Мин Иркутск шәһәрендә яшәгәндә, гадәтем буенча, якын-тирә авылларны да йөреп чыктым. Мәктәпләренә бардым, кая гына барсам да, һәр җирдә уяныш галәмәте күрдем. Иркутск әйләнәсендәге авылларның һәммәсе дә диярлек сөрген срогы тулганнан соң чарасызлыктан биредә төпләнеп калучылардан гыйбарәт икән. Димәк, болар – гаеплеләр һәм сөрелгән кешеләрдән оешкан авыллар булып чыга. Шул ук вакытта, дин юлындагы тырышлыкларының күрсәткече буларак, боларның да дини мәктәпләре, мәчетләре бар.

Сөрген срокларын тутырган гаеплеләр генә түгел, хәтта «каторга» дип аталган җәзага тартылган кешеләр дә үзләренә аерым мәктәп һәм мәчет ачканнар.

АЛЕКСАНДР КАТОРГАСЫ

Бу гаять зур, эчендә 25000гә якын каторжанны сыйдырган төрмәсе дә булган каторга дигән җирне шәһәр дип тә атарга мөмкин булыр иде. Биредә яшәүчеләрнең – төрмә сакчылары һәм анда эшләүче башка хезмәткәрләрдән тыш – һәммәсе җинаятьче һәм кеше хокукларыннан мәхрүм ителгән бәхетсезләр, ләкин барыбер дә безнең кебек үк кешеләр. Бу җинаятьчеләр, кеше үтерүчеләр, инсани хокуклардан мәхрүм ителгәннәр, дип хөкем йөртелгән кешеләр арасында безнең дин кардәшләребез, мөселманнар да бар. Шундый хәлдә дә, болар дини тырышлыклары белән үз араларыннан берәүне имам итеп сайлап куеп, гаиләсе, бала-чагасы белән бергә килгәннәрнең балаларына ислам динен өйрәтәләр. Имам әфәнде дә бу гаеплеләрнең берсе, шулай булса да, дин таләп иткәнчә, имамлык урынын яклап, саклап тора. Менә шул Александр каторгасы имамы Мифтахетдин мулла гаять яхшы кеше булып чыкты. Мәгълүматы, белеме бик тирән булмаса да, дине бөтен, нык, какшамас, бик эшчән һәм тырыш шәхес. Җинаятьчеләрне бергә җыеп, динебезгә хезмәт итә, җаваплы вазыйфа башкара.

Александр каторгасына һәр ел саен биш меңнән алып сигез меңгә кадәр яңа җинаятьче килә, өч-дүрт мең җинаятьче срогын тутырып аннан чыга һәм әйләнәтирәгә авыллар итеп урнаштырыла. Килгән җинаятьчеләрнең саны елдан-ел арта бара икән. Төрмәдә әхлак бозыклыгы бик күп, бер-берсен үтерү, эчеп үлү бигрәк тә күп, ди. Мин Усолье дигән авылда хезмәттә булганнардан 700-800 кешене эш вакытында күрдем, 35 градус суыкта эшлиләр иде. Күкрәкләре ачык, башларыннан күтәрелә торган пар өсләрендә томанга әйләнгән. Бу җир күмер шахтасы булганга, йөзләре дә су күрмәгәнгә, котчыккыч, боларны кеше кыяфәтендәге ерткыч җанвар дип уйларлык иде.

Бу каторжаннар арасында гаять диндар, тәкъва кешеләр дә очрый. Боларның җинаятьләре дә, дөресен генә әйткәндә, диннәре хакына күрсәткән ныклыклары белән бәйле. Шулай ук, гаять мәгълүматлы сәяси каторжан руслар да бар. Ләкин бу җирләрнең тәэсирендә боларның аңлылыклары – уйсызлыкка, бәхетләре бәхетсезлеккә әйләнеп, инсан булуларыннан бары тик исемнәре генә калган. Сәяси тоткыннар арасында 16-18 ел каторгада калган кешеләр булуын сөйлиләр.

Каторга җире – авыр хезмәт белән җәзалау урыны, руслар аңа «каторжная работа» диләр, ул хезмәттәге кешеләргә «каторжанин» диләр. Үзәгендә Александр исемендәге төрмә тора. Биредә кулы эш белгән эшчеләр өчен бик зур остаханәләр бар. Җинаятьченең нинди хезмәт тәҗрибәсе булса, шул эштә эшләттерелә: өс киеме тегүчеләр, аяк киеме тегүчеләр,

балта осталары, тимерчеләр, бизәнү әйберләре ясаучы осталар һ.б. гел шул үз эшләрендә эшлиләр. Әгәр инде андый эшләргә осталыклары булмаса, авыр хезмәт башкаралар.

Бу төрмәләрдә җитештерелгән маллар бик зур табыш китерә. Шул рәвешле, хезмәтенә күрә һәммә кешегә хезмәт хакы билгеләнгән һәм ул төрмә казнасында җыелып бара. Аның өчтән бере – хөкүмәткә дигән акча, тагын бер өчтән бере төрмә чыгымнарына тотыла, калган өчтән бер өлеш җинаятьче исеменә җыелып бара, каторга срогы тулып, төрмәдән чыкканда үзенә бирелә. Болар арасында кайбер осталар шактый ишле акча белән чыгалар. 3000-5000 сум акча белән чыгучылар да булгалый, ди. Соңыннан үз теләге белән эш башлап җибәреп, байлык туплаган кешеләр дә бар икән. Тик бу кешеләр туган җирләренә кайтып китә алмыйлар, бу – тыелган.

Бу кешеләр үзләре турында «университет студенты без», диләр. Болар арасында гаять сәләтле кешеләр дә аз түгел. Бер каторжан белән күрештем, арабызда шундый сөйләшү булды:

– Бу каторгада кешеләрне авыр хезмәтләрдә эшләтәләр, шулаймы?

– Минем фикеремчә, биредә каторга юк. Каторга, беләсезме, кемнәр өчен? Сәясиләр өчен. Чөнки алар үз туган якларында мөхтәрәм затлар булганнар, фикерләре белән хезмәт иткәннәр. Тик безнең кебек туган якларында да ачялангач яшәгән кешеләргә монда әле яхшырак та. Һич югы, монда безгә эш бар. Безнең өчен каторга дип монда бары тик бернәрсәне генә әйтергә мөмкин: ул да булса, туган җиребез һәм гаиләбездән аерым булу. Гаиләсен дә янында китергәннәр өчен каторга бөтенләй юк.

– Сез бу хәлегездән канәгать, димәк.

– Минем уемны тырмалый торган бернәрсә бар: без гөнаһыбыз өчен җәзага тартылдык. Җәза, диделәр, туган җиребездән сөргенгә сөрделәр. Моны кабул итәргә була, моңа минем дә башым житә. Тик көн күрүе минем җилкәмдә булган гаиләм бар иде, инде минем аркамда алар ач калды, аларның гөнаһлары ни? Аларга карата бу золым һәм хаксызлык түгелме? Алар тик торганда ятим калдылар. Менә бу гаделлеккә туры килми, дип уйлыйм.

Каторжанның бу сүзләрен ошаттым:

– Бу турыда нинди фикерләрегез бар? Ничек булса, гаделлеккә туры килгән булыр иде? – дип сорадым.

– Минемчә, туган җиреннән сөрелү – җинаятьче өчен җәза түгел, ул аерылу аркасында башта бераз сагынып күңелсезләнсә, кайгырса да, бирегә килеп урнашкач, онытa башлый. Ә менә гаиләсе өчен бу бик зур җәза. Хөкүмәтләрнең максаты да шул: кеше аз яши торган җирләрне тутыру. Сөрген җәзасы булган дәүләтләрдә гомумән җинаять күп була, бу исә мәгълүм һәм үзгәрмәслек нык урнашкан нәрсә. Минем фикеремчә, җинаятьчегә авыр җәза бирергә кирәк, ләкин бу гаиләсенә яшәр өчен акча җибәрттерү шарты белән булырга тиеш. Минем өч яшьлек, биш яшьлек балаларым калды, аларның караучысы юк, шулай булгач, тәрбия күрмәячәкләр, белем алмаячаклар. Мин хулиган идем, ләкин үз хәлемнән үзем канәгать идем, дип әйтә алмыйм. Шуңа күрә, әлбәттә, ичмаса балаларым минем көнгә калмасын, дип, ничек булса да аларны мәктәпкә биреп укытыр идем. Инде мин сөргенгә сөрелдем, тик минем урыныма тагын өч хулиган җитешәчәк. Гомумән, биредә җинаятьчеләрнең елдан-ел артуының сәбәбе дә мин әйткәннәр белән бәйле.

Менә бу сүзләр минем игътибарымны бик нык җәлеп итте. Тик әңгәмәне дәвам итәргә мөмкин булмады, шул арада сакчы килеп, безнең сөйләшүне тыйды.

Мин каторжан авылларын шул рәвешле карап йөргәннән соң, кире Иркутскига кайтып киттем.

Төрекчәдән Асия Рәхимова тәрҗемәсе. ■

Безнең мирас №5 май 2018

ХАҖГА ОЗАТУ ДОГАСЫ

Җәлил Фазлыев

«Әлхәмдүлилләһи раббилгәәләмииин. Үәсаләәту үәссәләәму гәләә расүүлинәәә Мухәммәдиү үә гәләә әәлиһи үә сахбиһи әҗмәгииин.

Әгүүзү билләәһи минәш-шәйтаанир-раҗиим. Бисмилләәһир-рахмәәнир-рахиим. Иннә әүүәлә бәйтин. Үүдыйгә линнәсил-ләлләзи бибәккәтә мүбәракәү үә һүдәл лил гәләмииин. Үә лилләәһи гәлән-нәси хиҗҗүл-бәйти мәнистәтагә иләйһи сәбилә».



Гарәпчә өлешеннән соң татарча шулай дога кылына:

– Аллаһым! Биргән саулыгыңа, биргән нигъмәтләреңә меңнәрчә мәртәбә шөкерләр булсын! Безне яралттың, кальбебезгә Ислам нурын урнаштырдың, мактау булсын Сиңа. Кәгъбәне мөбарәк кылдың. Күңеле Аллаһ сөйгесе белән янган Ибраһим пәйгамбәрне (г.с.) анда урнаштырдың. Безләргә өеңне зиярәт итүне фарыз кылдың, инде ул мөбарәк туфракларга кавышу, өеңне тәвәф кылу, зәмзәмеңне эчү теләге белән юлларга чыгабыз. Бу Аллаһка, Мөхәммәд (с.г.в.) Пәйгамбәребезгә карата булган ашкынуда, Кәгъбәне, өеңне күрмичә, җаныбызны алма, йөзебезне Хаҗәри-әсвәдкә кую өчен саулык бир. Кәгъбә тирәсендә фәрештәләр кебек әйләнергә көч һәм куәт бир. Сафа һәм Мәрвә таулары арасында, Ибраһим Хәлиуллаһны искә алып, Мөхәммәд (с.г.в.) Пәйгамбәрнең юлында җаныбызны фида кылыйк. Аллаһым, гөнаһларыбыз гафу ителсен, йортыбыз-

Безнең мирас №5 май 2018

Җәлил хәзрәт
Фазлыев

га яңа туган кебек пакь һәм гөнаһсыз кайтыйк. Эчебездәге шәйтанны үтерик. Бөтен җаныбыз-тәнебез белән: «Ләббәйкәллааһүммә ләббәйк», – дип кычкырыйк.

Мин Синең әмереңдә, Аллаһым, әмер ит.

Йа, Рабби! Синең сөюең белән юлларга чыктык. Исән-сау кайтып җитүне, гаиләбез һәм дусларыбыз белән кавышуны, аларны да сау-сәламәт күрүне насыйп ит! Һәр мөэмин колыңа Кәгъбәне тәвәф кылуны насыйп әйлә, Аллаһым!

Аллаһым! Синнән бу дөньяда һәм ахирәттә яхшылык сорыйбыз, гөнаһларыбызны кичер. Сөекле Пәйгамбәребезнең (с.г.в.) шәфәгатенә ирештер.

ХАҖ ГАМӘЛЛӘРЕ

Хаҗилар, Мәккәи Мөкәррәмәгә барып җиткәнче, «Мәйкат» дип атала торган җирләрнең берсендә туктап, сакал-мыекларын кыскартырлар, тырнакларын кисәрләр, артык төкләрне китәрерләр, гадәттә кия торган киемнәрен салырлар. Госел кылып, ихрам киемнәрен киярләр.

Аннан соңра ике рәкәгать нәфел намазы укыгач:

– **«Әллааһүммә иннии үриидүл-хәҗҗә фәйәссирһү лии үә тәкаббәлһү минии»**, – дип, хаҗга ният кылырлар.

Мәгънәсе: Йа, Рабби, тәхкыйк, мин хаҗ кылуны ният кыламын: инде Син аны миңа җиңел кылгыл һәм аны миннән кабул кыл, димәктер.

Ният кылганнан соң, кычкырып ошбу талибияне укырлар:

– **«Ләббәйкәллааһүммә ләббәйк, ләббәйкә, ләә шәриикә ләкә ләббәйк, иннәлхәмдү үән-нигмәтә ләкә үәл-мүлк, ләә шәриикә ләк».**

Мәгънәсе: Йа, Рабби, Синең гыйбадәтеңә камил итагать илә кыламын, Синең һич шәрикең юктыр. Тәхкыйк: барча мактау вә барча нигъмәт Сиңа хастыр. Вә хуҗалык та Сиңа хастыр. Синең һич шәрикең юктыр.

Ният кылып, ошбу талибияне укыганнан соң, хаҗилар «мохрим», ягъни «ихрамлы» дип аталырлар.

Ихрам киемнәре изар исемле бер киң алъяпкыч илә рида исемле бер киң җәймәдән гыйбарәттер. Хаҗилар изарны кендек турысыннан билләренә бәйләп, гаурәтләрен капларлар. Риданы иңбашларына һәм аркаларына салырлар.

Зәмзәм суын кыйблага карап, аягүрә торып, өч йотым итеп эчү тиешледер.

Аны эчкәннән соң, ошбу дога кылыныр:

– **«Әллааһүммә иннии әс әлүкә ризкаү үәәсигәү үә гилҗиән нәәфигәү үә шифәә әм мин күлли дәәәин».**

Мәгънәсе: Йа, Рабби, тәхкыйк, мин Синнән сорыймын – киң ризыклы вә файдалы гыйлемлекне вә һәрбер авырудан шифаны. ■

Безнең мирас №5 май 2018

Аяз Гыйләҗев һәм мин

Фатих Кутлу

Татар әдәбияты классигы Аяз Гыйләҗев

Бу мәкалә минем күңелемдә күптәннән туган, башымда байтактан язылган иде... Каләмгә үрелергә генә вакыт җитенкерәми йөрде.

Ниһаять, узган елның 1 ноябрь көнендә остазым Аяз Гыйләҗевне төштә күрдем.

Көндез икән, имеш. Казандагы фатирыбыз. Залдагы көлсу төстәге диванда Нәкыя апа (Аяз аганың җәмәгате) белән Искәндәр абый (Аяз аганың улы) утыра. Аяз Гыйләҗев үзе аягөсте. Өстенә шулай ук көлсу костюм кигән. Ә мин шушы язмам өчен кирәкле материаллар актарам. 2000 елның гыйнварында матбугатта аның «Төркиянең

* Бу истәлекне Аяз Гыйләҗевнең «Сайланма әсәрләре»нең 6 томыннан (Татарстан китап нәшрияты, 2016 ел) табып укырга мөмкин. – *Редакция.*



Аяз Гыйләҗевнең Фатих Кутлуга язган ихлас теләкләре (автографлар). 2000 ел

түренә үк уздык»* исемле хатирәләре басылган иде. Шуларны укыганнан соң туган хисләремне, «Язучы Аяз Гыйләҗевкә ачык хат» дип атап, газетага җибәргән идем. Хәзер менә, төшемдә, дөнья бетереп шул материалны эзлим. Билгеле, кулга эләгеп тә «кирәге чыкмаган» саннарны тәртипсез рәвештә таратып ташлыйм. Аяз ага, моны күреп: «Газеталарны алай тарау калдырма, тәртипкә салып җыеп куй», – диде.

Төштә без татарча сөйләштек.

Уянып киткәч, ошбу язманы язар вакыт җиткәнен аңладым.

***

Күңелемдә Аяз Гыйләҗевкә карата җылылык хисләре уяткан иң беренче вакыйга бая телгә алынган интервью-хатирә булды. (Сүз уңаеннан, бу эшне башкаручы, идея авторы, журналист Язилә ханым Габделкадыйровага олы рәхмәтемне белдерәсем килә. Атна саен Гыйләҗевләр йортына килеп, әдипнең тавышын яздырып, шуны кәгазьгә төшереп бастырган кеше ул.) Әлеге язма уңаеннан матбугатка юллаган ачык хаттан (16 март, 2000 ел) бер өзек китерим:

«Газиз кардәшебез Аяз бәй! «Заман-Татарстан» газетасында Сезнең «Төркиянең түренә үк уздык» дигән исем белән басылган хатирәләрегезне бик яратып, сокланып, ябырылып укып бардым. Туган илеңнән еракта яшәгәндә аның турында шундый сүзләр ишетү җанга рәхәтлек бирә икән. Ә инде аларны Сезнең кебек олуг татар әдибе авызыннан ишетү күңелгә горурлык та өсти. Хөрмәтле татар халкының Төркиягә мөнәсәбәтен Сез бик ачык, матур итеп, көчле дәлилләр белән сурәтлисез.

Хөрмәтле Аяз бәй! «Заман-Татарстан» газетасы битләрендә Сезнең яңа язмала-

рыгызны да укырга насыйп булсын иде. Мин аларны түземсезлек белән көтәм...»

Болар – булачак остазыма карата йөрәгемнән ургылып чыккан иң беренче самими, җылы хисләрем...

Мин әлеге хатны язганчы ук, 2000 елның 12 февралендә, Казанга килеп киткән идем инде (ул вакытта Чаллыда яшәгән чагым). Чехов базары тирәсендә йөргәндә янәшә урнашкан бер китап кибетенә тап булдым һәм сөенеп эчкә уздым. Шунда «Йәгез, бер дога!» китабына күзем төште. Авторы кем икән, дип карасам... Аяз Гыйләҗев! Алайса, яхшы китап булырга тиеш, дип, ике дә уйламыйча сатып алдым.

Китапны ничек яратып, тәэсирләнеп укыганымны белсәгез иде! Күргән һәрбер кешегә: «Йәгез, бер дога!» романын укыганыгыз бармы, ул шундый әсәр, ул мондый әсәр», – дип, романнан өзекләр укып йөргәнем истә.

Әлеге романны укыганда минем шулкадәр михнәт, җәбер-золым күргән, тәмуг газапларын кичкән олы шәхес белән танышасым һәм аның таш ташып интеккән кулларын үбәсем килде. Бу уй бик зур хыялыма, тора-бара йөгәнләп булмаслык теләгемә әверелде. Шундый хисләр белән янып йөргән мәлдә ул минем төшемә керде хәтта. (Сүз уңаеннан, безнең шәһәрдә: «Башта төш, аннан эш», – дигән мәкаль дә бар.) Менә ул төш: Аяз ага төрек телевидениесендәге бер тапшыруның кунагы икән; ярсып-ярсып: «Безгә җитмеш ел буе Пәйгамбәребезнең сәхабәләре – хәзрәти Әбүбәкер, хәзрәти Гомәр ише кешеләр хакында сөйләмәделәр. Моны юри шулай эшләделәр. Мин бу хакта гомерем буе сөйләячәкмен!» – ди...

Мин олуг максат белән 2000 елның 25 апрелендә Казанга юл тоттым. Газета редакциясенә кереп гозеремне җиткердем. Төркия хатирәләрен бастырып чыгарган Язилә ханым, Аяз Гыйләҗевләр йортына шалтыратып: «Сезгә ачык хат язган төрек егете килде. Сезнең белән танышырга тели, өегездә кабул итәсезме?» – диде. Аннан: «Рәхим итсен! Иртәгә сәгать алтыда көтәбез», – дигән җавап яңгырады. Минем шатлыгым эчкә сыймады.

Кунакка барырга әзерләнгәндә кечкенә генә, матур гына, мәрмәрдән эшләнгән табигать күренеше сатып алдым. Артына мондый сүзләр теркәп куйганмын: *«Татар халкының горур аксакалы Аяз әфәндегә танышу истәлеге. Сез минем күңел түрендә мәңге яшәячәксез! Төрек егете Фатих Кутлу. 26.04.2000»*. (Бүген шул сүзләремне укып шаккатам. Кара әле, дим, танышканчы ук мин аны шулкадәр яратып өлгергән булганмын.)

26 апрель, чәршәмбе көнне, кичке сәгать алтыда, дулкынлануымның соңгы чигенә җитеп, йөрәгем дөп-дөп типкән хәлдә ишек кыңгыравына бастым. Нәкыя апа бусагадан ук: «Татарча беләсезме?» – дип каршылады...

Түргә уздык. Аяз ага бүлмәсендәге кәнәфидә утыра иде. Нәкыя апа: «Менә, кунагыбыз, төрек егете килде», – диде. Аны күрү белән эчтән генә: «Нәкъ хыялымдагыча, күзаллавымча икән үзе. Бер дә ялгышмаганмын», – дидем һәм, төрек йоласы буенча, ихтирам йөзеннән әдипнең кулларын үптем.

Танышып, хәл-әхвәл белешеп чыкканнан соң, мин, бар дөньямны онытып, аңа «Йәгез, бер дога!» романы турындагы хис-фикерләремне җиткерә башладым. Ничә сәгать сөйләшеп утырганбыздыр, хәтерләмим. Мин, култамга сорап, җөмлә асларына сызып-сызып укыган китабымны татар әдәбиятының йөзек кашына суздым. Ул, бер дә көтмәгәнчә, гаять җылы сүзләр язды: *«Фатих бәй! Сез минем йортыма кояшның бер кисәген алып кердегез. Рәхмәт!»* Күңелем тулып китте. Димәк, бу танышудан үзе дә риза-канәгать калган? Алай булмаса, мөгаен: «Иртәгә тагын кил, улларым Искәндәр һәм Мансур белән таныштырырмын», – димәс иде.

Икенче көнне баруыма ул дүрт томлыгын имзалар төшереп әзерләп куйган иде. Аның: «Фатих бәй, Сезгә шушы китапларымны бүләк итсәм, кабул итәрсезме?» – дип

соравына, каушап: «Күктән ни яуган да җир кабул итмәгән?» – дип сорау белән үк җавап кайтардым. Анда минем өчен бик кадерле сүзләр язылган иде: *«Мөхтәрәм Фатих бәйгә, гаҗәеп бер төрек баласына, чиксез яратып, зур өметләр баглап бүләк итәм шушы китапларны»*.

Бу вакытта мин – башка илдә, башка мохиттә туып үскән һәм язмыш кушып татар иленә килеп чыккан 26 яшьлек төрек баласы, ә ул – татарның 72 яшьлек аксакалы, олпат әдип иде...

***

Фатих Кутлу Аяз Гыйләҗевнең төрекчәгә тәрҗемә иткән китапларын тотып тора. 2018 ел

Шунысы игътибарга лаек: әлеге очрашуларда булсын, хәл-әхвал белешеп телефоннан шалтыраткан вакытларда булсын, аның миңа беркайчан да, «Фәлән әсәремне төрекчәгә тәрҗемә итмәссезме?» – дигән тәкъдим ясау түгел, хәтта моңа ишарә иткәне дә булмады. Дөрес, сүз ара сүз чыгып: «Кайсы әсәрегезнең төрек теленә тәрҗемә ителүен теләр идегез?» – дип соравыма ул: «Өч аршын җир», – дип әйткән иде...

Аяз Гыйләҗевнең вафаты турында ишеткәч, күңелем тулып, күзләремнән кайнар яшь бәреп чыкты. «Шушы күз яшьләрем иң җылы хисләремнең шаһиты булсын! – дидем мин, ачынып. – «Өч аршын җир»не төрекчәгә тәрҗемә итү – изге бурычым булсын!»

Башта төрле сәбәпләр аркасында укылмыйча калган дүрт томлык әсәрләрне 2005 елда – остазым васыять иткән (мин аны шулай саныйм) әсәрне төрекчәгә аударырга алынгач кына укый башладым. Повестьны хәйран калып, җөмлә асларына сыза-сыза, дүрт мәртәбә укып чыктым. Шуннан башка әсәрләргә күчтем... Теленең тәмлелеге, фикерләвенең югарылыгы һушымны алды. Чәйлимме, тукталышта автобус көтәмме – һәрвакыт кулымда Аяз Гыйләҗев китабы иде.

Әсәрләрен тәрҗемә итү бик авыр һәм мәшәкатьле эш булуга карамастан, Аяз Гыйләҗев моңа күптән лаек зат иде, билгеле. Төрек халкы бу җәүһәрләр белән һичшиксез танышырга тиеш, дип уйладым. Чыннан да, «Өч аршын җир» повесте Төркиядә дөнья күргәч (ул профессор Хатыйп ага Миңнегуловның кереш сүзе белән басылып чыкты), укыган һәркем – галимме ул, әдипме, гади халыктанмы – әсәрне үлеп яратты. Төрек халкының әлеге әсәр хакындагы фикерләрен туплап чыгарырга уйласаң, тулы бер китап булыр иде. Туган илемдә «Өч аршын җир»не, Чыңгыз Айтматовның «Гасырга сузылган көн» әсәренә караганда да тәэсирлерәк, дип бәяләделәр; бик кызыксынып, сабырсызланып Аяз Гыйләҗевнең чираттагы әсәрен төрекчәдә көтә башладылар...

Ахыры киләсе санда ■

БУЛАТ СӨЛӘЙМАНОВНЫҢ ТУУЫНА 80 ЕЛ

Булат Сөләймановның ике гаризасы

Ләбиб Лерон



Миндә Булат Сөләймановның ике гаризасы саклана. Шуның берсенә – 1968 елның 9 октябрендә язылганына өч әдип (Ибраһим Гази, Гариф Ахунов, Ләбибә Ихсанова) үз имзасын салган.

Беренче гаризага игътибарны юнәлтик:

Татарстан Язучылар союзына
яшь шагыйрь Булат Сөләймановтан

Гариза.

«Һәйкәлләр» дигән шигъри циклны тәмамлау өчен, Сездән 30 сум акча бирүегезне сорыйм.

Үтенеч белән, Булат Сөләйманов.
9/X – 68 ел.

Гариза язылган кәгазьнең өске уң ягына Язучылар берлегендә җаваплы сәркатип вазыйфасын башкарган Гариф Ахунов кызыл кара белән урысча мондый сүзләр язып куйган: *«Яшьләр фондыннан 30 (утыз) сум бүлеп бирергә. 9/X – 68. Имза»*

«Онытылмас еллар» дигән атаклы роман авторы, ул чакта Татарстан Язучылар берлеге рәисе Ибраһим Гази шулай ук кызыл кара белән: *«Хуплыйм. Ибраһим Гази. 9/X – 68.»* дип үз култамгасын салган. Ул елларда «Казан утлары» журналының җаваплы сәркатибе *(шул ук вакытта Язучылар берлегенең партия оешмасына да җитәкчелек иткән булса кирәк. –* **Л.Л.***)* булган Ләбибә Ихсанова исә *«Риза. 9/X – 68» дип имзасын*

(исем-фамилиясен кәгазьгә төшермәсә дә, имза тәгаен Л.Ихсанованыкы . – **Л.Л.***)* салган.

Икенче гаризаны Булат Сөләйманов 1969 елның 26 маенда, ягъни утыз бер яше туларга ике көн кала, алдагысыннан аермалы буларак, татарча язган:

Татарстан Язучылар союзы
идарәсенә Булат Сөләймановтан

Гариза.

Иртәгә, Мәскәүгә чираттагы сессиягә экзаменнар тапшырырга китәм (шагыйрьнең Мәскәүдә А.М.Горький исемендәге Әдәбият институтында укыган чагы. Ул аны 1974 елда тәмамлый. – **Л.Л.***). Юллык булса да акча белән ярдәм итүегезне сорыйм.*

26/V – 1969 ел. Имза.

Гаризаның бусына Гариф Ахунов, имзасын салып тормыйча гына: *«Сынау шарты белән соңгы тапкыр. Яшьләр фондыннан 30 сум»*, – дип язып куйган.

«Сынау шарты белән соңгы тапкыр»...

Хәер, кайсыбыз хатадан хали әле?! Бу урында драматург **Ризван Хәмид**нең (1941-2017) шагыйрьгә 60 яшь тулу уңаеннан язган истәлегеннән бер өзек китерү урынлы булыр кебек: «*...Себер татарының буаз портфеленнән бушатылган нигъмәтләр белән сыйланып утырдык: балыкның мин татымаган нинди генә төре өстәлгә тезелмәде анда! Соңрак белдем: Булат Сөләйманов шул иртәдә генә туган якларыннан, Түмән төбәгеннән килеп төшкән булган икән... Казан шагыйрьләре әнә шулай елына берничә мәртәбә затлы балыкка тиенеп кала иде...*»

Себер шагыйре, Күчем хан оныгы Булат Сөләйманов корган әлеге балыклы мәҗлесләрнең берничәсендә мин бахырыгызга да катнашу насыйп әйләгән иде. Корней Чуковский А.П.Чехов турында: *«Ул магнит шикелле кунакчыл иде»*, – ди. Мәрхүм Булат Сөләйманов та шундый кеше иде, бахыр...

Булат Сөләйманов

АУЧЫ ӨЕНӘ КИРЕ КАЙТМАДЫ

Аучымы,
Аучынымы нидер аулады...
Кара урман шомлы шаулады.

«Озак йөрмәм», – дигән иде бит.
Авылдашлар тирги давылны,
Күмеп киткән өчен авылны.

У-у-у...
Йокламады авыл төн буе.
Һәркемнең дә иде бер уе:
«Менә-менә кайтып керер ул».

Төн үтте...
Төн артыннан тагын көн үтте.
Аучы өенә кире кайтмады...
Авыл өстен болыт каплады. ■

Галимҗан Нигъмәти

(1897-1941)

Бу сәхифәне, бигрәк тә аның шәхес культы корбаннарына багышланган язмаларын әзерләгәндә безгә күренекле язучы-эзтабар Рафаэль ага Мостафинның хезмәтләре гаять зур ярдәм күрсәтә. Бөтен гомерен рәнҗетелгәннәрне яклауга, нахак яла ягылганнарны аклауга, Олуг Хакыйкатьне эзләүгә һәм табуга фида кылган әдибебез, баксаң, төгәл 87 ел элек – 1931 елның 14 маенда дөньяга килгән икән. Сез хәзерге вакытта укый торган мәкалә дә, нигездә, Рафаэль аганың «Һәммәсен исемләп искә алыйк» документаль циклыннан әдәбият галиме һәм тәнкыйтьче Галимҗан Нигъмәтигә багышланган өлешенең сөземтәсе булыр.

Шул рәвешле без татарның ике күренекле улын берьюлы яд итәрбез.

Урыннары җәннәттә булсын!

Әдәбият галиме, тәнкыйтьче һәм педагог Галимҗан Әмирҗан улы Нигъмәти (Нигъмәтуллин) – илдә пролетариат диктатурасы һәм идеологиясе хөкем сөргән, әдәбият-сәнгать өлкәсендә вульгар социологизм карашлары өстенлек иткән чорда яшәгән шәхес. Әдәбият-сәнгать әсәренә бәя биргәндә, иң әүвәл сыйнфый күзлектән якын килү, әсәрнең эчтәлеге, идеясе пролетариатка хезмәт итәме-юкмы икәнлеген, иҗатчысының да кайсы сыйныфтан булуын ачыклау – ул чор әдәбият белеме методологиясенең төп нигез принциплары рәвешендә кабул ителгән. Билгеле, үзен марксист тәнкыйтьче итеп санаган Галимҗан Нигъмәтинең хезмәтләрендә дә бу социологик ысулларны еш очратырга мөмкин. Әмма, татар әдәбият белеме һәм тәнкыйтендәге ортодоксаль вульгар социологизм тарафдарларыннан (Х.Наум, Х.Вәли һ.б.) аермалы буларак, Нигъмәти әдәби әсәрләрне яки язучы иҗатын анализлаганда аларның сәнгатьчә эшләнеш дәрәҗәсенә, образлылык, тел-стиль мәсьәләләренә дә игътибарын юнәлтә, язучылардан укучыларны тирән дулкынландырырлык эмоциональ тәэсир көченә ия булган, югары сәнгать дәрәҗәсендәге әсәрләр тудыруны таләп итә.

Галимҗан Нигъмәти – утызынчы елларда совет режимы оештырган һәм өч дистәдән артык татар язучысының гомерен өзгән дәһшәтле репрессия корбаннарыннан.

Шомлы 1937 елның апрель уртасында НКВДның яшерен хезмәткәре (исеме бүгенгә кадәр сер итеп саклана) Черек күлдәге башлыкларына Казан педагогия институтының татар әдәбияты кафедрасы мөдире, профессор Нигъмәтинең 11 апрель көнне (берәр атна элек) шагыйрь Хәсән Туфанда кунакта булуы турында җиткерә. Бу көнне шагыйрь кызы Гөлгенәнең туган көне уңаеннан дуслары белән кечкенә генә мәҗлес оештыра. Табын артына иң якын дуслар һәм туганнар җыела. Шунда яңа гына кулга алынган тәнкыйтьче һәм әдәбиятчы галим Гомәр Гали[1] турында сүз чыга. Туфан үзенең борчылуын һәм аптыраашта калуын яшерми, гадел һәм сүзендә торучан бу кешене тирән хөрмәт итүен, аның гаепле булуына ышанмавын әйтә. Аның фикеренә кушылып, Галимҗан Нигъмәти, әгәр дә Гомәр Гали партиядә тормаса, мөгаен, бу хәл булмас та иде, дип куя. Һәм, партиясезләргә мөрәҗәгать итеп: «Партиягә кермәгәнегезгә шатланыгыз», – ди.

Бөтен «гаеп» шуннан гыйбарәт була. Нигъмәтинең нәрсә әйтергә теләвен барысы да аңлый, әлбәттә: бу вакыйгаларга ярты ай кала аның үзен дә «контрреволюцион элементлар һәм буржуаз милләтчеләр белән бәйләнештә торганы өчен» ВКП(б) сафларыннан чыгаралар... Ул елларда партиядән чыгарылганнан соң кулга алыну күк күкрәгәннән соң яшен суккан тизлектә башкарыла.

Кырык яше тулып узган Галимҗан Нигъмәти 1937 елның 16 сентябрендә Тельман урамындагы 4 йортның 6 фатирында кулга алына. НКВД тикшерүчеләре Әүхәдиев һәм Каменщиков, IV бүлек баш-

---

[1] Алдагы саннарның берсендә аның да фаҗигале язмышын күздән кичерербез әле. – Р.М.

Тоткыннар утын әзерләү эшендә. 1940 нчы еллар

лыгы Веверс имзалаган кулга алу турындагы карарда Нигъмәти «троцкийчыларның милләтчел контрреволюцион оешмасы әгъзасы буларак, аның актив эшлеклеләре Атнагулов[2], Касыймов, Толымбай[3] һ.б. белән хәзерге көнгә кадәр әдәби-идеологик фронтта корткычлык эше алып бара», диелгән.

Бу елларда НКВД аерым шәхесләр белән шөгыльләнеп мәшәкатьләнми, нигездә, дистәләгән, кайчакта йөзләгән кешене тикшерергә мөмкинлек бирә торган «төркемле» эшләр уйлап чыгара. Бу очракта кешенең элек хөкем ителгән «халык дошманнары» белән нindидер бәйләнеше булуын ачыклау (яки ачыкланды дип яла ягу) җитә кала, аны шул ук «советка каршы контрреволюцион төркем»гә теркәп тә куялар. Гаепләү карары күрсәткәнчә, Галимҗан Нигъмәтине башта «Атнагулов төркеме»нә кертергә уйлыйлар.

Беренче сорау алу тоткарланган көнне үк үткәрелә. Тикшерүченең: «Үзеңә тагылган гаепне танныйсыңмы?» – дигән соравына ул: «Юк, танымыйм», – дип катгый җавап бирә. Берничә көн буена шулай дәвам итә. Аннары сорау алу ярты ел тукталып тора. 1938 елның март ахырларында гына Нигъмәти үзен япон шпионы дип таный. Әлеге сорауга җавапны тикшерүче түбәндәгечә теркәп куя: «Әйе, Совет хакимиятен Япония ярдәмендә бәреп төшерүне һәм Япония протектораты астында төрки-татар буржуаз «Идел-Урал» дәүләте төзүне максат итеп куйган Советка каршы контрреволюцион оеш-

---

[2] Сәлахетдин Садри улы Атнагулов (1897-1937) – сәясәт эшлеклесе, публицист, язучы. Милли Мәҗлес депутаты.

[3] Габделхак Җәләлетдин улы Шаһиәхмәтов (тәхәллүсе – Гомәр Толымбай, 1900-1939) – язучы һәм әдәбият тәнкыйтьчесе.

Вожаель бистәсендәге элеккеге карцер һәм тикшерү изоляторы. 2000 нче еллар

мада 1929 елдан бирле тордым, үземне гаепле дип таныйм».

Язма астына Галимҗан Нигъмәти үзе кул куйган. Имза элеккеләреннән аерылып тора: калтыраган кул белән язылган кыек, аска тәгәрәп бара торган хәрефләр...

Гаепләү карарында тагын бер нәрсә игътибарны җәлеп итә: тикшерү башланган чакта Нигъмәтине «Атнагулов төркеме»нә «кушсалар», соңыннан аны «Идел-Уралчылар» төркеменә «күчерәләр».

1938 ел ахырына СССР эчке эшләр министры Николай Ежов вазыйфасыннан алынып, НКВД хезмәткәрләре арасында кадрларны алмаштыру башлангач, сәяси тоткыннарны кысу бераз кими төшә, кайберәүләрне хәтта иреккә чыгаралар. Нигъмәти, әлеге хәлдән файдаланып, үзенең элек биргән мәгълүматларыннан баш тарта һәм бу фактны рәсми беркетмәдә теркәтүгә ирешә.

Аңа да карамастан, Галимҗан Нигъмәтинең үзе дә кире кага алмаслык бер «гөнаһы» була һәм тикшерүче шуңа ныклап ябыша. Документларда бу «гөнаһ» «татар әдәбиятының үзенә хас юлы турындагы буржуаз теорияне яклый» рәвешендә теркәлгән.

Чыннан да, тәнкыйтьче һәр язган мәкаләсендә, һәр чыгышында күп гасырлык традицияләргә ия булган татар әдәбиятының үзенә генә хас юлы турында фикер үткәрә; халкының борынгы тарихы, гореф-гадәтләре, теле, меңьеллык имласы җуелу белән килешергә теләми. Мондый үҗәтлек, билгеле, милли үзенчәлекләрне юкка чыгаруга, «реакцион, идеалистик, байлар, феодаллар» традицияләреннән баш тартуга юнәлдерелгән сталинчыл партия аппаратының һәм аңа эшләүче репрессия машинасының максатларына аркылы төшә.

Нәтиҗәдә, 1939 елның 15 маенда Галимҗан Нигъмәтигә яңа гаепләү карарын укыйлар, бу юлы ни «Атнагулов төркеме», ни

«Идел-Уралчылар» турында сүз булмый. Аны шундый ук уйдырма «уң троцкийчыларның контрреволюцион террористик үзәгендә» актив эшчәнлек алып баруда гаеплиләр. Хөкемгә тартылучы үзен гаепсез санап, бу хакта рәсми беркетмәдә теркәлсә дә, «махсус киңәшмә» аны биш елга ирегеннән мәхрүм итә.

Ул заманнар өчен биш ел гаять кыска срок булып күренергә мөмкин. Өстәвенә, Галимҗан Нигъмәти, мәхкәмә көтеп, тоткынлыкта өч ел гомерен уздырган була инде, аңа лагерьда ике елдан артык вакыт кына үткәрәсе кала. Әмма, тикшерүчеләр сүзенә караганда, «гади совет тоткыны»ның ГУЛАГ шартларындагы гомере алты айдан артмый. Җиңелрәк эшләргә эләккән кайбер бәхетлеләр генә (тоткыннар үзләре аларны «тинтәкләр» – «придурки» дип атый) озаграк яши ала... Тәнкыйтьче-әдип исә алар рәтенә керми.

Аның «эше»нә беркетелгән белешмәдә «хөкем ителгән Галимҗан Нигъмәтуллин 1941 елның 4 декабрендә Коми АССРның Тимер юл районы Вожаель поселогындагы[4] «Устьвымлаг»та үлде»[5] дигән мәгълүмат бар. Күренгәнчә, тоткынлык чоры бетәргә берничә ай гына калган була. Галимҗан Нигъмәтинең соңгы адресы – 243 номерлы почта тартмасы (хәер, туганнары белән хат алышу тыелган була). Аны, аягына химик карандаш белән тоткынлык номеры (802144[6]) язылган фанер такта бәйләгән хәлдә, торф сазлыгына күмәләр. Кабер өстенә куелган агач тактада да шул ук номер күрсәтелгән була. Каберне эзләүдән файда юк, чөнки ул инде күптән тундра баткаклыгында түмгәкләр белән кушылып юкка чыккан[7].

Кулланылган әдәбият:

1. Әдипләребез: биобиблиографик белешмәлек: 2 томда: 2 том/ төзүчеләре Рәис Даутов, Равил Рахмани. – Казан: Татарстан китап нәшрияты, 2009. – Б.198-199.
2. Рафаэль Мостафин. Һәрберсен исемләп искә алыйк. – Казан: Татарстан китап нәшрияты, 2014.
3. Хәмзә Бәдретдинов. Галимҗан Нигъмәти токымы. «Мәдәни җомга» г., 15 декабрь 2017 ел, №49. – Б.8-9.

Рузәл Мөхәммәтша *әзерләде.* ■

[4] Рафаэль Мостафин хезмәтендә шулай язылган. Бу хезмәттә яисә белешмәнең үзендә үк хата киткән булса кирәк, чөнки Вожаель тимер юл станциясе (бистәсе) дә, «Устьвымлаг» үзе дә Коми Республикасының Княжепогост районында урнашкан була.

[5] Әдипнең хатыны (белгечлеге буенча юрист һәм икътисадчы) Маһиҗиһан Нигъмәтуллина иренең язмышын ачыкларга теләп язган хатка югарыдан ике җавап килә: беренчесендә галимнең үлеме йөрәк авыруына бәйләп аңлатыла; икенче белешмәдә диагноз «җылылык суккан» (кыш көне! салкын якта!) дип күрсәтелә.

[6] Кайбер тикшеренүчеләр карашынча, әлеге номер ГУЛАГ системасында үлгән тоткыннарның тәртип санын күрсәтә. Димәк, Галимҗан Нигъмәти төньяк киңлекләрдә күмелгән 802114 нче кеше булган.

[7] 2017 елның 15 декабрендә (№49) «Мәдәни җомга» газетасында дөнья күргән «Галимҗан Нигъмәти токымы» язмасында автор Хәмзә Бәдретдинов күренекле әдәбият галиме һәм тәнкыйтьченең бу рәвешле бакыйлыкка кичүен шик астына ала. Ул, милләтпәрвәрнең кызы – Казан дәүләт университетының профессоры Йолдыз Нигъмәтуллина фаразына һәм башка чыганакларга таянып, Галимҗан Нигъмәтинең тоткынлыктан яуга җибәрелүе, Бөек Ватан сугышында катнашуы һәм Сталинград фронтында һәлак булуы турында фикер уздыра. Ләкин бу фараз төрле истәлекләр, хатирәләр белән баетылса да, нинди дә булса документлар белән ныгытылмаган. Мәсьәлә алга таба да өйрәнелеп, күренекле галимнең бакыйлыкка кичү тарихына ачыклык керер, дигән өметтә калабыз. – Р.М.

ШАГЫЙРЬ МАКС ГАТАУ ҺӘМ АНЫҢ ТУГАН АВЫЛЫ ТОЗАУ

Узган ел Курган өлкәсенең Әлмән районындагы татар авылларында, аерым алганда, Өчкүлдә, Бишнәктә (Вишняково), Иминкүлдә (Иванково), Тозауда булырга туры килде. Тозау – татар совет шагыйре Макс Гатауның (Гайнетдин Гатауллин, 1913-1941) туган авылы. Татарстанның сәнгать эшлеклесе, рәссам Ким Сафиуллин да тумышы белән шушы авылдан.

Тозау авылындагы Яр буе урамы. 2017 ел

Тозау – өч урамнан (Яр буе, Совет һәм Гагарин) торган авыл. Иң зурысы – Тозау күленә караганы – Яр буе урамы. 1926 елда бу авылда – 1017, 2010 елда 95 кеше яшәгәне билгеле...

...1586 елда 12 нәсел ыруы (Тынкачевлар, Байбулатовлар, Әнвәровлар, Әсәновлар, Уразмәтовлар, Искәевләр, Кампачевлар, Юмаевлар, Мансуровлар, Алферовлар, Барашевлар һәм Бармаковлар) хәзерге Әлмән биләмәсенә килеп урнаша. Аларны эчкен татарлары дип атап йөрткәннәр. Күчеп килүчеләрнең соңгы өчесе урыслар була. Тора-бара алар, татарлашып, мөселман динен кабул итә.

Галия апа Әхмәтҗанова шагыйрь Макс Гатауны белгән укытучы Гайшә апа турында сөйли. 2017 ел

Макс Гатауга туган тиешле Рәйфә Җамал кызы Әминева (Иминкүл авылы)

Килүчеләр ике күл арасындагы калкулыкта төпләнә. Күлнең берсен – Билкау (авыл исеме дә шуннан килә, урысчасы – Бельково) дип, икенчесен Юньле Әлмән (яки Әлмәнкүл) дип атый башлыйлар.

Билкау белән бер үк вакытта янә ике авыл – Өчкүл (Учкулево) һәм Чияле (Вишняково) барлыкка килә.

XVII гасырда нәкъ менә шушы өч авылда яшәгән эчкен татарлары ул вакытта җирле ак казаклар булып саналып йөртелгәннәр.

1720 елда әлеге авылларда яшәүчеләр янә өчкә бүленә. Күчүчеләрнең күпчелеге Әлмәнкүлнең көнчыгыш ягына килеп урнаша һәм ул урында Әлмән (Альменево) дигән авыл барлыкка килә.

Шул ук елда җиде гаилә исемсез бер күл янына килеп урнаша һәм Тозау авылына нигез сала. Әлбәттә, күл Тозау исемен йөртә башлый.

1740 елда Өчкүлдән берничә гаилә аерылып чыга һәм суы сихәтле бер күл янында Иминкүл (Иванково) авылы барлыкка килә.



Гайнулла Насыйбулла улы Рәхмәтуллин (1924-1993)

Рәссам Ким Сафиуллин шәкертенә киңәш бирә. 2004 ел

Шагыйрь Макс Гатау* турында берничә сүз.

«Әдипләребез» (2009) китабында Макс Гатау (Гайнетдин Зәйнетдин улы Гатауллин) турында кыска гына мәгълүмат бирелгән: шагыйрь 1913 елда хәзерге Курган өлкәсенең Әлмән районы Тозау авылында туа. Яшьтән ятим калып, балалар йортында тәрбияләнә, шунда җиде класс белем ала, аннары Чиләбе өлкәсенә китеп, авыл хуҗалыгы техникумын тәмамлый. 1937 елда ул Казан дәүләт педагогия институтының читтән торып уку бүлегенә кабул ителә.

М.Гатау балачактан ук әдәбият белән кызыксына, халык авыз иҗатын өйрәнә, җырлар, бәетләр җыя. Урал табигате, андагы социалистик төзелеш күренешләре, күмәк хуҗалыклар оештыру – яшь шагыйрьнең 1939 елда басылып чыккан «Урал мәхәббәте» исемле бердәнбер шигъри җыентыгының төп эчтәлеген шул тәшкил итә.

М.Гатау 1941 елның июлендә фронтка китә һәм шул елның 20 ноябрендә Калинин өлкәсендәге Гаврилово авылы янында барган каты сугышларда батырларча һәлак була.

***

Тумышы белән Тозаудан булган рәссам Ким Сафиуллин (1926) турында берничә җөмлә. Ким Мөхәммәт улы Сафиуллин – Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе, 1958 елда Дүшәмбе сәнгать училищесын, 1962 елда исә Мәскәүдәге Суриков исемендәге сәнгать институтын тәмамлый. Яшьлек еллары Таҗикстанда уза. Бөек Ватан сугышы ветераны. 1969 елда Казанга килә. 1971 елдан Чаллыда яши. 1993 елда «Чыңгызхан» (триптих) әсәрен иҗат итә.

Бөек Ватан сугышы ветераны Гайнулла Насыйбулла улы Рәхмәтуллин да шушы авыл кешесе. Ул 1924 елның 13 февралендә туган. Бихисап орден һәм медальләр иясе. Алар арасында «Батырлык өчен» медале, Кызыл Йолдыз ордены да бар. 1993 елның 27 мартында вафат була.

Язманы ***Л.Лерон*** *әзерләде.* ■

* Шагыйрь Макс Гатау (1913-1941) шигырьләре журналыбызның алдагы санында (№4, 2018) басылды.

Безнең мирас №5 май 2018

ИСТӘ, ҺАМАН ДА ИСТӘ!

Язучы Зариф Бәширинең тууына 130 ел

Шагыйрь, язучы, мәгърифәтче-педагог **Зариф Шәрәфетдин** улы **Бәширов** 1888 елның 5 маенда элекке Казан губернасының Чивил (Цивил) өязенә (хәзерге Татарстан Республикасының Кайбыч районы) кергән Чүти авылында туа.

1933 елда Уфага күчеп килә һәм гомеренең соңгы көннәренә кадәр шунда яшәп, 1962 елның октябрендә вафат була.

З.Бәширинең кайбер әсәрләре: «Ефәк күлмәк» (1928), «Кара тараканнар» (1930), «Шаян Фәһим» (1910), «Чуаш кызы Әнисә» (1910), «Каракошявы» (1938).

«Мин җиде яшемдә чагымда укырга-язарга өйрәнгән идем. Минем бөтен бирелеп укыганнарым «Таһир-Зөһрә», «Буз егет», «Мәгъшукнамә», «Кәҗә бәете», «Килен бәете» кебек нәрсәләр була торган иде...

Әтинең ике хатыны, ике хатынга ике оя баласы бар. Ул оялар да, юри шулай эшләнгән шикелле, бер-берсенә капма-каршы: зур әнкәйнең балалары – һәммәсе дә кызлар, ә минем әнинең балалары – һәммәсе дә малайлар. Йорт эчендәге бөтен талаш-кычкырышның да төп сәбәбе әнә шунда».

Зариф Бәшири.

«Замандашларым белән очрашулар». (Казан: Татар. кит. нәшр.,1968. – 292 б. – 7000 д.)

Артист Рәсим Сәлаховның тууына 80 ел



Татарстанның халык артисты Рәсимҗан Салихҗан улы Сәлахов 1938 елның 10 маенда Башкортстанның Илеш районындагы Җәйләү авылында туа.

1961 елда В.Качалов исемендәге Зур драма театры каршындагы студияне тәмамлый. Армия хезмәтеннән соң, 1965 елдан алып вафатына чаклы Г.Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрында эшли.

Р.Сәлахов башкарган рольләр: Хаммат, Бики – «Хуҗа Насретдин», Качкинский – «Һиҗрәт» (Н.Исәнбәт); Рәдиф – «Җиргә тапшырылган серләр», Марат –«Әңгер-меңгер» (А.Гыйләҗев); Зөфәр – «Зөбәйдә – адәм баласы» (Ш.Хөсәенов); Наил – «Туй алдыннан» (Х.Вахит); Ибраһим – «Казан сөлгесе» (К.Тинчурин); Баязит – «Улыбыз өйләнә, без аерылышабыз» (И.Юзеев); Калакай – «Бәхетсез егет» (Г.Камал); Савва –«Рәхәт яшибез» (М.Гыйләҗев); Фәһим – «Хушыгыз», Юныс – «Шәҗәрә» (Т.Миңнуллин); Хәзрәт – «Зөләйха», Әхмәтсагыйр – «Алдым-бирдем» (Г.Исхакый); Хәлим – «Карак» (З.Хәким); Тикшерүче – «Саташкан сандугач» (Р.Зәйдулла) һ.б.

Артистка Дамира Кузаеваның тууына 70 ел

Татарстанның халык артисткасы (1986), Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты (1979) Дамира Нәҗмиҗан кызы Кузаева 1948 елның 16 маенда Молотов өлкәсе Барда районының Төнгүк авылында туа.

Туфан Миңнуллинның «Ай булмаса – йолдыз бар» пьесасы буенча куелган спектакльдә Мәдинә ролен уйнаган өчен 1979 елда Татарстанның Г.Тукай исемендәге Дәүләт бүләгенә лаек була.

Дамира Кузаева 1993 елның 20 декабрендә 45 яшендә вафат була һәм туган авылы Төнгүктә җирләнә.

«...Инде барысы да җайга салынды, дигәндә генә, күпме рәнҗетелүләр күргән, ятьмәгә эләккән сайрар кош кебек чәбәләнгән Дамира Кузаева 1993 елның декабрендә үз-үзенә кул салган, дигән хәбәр татар җәмәгатьчелегенә аяз көнне яшен суккан кебек тәэсир итте. Үз-үзенә кул салырлык сәбәпләре юк иде инде аның бу чорда. Ул, әлегә хәтле ачылып бетмәгән сәбәпләр белән, якты дөньядан китеп тә барды».

Рәдиф Сәгъди.
«Тетрәндереп киткән алиһә». («Безнең мирас», №6, 2016 ел)

Галим Хатип Госманның тууына 110 ел

Әдәбият галиме, филология фәннәре докторы, ТАССРның атказанган фән эшлеклесе **Хатип Госман** улы **Госманов** 1908 елның 21 маенда элекке Пермь губернасының Усы өязендәге (хәзер Пермь краеның Чернушка районы) Сулмаш дигән татар авылында мәзин гаиләсендә туа.

Х.Госманның турыдан-туры катнашында 1969 елда урта гасыр шагыйре Котбның «Хөсрәү вә Ширин» поэмасы гарәп графикасында ике кисәк булып басылып чыга, 1970 елда, шәрех-аңлатмалар белән, ундүртенче йөз шагыйре Хисам Кятибнең «Җөмҗөмә солтан» дастаны, 1980 елда Сәйф Сараиның «Китабе Гөлестан бит-төрки» поэмасы, 1981 елда XIV-XVIII йөз шагыйрьләренең әсәрләрен үз эченә алган «Борынгы төрки һәм татар әдәбиятының чыганаклары» дигән күләмле китабы нәшер ителә.

Х.Госман 1992 елның 12 февралендә Казан шәһәрендә вафат була.

«1929-1932 елларда Хатип Госман «Динсезләр» исеме белән Казанда чыккан газета редакциясенә эшкә урнаша. 1931 елда Галимҗан Нигъмәти булышлыгы белән аның «Кырлар лирикасы» дигән беренче шигъри җыентыгы басыла. Ләкин озак та үтми, газетада җыентык турында Ибраһим Гази имзасы белән «Кулак лирикасы» исемле үтергеч тәнкыйть мәкаләсе басылып чыга. Нәтиҗәдә, яшь шагыйрьнең матбугат мәйданы киселә, аның язганнарын беркайда да басмый башлыйлар. Шагыйрь үзе Казанны ташлап китәргә мәҗбүр була...»

(«Әдипләребез. Библиографик белешмә». 2009 ел, 1 том) ■

Безнең мирас №5 май 2018

ӘЗ-МӘЗ ҮЗЕМ ТУРЫНДА

Равил Шәрәфи

ӘНИЕМ ШӘМСЕЗОХА

Димәк, минем файдалы хезмәт белән шөгыльләнә башлавым, әлеге дә баягы, 1943-44 еллар кышыннан баш алып киткәндер, дип уйлыйм. Кышы буе кысылыбрак утырган баланың җәйге көннәрдә тәмам языльш, җәелеп, исәрләнеп чабып йөрүе хәтергә уң яктан килеп кергән хатирәләрне сул яктан ук чәчеп барган, ахры, искә алып сөйләрлек берни калдырмаган. Хәер, авылыбызның Каршы асты тавы дигән матур бер урынында, беренче тапкыр үзем тапкан җир җиләген өзеп капканымны һәм ул җиләкнең татлыдан да татлы тәменең әлегәчә тел очымда саклануы да, ирексездән, бу язма истәлегемдә урын даулады.

Әйтергәме-әйтмәскәме бусын, дип, үз-үземне аптырата торгач, чөнки адәм баласы мондый нәрсәгә шикләнеп карый, шулай да бала башыннан узган бу тәкый гаҗәп хәл белән дә уртаклашырга кирәк таптым. Гадәттә бит инде балалар кече йомышларын өйдә калдырылган махсус савытта башкаралар. Суык өйалдында озак торып булмый, аякларың бик тиз бозга ябышып ката. Ходаның хикмәте, ниндидер көч мине чатнама

Дәвамы. Башы журналның 4 нче (2018) санында.

салкын көнне өйалдына чыгарга мәҗбүр итте. Өйалды ишегенә карасам, ишекнең аскы ягында тәрәзә хасил булган. Шул тәрәзәнең тыш ягында ап-ак бик матур сарык бәрәне арт аякларына баскан да актан да ак, пакьтан да пакь нәни тояклары белән тәрәзә пыяласын шакып тора. Ишекне ач та бу сөйкемле җан иясен өй эченә чакырып керт бит инде... юк, ни сәбәптәндер, кулларым ишек келәсенә үрелмәде. Ялан тәпиләремне куырган салкын да минем күңелемне уята алмады. Бу хәл турында кат-кат уйлаганым бар, хәтта менә хәзер дә уйлыйм, тик очына гына чыгып булмый. Әллә минем янга «агнец божий», үзебезчә итеп әйтсәк, корбан бәрәне килгән булдымы икән? Шунда яныма керткән булсам, изге кешегә әверелеп киткән булыр идемме?! Начар булмас иде кебек бу, дим, әмма изге кеше булмый калуыма да сөенәм. Изге зат булу бик-бик җаваплы, бик-бик авыр эш шул. Бу гөнаһ белән шыплап тулган дөньяда изге кешегә тормыш итүләре отыры авыр булыр иде, дим. Әле монда гөнаһлар кыла-кыла яшәве дә бик ансат түгел.

Шулай да иң-иң истә калган балачак хатирәсе әтиемнең үлү хәбәре белән бәйле. Бу турыда мин мәктәптән кайтып кергән нәни абыйдан ишеттем. «Әтине үтергәннәр, бар, кырга мен дә, әнине табып шуны әйт!» – диде. Үзең барып әйтсәң әйбәтрәк булыр иде, дип карышып маташмадым, аның сүзен аста калдырып буламыни?! 1944 елның инде катыра башлаган салкын көзендә, яланаякларым туңуга да карамастан, тегермән тавының пычрак сыртына тая-егыла менеп, кырда әниләр эшләгән җирне эзләп киттем. Бата-чума йөри торгач, караеп күренгән бәрәңге саплары артындагы зур бер бәрәңге көшеле янына барып чыктым. Бәрәңге чүпләп утыручы хатын-кызлар арасында әнине күреп: «Әни, анда әтине үтергәннәр!» – дидем. Әни: «Беләм, улым, син бар, кайт!» – диде. «Бергә кайтыйк» – диюемә: «Мин эш беткәч кайтам, монда туңып торма!» – диде.

Ә бит мондый чакта кайтып китсә дә сүз әйтүче булмас иде аңа. Юк, эш ташлап кайтып китсә, ул аннары минем әни булмас та иде. Әниемнең беркайчан да эштән качарга сәбәп эзләгәнен хәтерләмим. Бушка эшләнгән эшләр дә аның җанына тынычлык биргән,

«Мулланур Вахитов» (Н.Исәнбәт) спектакленнән бер күренеш. Сулдан уңга: Мулланур – Ринат Таҗетдинов, Әҗим – Равил Шәрәфи, Сатаев – Фатыйх Кульбарисов. 1976 ел

«Шау-шулы көн» (П.Бомарше) спектакленән бер күренеш.
Сулдан уңга: Фигаро – Н.Дунаев, граф Альмавива – Р.Шәрәфи.

күрәсең. Кырдан кайткач кына елады әни ул көнне. Кешегә күз яшьләрен күрсәтмичә елый белә иде. Әни кебек кешеләр эш сөймәгән, хәзерге телдә «сачок» дип йөртелгән кешеләрдән бәхетлерәк иделәр. Эштән тәм һәм җанына тынычлык таба белгән әнием кайгы-хәсрәтләргә дә бирешмәде. Соңрак чорда әнинең кырда урак урганын шаккатып күзәткән чакларымда шуңа игътибар итә идем – кырда аңа тиңнәр юк иде. Урак уручылар бер «бәпкә» куйганда әнием икене куеп өлгертте.

Кабат әтием искә килеп төште. Ничек инде аны сагынмаска, аның белән горурланмаска мөмкин. Күпме кеше авызыннан мин аның турында легендага охшаган сөйләкләр ишеттем. Аның башбирмәс бәйсез холыклы булуын, ирек яратуын, гаять гайрәтле ир дә булуын бик еш сөйләрләр иде.

Шулардан берсен сезгә дә, авыл кешеләреннән ничек ишеткән булсам, шулай тәкъдим итәм. Сугыш алды елының ниндидер яңгырлы пычрак аенда, җиде төн урталары җиткәндә авылның «Борахау» дигән очыннан берничә атлы авылга кереп кунып чыгарга урын эзли башлый. Муеннан пычракка баткан бу урысларны берәүнең дә өенә кертәсе килми. Безгә килеп ялынган бу юлчыларны, өебез артык зур булмаса да, әти кире борып җибәрми: «Сыйсагыз – кунигыз», – ди. Болар бездә кунып, иртәнге чәйләрне дә эчкәч, «спасибо»ларын әйтеп, 12 чакрымдагы авылларына юл алалар. Бераздан әти ишегалдына кичтән бүкәнгә чабып калдырган балтасын алырга чыга. Балтадан җилләр искәнен күреп, эшнең нәрсәдә икәнен аңлауга, ике дә уйлап тормыйча, иңенә мылтыгын аса һәм атына сикереп атланып кунаклар киткән якка чаптырып китеп бара. Аның: «Теге урыслар эше», – дигән сүзләрен генә ишетеп калалар. Кунак иткән урысларын әти тегеләр авылларына килеп җитәрәк куып тота. Авыл белән атлылар арасындагы юлга аркылы төшеп, атын туктата да бик тыныч кына, әмма үзенә генә хас кырыслык белән: «Братцы, сездән соң лапас астындагы балтам юкка чыкты, кайда ул?!» – ди. Үзен бик үк аңламаганнарын күрепме, әллә юри аңламамышка салышалар, дипме, русча да өсти: «Кто взял мой топор? Посмотрите у себя!» Тегеләр бик тиз генә бер-берсенең арбасын тикшерергә керешәләр һәм балтаны яшерелгән җиреннән табып алып шау куптаралар. Әти, балтаны алып: «Ит яхшылык, көт ширлек», – дип

сукрана да: «Ну покажите как следует этому неблагодарному!» – ди. Тегеләр: «Давай, сам накажи его!» – дип, әлеге комсыз кешене аның каршына ук бастыралар. Әти: «Эх ты, неблагодарный, тычкак сыер, бөтен көтүгезне бukладың!» – дип җиргә төкерә дә, атын кайту ягына бора. Урыслар моны үзләренчә аңлап, әлеге каракны бик рәхәтләнеп дөмбәсләргә керешәләр. Әти, китә башлаган җиреннән әйләнеп кайтып: «Достаточно бить, я не такой уж жестокий, но если вы уж сочтете, что мало поучил, то вам виднее, продолжайте!» – дип өсти. Берникадәр юл үтеп артына борылып караса, тегеләр һаман да бу акылсызны акылга кертеп маташалар, имеш.

Сугыш та әти холкын үзгәртә алмаганга охшый. Сөйләгәннәренә ышансак, аның бөтен сугышып үткән юлы гел батырлыклардан гына торган кебек. Интернеттан укып белгәнебезчә, Кызыл Йолдыз ордены аңа бер-бер артлы дүрт батырлык кылганы өчен бирелә. Моны ишеткән кешеләр, башка сугышчыларга мондый батырлыкларның сыңары өчен генә дә орден-медальише бүләкләр бирелгән, хәтта Герой исемен дә алучылар булган, ә Шиһап абзый мәсьәләсендә нигә шундый саранлык күрсәттеләр икән соң, дип аптырыйлар. Ә инде аның берьялгызы 50 немецны әсир итеп алып кайтуын да белгәч, кешеләр тәмам хәйран калалар! Чыннан да, дошман тылыннан бер «тел» алып кайтучы да герой исемен йөрткәндә, әтине бөтенләй онытып калдырулары минем дә күңелне тырный. Күрәсең, сугышта да нәкъ бүгенге тыныч тормыштагыча булган: эшләгән эшләреңә бәя куюдан да бигрәк, күндәм холыклы булуыңны артыграк күреп бүләкли торган булганнар, ахры. Әтинең үлү хәбәре килгән документта: «Шиһабетдин Шәрәфиев сугыш кырында батырларча һәлак булды», – дигән юллар бар. Менә монда да уйласаң уй җитәрлек. Ядрә әтинең нәкъ йөрәгенә төбәп атылган. Туры сүзле, үз уен беркемнән дә курыкмыйча йөзләренә бәреп әйтә торган әтинең дошманнары да җитәрлек булган, диләр, шуңа, үлеме үзебезнекеләр кулыннан булмадымы икән, дим. Аның йөрәге сугышның ахыры якынлашкан бер вакыт аралыгында, Җиңү көннәренә инде санаулы айлар гына калып барган чорда туктап кала. Әйтерсең лә сугыш турында чын дөресен әйтеп бирәчәк кешеләрне алдан ук күреп гомерләрен чикләп куйганнар, ягъни мавр үз эшен эшләде инде, аның кирәге юк, дигән гыйбарәдәгечә. Минем башка килгән уй гына димәс идем моны. Ул инде шул чорга караган бүгенге документларда да ныклы урын алган. Үзләре булдыксыз, куркак һәм бик надан булган командирларның хәлиткеч ялгышлары аркасында күпме кешенең гомерен өзгәннәре бик күпләргә билгеле. Ә сугыш чорында бу хакта сөйләп кара! Дөресен сөйләүчеләрне тәртип сакларга куелган органнарның бик ныклап куркытып йөрүләрен, буйсынмаучыларын төрле юллар белән юк итүләрен дә хәзер инде сер итеп сакламыйлар. Мин мондый фикерне әти белән бергә сугышып йөргән авылдашым Дәүләт абыйны да күз алдымда тотып әйтәм. Авылга язган хатында: «Шиһапның орден-медальләрен үзем белән алып кайтам», – дип нәзер әйтеп тә, авылга кайткач безне күрмәмешкә салышып йөрүе сәер түгелмени? Кайда соң ул безгә вәгъдә иткән әти бүләкләре?! Үзләштермәгәндер бит инде ул аларны, әллә югалтканмы, әллә аны да куркытканнармы? Һич булмаса, безнең өйгә кереп, башыбыздан сөепме шунда юатып кына чыкса да ярар иде. Юк бит, шуңа да күңелемдә әлеге дә баягы, мөгаен, куркытылгандыр, дигән уй ныгып калды. Юкса, өмет тулы күзләребезгә күтәрелеп карарга да кыймыйча, бер кәлимә җылы сүз дә әйтмичә, бездән качып йөрмәс иде. Ходай каршысында ни дип җавап бирде икән ул мескен гөнаһлы җан? Шәт, иншаллаһ, Ходай Тәгалә аны үз хөкеме белән хөкем итеп, әтием җанына тынычлык иңдергәндер.

Дәвамы бар ■

АЙДАР ХАФИЗГА 75 ЯШЬ

ЧЫН ИҖАТ КЕШЕСЕ

Юныс Сафиуллин

(«Күңеле изгелеккә тарта» дигән китаптан өзекләр)

Әсәрне башлау бурычы йөкләнгән җөмлә мөһим үзенчәлеккә ия. Язучы кеше аны табар өчен беркайчан да вакытын кызганмый. Айдар Хафизга 75 яшь тулу уңаеннан, китап язуны театр миңа йөкләгәч, мин дә шактый вакытлар эзләдем аны. Инде менә Айдар Хафизның башыннан узган вакыйгаларны, аның үзенчәлекле тормышын, гаять бай иҗатын гәүдәләндерергә бурычлы китапның ничегрәк булырга тиешлеге берникадәр төсмерләнә башлаганда, уй-фикер болытларымны яргалап, күңеле изгелеккә тарта, дигән якты гыйбарә калыкты.

Айдар Хафиз сәнгатьтә мөгез чыгара торган кеше түгел, бер сүз белән әйткәндә, халык күңелендә бакый урын алган Марсель Сәлимҗанов шәкерте. Шул ук вакытта Айдарның Рәфкать Бикчәнтәев шәкерте булуын да онытмавын күрәбез.

Айдар беркайчан да авыл боламыклары шикелле яки шәһәр тузанын һәм газын йотып үскән мутантлар кебек кыланмады, чиратсыз кереп, сәнгатьнең хәзинә казнасыннан әллә ниләр даулап маташмады, режиссура дөньясына аяк баскач та, «минме, мин әле Рәфкать Бикчәнтәев, Марсель Сәлимҗанов кебек остазларымны артта калдырачакмын», дип, шаккатризм алашасына атланып мөгез чыгармады. 1989 елда ук аяк баскан режиссура дөньясында, үзендәге Ходай биргән кысаларны җимерми генә, татар театр сәнгате мирасын аяк астына салып таптамый гына, шуңа үзенең халыкчан эзләнүләрен дә өстәп, милләткә файдалы мәгънәви дөньяга хезмәт итеп килде һәм хәзер дә, шөкер, шул юнәлешкә хыянәт итми.

Айдар үзе: «Татар халкы өчен урынны киләчәктән барлыйк, ә тарих чүплегеннән түгел», – ди! Шуңа да аның турындагы китапның башлам өлеше «Әңгәмәләр яки киләчәккә хатлар» дип аталды.

Китаплар замандашлар өчен генә язылмый, аларда гәүдәләнгән бүгенге тетрәндергеч кичерешләребезнең һәм уй-фикерләребезнең тере сөземтәләре татар тормышын, татарның олы мәдәниятен дәвам итүче яңадан-яңа буын укучыларыбызга да барып ирешер, дигән якты өметтән дә баш ала. Нәкъ шушыны истә тотып, «Айдарның күңеле изгелеккә тарта» дигән шигар астында яралган китапны «Әңгәмәләр яки киләчәккә



«Талак,талак» (Х.Вахит) спектакленнән бер күренеш. Сулдан уңга: Гөләндәм – А.Гайнуллина, Мирсәет – А.Хафиз. 1978 ел

хатлар» дигән башлам астында тәкъдим итәм. Бу алым инде Һади Такташның «Киләчәккә хатлар» кебек күләмле поэмасында һәм аңардан элгәрерәк яшәп киткән башка әдипләрнең дә кайбер әсәрләрендә чагылыш тапкан. Мин исә менә шул «искедән шыткан яңаны» тәмам аягүрә баскан XXI гасырыбызга турылыйм: игътибарлы укучылар Айдар Хафиз китабындагы изгелеккә тартылу шигаренең Такташның шигъри хатларындагы «коммунизм кыры күренә» кебек ясалма байрактан аерылып торуын да төсмерләрләр дип өметләнәм. Әйтик, без киләчәккә юллаган әңгәмә-хатларыбызның эчтәлегенә Такташтан соң килгән катлаулы чорларда яшәгән һәм милли мәдәниятебез өчен барган аяусыз көрәштә иң алгы сафларда атлаган шәхесләрнең ачы һәм татлы, гыйбрәтле тәҗрибәләрен генә кертергә омтылдык.

Китаптагы әңгәмә-хатлар журналга кыскартып бирелә.

Равил Фәйзуллин:

«Без, ягъни менә мин үзем әдәбиятта, Айдар исә театр дөньясында нидер эшләп калырга тиешбез һәм бик тырышсак булдырырбыз, дип инанып яшәүче егетләр идек. Татар театр дөньясы мәшһүрләргә бик бай иде. Казандагы татар мәктәпләре кимегәннән-кимесә дә, әлеге чорны торгынлык еллары дип искә алсак та, нииндидер күңел чаткыларын дөрләтерлек, бигрәк тә татар теленә, яшим! дип тартышырлык ирекле мөмкинлекләр калган иде. Телебезнең авылдагы учаклары тере булуы да – ул чакта сүндереп бетерергә өлгермәгәннәр иде – әлбәттә, безне өмет белән яшәтте.

Айдар белән очрашулар булып торгандыр, әмма чынлап танып, аңа кызыксыну уятырлыгы театр училищесында булды. Алар безне очрашуга чакырганнар иде. Айдар инде бу вакытта армияләрдән әйләнеп кайткан егет. Чын артист булачагы һәр кыланышыннан күренеп торган кыю егет. Айдарны армиягә училищеда ике ел укуга алып киткән булганнар.Чыныгып кайткан. Марсель Сәлимҗанов аны үз курсына алган. Шул очрашудан башланды чын-чынлап аралашуыбыз. Күп түгел иде бит әле Казанда татар телен саклый, үстерергә омтыла торган җирләр: Камал театры, Тукай клубы, театр училищесы, консерватория, югары уку йортларындагы татар бүлекләре, ШТМнар. Менә шулардагы җан азыгы бирүче мизгелләр безне очраштыра иде. Айдар кешеләрне бик җитди, бик таләпчән егет булуы белән дә үзенә тартыр иде. Безне ни берләштерә иде



«Алмазбулат» (Ю.Сафиуллин) спектакленнән бер күренеш.
Сулдан уңга: Вәзир – А.Хафиз, Шымхан – Н.Гарифуллин.

соң, дигәндә, иң беренче урында чын профессионаллар булырга омтылуыбыз, дияр идем. Театр дөньясы гади дөнья түгел. Ул чуп-чуар дөньяда ниләр генә булмас, дисең. Затлы професссионал булып өлгермәсәң, шундый буталчык дөньяда халкыңны алга илтә торган юнәлешне иярли алмас идең! Телебезне, мәдәниятебезне чикләү, кысрыклау отыры көчәя барган заман ласа. Әнә әдәбиятыбызга күкеләр кереп йомырка сала башлады, диючеләр ялгышмый кебек. Җиде ятлар салган йомыркалардан борынлап чыккан ят кошлар оябыздагы үз балаларыбызны төртеп төшермәсме?!

Айдар белән без соңгы 20 елда аеруча якынайдык. Аның иҗатында шаккатризм, үзүзен күрсәтү, ниндидер милләтебезгә хас булмаган, халыкка ят булган алымнар белән мавыгулар юк. Айдар, бүгенге режиссерлардан аермалы буларак, халкыбызның борынгы чорларын да бик яхшы күзаллый. Кара син аның режиссурасында сәхнә күргән «Мөхәммәдьяр»ын! Айдар анда әле шагыйрь Мөхәммәдьяр ролен дә башкарып затлы һәм зыялы артист буларак та ачылган иде.

Моннан утыз еллар элек үк шигырь уку остасы булып танылды ул. Ходай аңа бик матур тавыш биргән, бик килешле кыяфәтне дә жәлләмәгән. Күпләребез коры калган чама хисе дә көчле аңарда. Кайсы халыкның улы икәнен бервакытта да исеннән чыгармый: спектакльләр куйганда да, юбилей кичәләрен мәгънәле итеп оештырганда да татарның изге максатына йөз тота, рухына бага. Шәп артист, ул уйнаган бер генә роль өчен дә оялып утырмыйсың...»

Илфир Якупов, *Г.Камал театры директоры, А.Хафизның шәкерте:*

«2000 нче елны Казан мәдәният һәм сәнгать университеты яңа курс җыйды. Тоташ шатлык булып истә калган еллар бу. Чөнки безнең остазларыбыз төрки театр дөньясында гына түгел, ә чит илләрдә дә танылу алган үз эшләренең чын осталары иде. Әмма бәхетле бу курс шәкертләрен алда бик күп сынаулар көтеп торган икән... Марсель абыйның җитди авырый башлавы курсыбызның нигезен какшатты диимме, һәрхәлдә, аяк астыбызда җир тетри башлагандай тоелды. Дөрес, көчле, бик көчле шәхес буларак, авыруларга бик озак бирешмәде әле ул... Икенче остазыбыз Фәрит Рәфкать улы Бикчәнтәев безне Марсель абыйның үзенә генә тапшырып, яңа курс җыярга ниятләгәч, Марсель абыйга ярдәмче педагог кирәк булды. Марсель абыйда алдан күрү сәләте бар

«Моңлы бер җыр» (Т.Миңнуллин) спектакленнән бер күренеш. Сулдан уңга: Муса Җәлил – Р.Таҗетдин, Ланфредини – А.Хафиз. 1981 ел

иде. Күрәсең, үзенең тиздән бу дөнья белән саубуллашасын сизгәндер, шуңа курсны ышанычлы кулларга калдырып китим дип тырышкандыр. Башта Сезне тәкъдим итте, беренче диплом эшебездән соң, Айдар абыйны да чакырды. Болар, тотынсалар, эшне соңгы ноктасына кадәр илтеп җиткезәчәкләр, дип уйлап эш иткәндер, дип уйлыйм. Чыннан да, Айдар абый безне шундук бер йодрыкка туплады һәм вакытның кадерен белеп, һәммәбез белән дә бик җәһәт кенә, әмма җентекләп тә эшләргә кереште. Ул – бик тәҗрибәле, гаять көчле оештыручы. Безнең әле беренче диплом спектаклебездән соң ук, аны караган белгечләр курсташларыма: бик талантлы курс, барыгыз да үзенчә талантлы дигән сүзләрне ишеттергән иделәр бит, әмма Айдар абый безнең белән ике диплом спектакле чыгарган чорда, иҗат кешесенә талант кына җитмәвен төрле юллар белән төшендерә барды. Курсташларымдагы инфантильлеккә каршы көрәште. «Үз фикерегез булсын, дөньяны иңләрлек үз акылыгаз калыплашсын, дөньяны үзегезчә күрергә өйрәнегез», – дип, шул максатка ничек барырга икәнен төшендерде. Иң мөһиме – татар дөньясының мәгънәви хәятенә алып керде».

Рауза Хәйретдинова: «Беренче тапкыр Айдарны «Һиҗрәт»тә күрдем. Әлеге спектакльдә мин мулланың яшь бикәче Сәрбине уйный идем. Айдар халык күренешенә кергән иде. Башта кыяфәте, хәрәкәтләре үзенә җәлеп итте. Әллә ничегерәк киенсә дә боламык артист түгеллеге, чын герой булырлык артист икәне сизелеп тора иде. Мәйтәм, кыяфәте геройныкы, ә менә күп артистлар бит, үзләре герой булып күренсәләр дә, аларның тавыш яклары бик чамалы. Инде Айдарның сөйли башлавы булды, шигем бетте, күңелемнең түренә үк үтеп керде, йөрәккә май кебек ята торган чын ир-егетләр тавышына ия бит безнең Айдар. Бөтен залны сихерли алырлык көч тә бар бу тавышта, һәр сүзе аңлашылырлык итеп сөйли дә белә ул. Нур өстенә нур, дигәндәй, сөйләм теле дә искиткеч бай һәм камил. Тумышы белән артист! Мин артистларда ясалмалылыкны сөймим. Менә Айдарда ясалмалылыкның эзе дә юк. Аның белән уйнаган рольләремне хәзер дә сагынып искә төшерәм. Миңа инде туксан, ә Айдарга 75 тула кебек. Аһ, ул бит әле режиссер да! Башта аның куйган юбилей кичәләре белән таныштык. Әнә минем

«Хан кызы Турандык» (К.Гоцци) спектакленнән бер күренеш. Рольләрдә – Х.Җәләлов, А.Хафизов һәм И.Әхмәтҗанов. 2012 ел.

юбилей кичәмне гаҗәп зәвыклы итеп куйган иде, бүген дә искә төшереп сөйлиләр. Гаҗәп бит, кайсы гына артистның юбилей кичәсен куярга алынмасын, артистны бөтен тулылыгы белән ача. Чөнки ул сәхнәдә артист буларак та, режиссер буларак та кыланмый. Айдарның бар ягы җитеш булганлыктан бу. Әлегәчә, Айдар куйган «Үзебез сайлаган язмыш»ны искә төшерәм. Анда Миңнурый ролен биргән иде. Ничек аңлашып эшләгән идек... Уртак эшебез зур уңыш китергән иде. Яшә, Айдар, иҗат ит!»

Фәрит Бикчәнтәев, *Г.Камал театрының баш режиссеры:*

«Артистны яратырга ярамый, аны хөрмәт итәргә кирәк. Соңгы елларда Айдар абыйга булган хөрмәтем арта бара. Аның үз гомерендә күп авырлыклар кичергәнен беләм. Шәхси тормышында да, иҗатында да ансат юлдан бармады. Аны озак еллар уйнатмадылар, башка театрга да китеп торды, эстрадада да эшләп алды. Миңа А.Хафизны күбрәк читтән күзәтергә туры килде. Ә минә Марсель абый аңа курсны тапшыргач, игътибарым көчәйде.

Кичәләр оештыруы да күз уңыма минде. Аның тирән белемгә ия кеше икәнлеген ачтым. Татар әдәбиятын бик яхшы белүчеләрдән. Шигырь уку остасы. «Мөхәммәдьяр»ның юбилеен оештырды. Шунда ук аның Мөхәммәдьярны уйнавы да искә төшә. Әйткәнемчә, Айдар абыйга булган хөрмәтем бүген дә үсештә. Кем минә тагын безнең артистларыбыздан, аның яшендәге артистлардан, диюем, интернет, фейсбукларны үзләштереп, шул яңа дөньяны иркенләп файдалана. Инде әнә компьютер белән шахмат уйный башлады. Тагын шунсы гаҗәп, Айдар абый карта уйнамый. Яхшымы ул карта уйнау, әллә начармы – мин инде аларына ук кереп тормыйм, әмма Айдар абыйның илһамлана-илһамлана компьютер белән шахматта көч сынашканын күреп соклануымны гына белдерәм. Айдар абыйның бик оста балыкчы булуын да беләм идем. Шуннан, Айдар Хафиз, бөтен коллективны гаҗәпләндереп, умарталар тота башлады. Һәм, әйтергә кирәк, аның балын татып карауучылар: балы чын, минә дигән бал бирә аның бал кортлары, диләр. Айдар абый хәтта бу гадәти тормышында да яңалыксыз яши алмый. Инде әнә иван-чәйләр үстерү белән дә мавыга башлады. Кыскасы, мин Айдар абыйның, яхшы артист булу өстенә, төпле шәхес булуын да күреп бик шатланам». ■

Республика традицион мәдәниятне үстерү үзәге

Җырлар артыннан илләр гизеп...

(Фольклорчы көндәлегеннән)

Эльмира Каюмова

СЕРГЕЙ РЫБАКОВ ЭЗЕННӘН

Фәнни эшчәнлегем башында гаять кызыклы, истәлекле, шул ук вакытта бик катлаулы сәяхәткә чыгарга туры килде.

Казан дәүләт консерваториясендә укыганда кулыма **«Музыка и песни уральских мусульман, с очерком их быта» (СПб., 1897)** дигән саллы гына китап килеп эләкте. Әлеге хезмәтнең авторы Сергей Рыбаков (1867-1921) – күренекле рус этнографы, фольклорчысы. Ул, XIX гасырның 90 нчы елларында Оренбург һәм Уфа губернасында яшәүче татар, башкорт, нугайбәкләр арасында йөреп, 204 музыкаль үрнәк, тормыш-көнкүреш һәм иҗат турында кыйммәтле язмалар калдырган. Менә С.Рыбаков экспедицияләренең 100 еллыгы уңаеннан миңа аның эзеннән сәяхәткә чыгарга кушканнар да иде инде.

1991 елның август ае. Миңа 22 яшь. Кыз чагым (Бухайрова фамилиясе белән йөрим). Консерваториядән экспедиция оештырылмагач, юлга әтием белән бергә чыктык (туганнарым мине ерак җирләргә ялгыз гына җибәрергә курыкканнар). Алда безне нәрсә көтә – билгесез. Таянырлык бер кешебез дә юк. Милләттәшләребез ярдәменнән калдырмас, дип, Татар иҗтимагый үзәгеннән хат алдык. Өстәвенә – илебездә кискен үзгәреш, ГКЧП барлыкка килде! Әзерләнеп беттек, билетлар алдык. Нишләргә? Башта алган билетларны кире тапшырсак та, аннары барыбер сәяхәткә чыгарга карар кылдык.

20 август (1 нче көн). Казан-Уфа поезды башкалабыздан 19 сәгать 16 минутта кузгалды. Әле 27 сәгать барасы.

21 август (2 нче көн). Эссе. Кояшлы көннәр. Поезд бик әкрен бара, һәрбер багана саен туктый сыман тоела. Бөгелмәдә, мәсәлән, 36 минут туктап торды. Уфага җирле вакыт буенча 22 сәгать 30 минутта килеп төштек. Вокзал халык белән мыжгып беткән, кассалар янына якын килеп тә булмый. Көчкә-көчкә Мәскәү-Костанай поездына билет алдык. Магнитогорскида иртәгә төнлә генә булырбыз. Шуңа күрә җирле милли үзәкнең рәисе Әдһәм Сафинга, каршы алуын сорап, телеграмма сугабыз. Кунарга вокзалда калдык.

22 август (3 нче көн). Йокысыз үткәргән төн хәлебезне алды (бары тик ике сәгать чамасы гына йокы эләкте). Кояш баегач, киң вокзал бинасы нурларга күмелә. Поездларның килүе-китүе турындагы игъланнарның рус телендә генә бирелүенә игътибар итәм. Махсус Уфа-Мәскәү поезды «Прощание славянки» вальсы музыкасы белән

Эльмира Каюмова (Бу-хайрова) җирле музыкантның скрипкасы белән. Ахун авылы. 1991 ел

озатыла. Ярый әле бездә андый очракта милли әсәр – С.Сәйдәшевнең «Совет Армиясе маршы» яңгырый, дип уйлап куям.

Көндез поездга утырып, бераз ял иткәч, дөнья хәлләре белән кызыксынабыз. Күршеләребез арасында – яһүд, молдаван, мари, рус кешеләре. Без юлда йөргәндә хөкүмәткә каршы чуалыш басылган, Б.Пуго үзен атып үтергән, фетнәчеләрне кулга алганнар икәнен белдек.

Төнлә **Магнитогорскида** безне беркем дә каршы алмады. Шәһәрне белмибез, танышларыбыз юк. Вокзал тирәсендәге ял бүлмәләрендә кунарга калдык. Аларны «бүлмә» дип атау шактый шартлы, чөнки стена урынына тукымалар эленгән. Димәк, барлык тавышлар ап-ачык ишетелә. Шуннан тыш, әле «кунакханәнең» хезмәткәрләре, тукыманы аерып, «бүлмә» эчендә нәрсә булганын еш кына тикшерергә яраталар. Әмма мине күбрәк башка нәрсә борчый. Өченче көн үтеп бара, ә мин әле эшкә керешмәдем. Вакыт әрәм үткәнгә эчем поша.

23 август (4 нче көн). Ниһаять, безгә бәхет елмайды. Әти Ә.Сафинны тапты. Безнең килү вакытын бутаганга күрә, бөтен кунакханәләрдә эзләп йөрүләре ачыкланды. Чәчәкләр белән каршы алмакчы булганнар (чынлап та, шиңә башлаган чәчәк бәйләме машина эчендә ята иде).

Әдһәм ага Сафинның үзен яздырдык. Ул 1920 елгы. Тальян гармунында үзе уйный, җырлый. Тавышы көчле. Башкарган җырлар арасында – «Таһир-Зөһрә», «Мачакия». Мача – хәзерге Чиләбе өлкәсендәге авыл, рәсми атамасы – Варна (район үзәге). С.Рыбаковның ноталы җыентыгында «Мачакия» көе сүзләрсез генә урнаштырылган (№20). Ләкин көйләр аерылып тора. Элегрәк Троицк шәһәрендә иҗат иткән данлыклы скрипкачы Гали Гобәйдуллин башкаруында «Мача авылы көе»н тыңласаң, нигездә «Герман көе»н танырга мөмкин.

24 август (5 нче көн). Магнитогорск-Учалы автобусы белән Ахун авылына таба юл алдык. Маршрутыбыз **Верхнеуральск шәһәре** аша үтте (автобус анда 5 минут туктап та торды). 100 ел элек С.Рыбаков биредә 29 көй теркәп калдырган иде. Информантлардан – Әхмәди Алиев (Ахмадей Алеев), базар маклеры, 50 яшь чамасы; Вәли исемле (Валейка) – 21 яшьлек солдат, туйларда гармунда уйнап дан казанган егет. Рус галиме алардан «Казанская», «Оренбургская», «Чистопольская», «Мензелинская», «Ак-

Ахун авылының йорт үрнәге. 1991 ел



ЗАПИСКИ ИМПЕРАТОРСКОЙ АКАДЕМІИ НАУКЪ.
MÉMOIRES
DE
L'ACADÉMIE IMPÉRIALE DES SCIENCES DE ST.-PÉTERSBOURG.
VIII
VIII° SÉRIE.

ПО ИСТОРИКО-ФИЛОЛОГИЧЕСКОМУ ОТДѢЛЕНІЮ.	CLASSE HISTORICO-PHILOLOGIQUE.
Томъ II. № 2.	Tome II. № 2.

С. Г. РЫБАКОВЪ.

МУЗЫКА И ПѢСНИ

УРАЛЬСКИХЪ МУСУЛЬМАНЪ

СЪ ОЧЕРКОМЪ ИХЪ БЫТА.

204 мелодіи съ текстами и русскимъ переводомъ. — Характеристики музыкантовъ и очерки путешествія. — Два приложенія.

Съ картою Уфимской и Оренбургской губерній и портретомъ башкира-музыканта.

(Доложено въ засѣданіи Историко-филологическаго отдѣленія 9 ноября 1896 г.)

С.-ПЕТЕРБУРГЪ. 1897. ST.-PÉTERSBOURG.

Продается у коммиссіонеровъ Императорской Академіи Наукъ:	Commissionaires de l'Académie Impériale des Sciences:
И. И. Глазунова, М. Эггерса и Комп. и К. Л. Риккера въ С.-Петербургѣ,	J. Glasounof, M. Eggers & Cie. et C. Ricker à St.-Pétersbourg,
Н. П. Карбасникова въ С.-Петерб., Москвѣ и Варшавѣ,	N. Karbasnikof à St.-Pétersbourg, Moscou et Varsovie,
Н. Я. Оглоблина въ С.-Петербургѣ и Кіевѣ,	N. Oglobline à St.-Pétersbourg et Kief,
М. В. Клюкина въ Москвѣ,	M. Klukine à Moscou,
Н. Киммеля въ Ригѣ,	N. Kymmel à Riga,
Фоссъ (Г. Гессель) въ Лейпцигѣ.	Voss' Sortiment (G. Haessel) à Leipzig.

Цѣна: 3 р. — Prix: 7 Mrk. 50 Pf.

С.Г.Рыбаков. «Музыка и песни уральских мусульман, с очерком их быта» (СПб., 1897) китабының титул бите

чарлак», «Бәнем киявем», «Ак чишмә», «Без урамнан үтәек» һ.б. үрнәкләр язып алган иде. Верхнеуральск зур булмаган, бер катлы агач йортлардан торган торак пункт булып чыкты. Шәһәргә кергәнче мөселман зиратын күрергә була. Кызганыч, хәзерге заманда бу шәһәрдә татарлар аз санлы, калганнары да урыслашып бара, дип сөйләделәр.

Ахун авылы Башкортстан Республикасының Учалы районына керә (XIX гасырда – Оренбург губернасының Верхнеуральск өязе). С.Рыбаков мәгълүматлары буенча, авылда халык күп, өч мәчет бар. Минем беренче тәэсирләргә килгәндә, бу – бай, нык тормышлы зур авыл. Керүгә үк, Верхнеуральскидагы шикелле, матур капкалы зират урнашкан. Экспедиция вакытында монда 960 хуҗалык, 22 меңнән артык гектар җир бар иде. Музыка мәктәбе эшли. Мәчетләрдән берсе генә исән калган, анысы да реставрацияләнә иде. Калганнары 1930 нчы елларда җимерелгән булган. Мәчеткә каядыр 10 карт кына йөри, дип зарланганнар.

Ахун авылы безне салкын каршы алды. Без мөрәҗәгать иткән колхоз рәисе булышырга бернинди теләк белдермәде. Урамда очраган кешеләр дә, шикләнеп карап:

– *Сез кайдан? КГБданмы?* – дип сорыйлар иде.

Аңлашыла ки, шомлы чорда нindидер ят кешеләр нәрсәнедер гел сорашып йөриләр. Кулларында – зур күләмле, авыр диктофон. Муеннарында – фотоаппарат.

– *Юк. КГБдан түгел, без – ГКЧПдан!* – дип шаярып җавап кайтара идек.

Халыкның үзаңы да үзенчәлекле, соңгы елларда башкорт мәдәнияте йогынтысы

Нәфисә Мөрсәлимова (1919) – җырчы һәм гармунчы. Ахун авылы. 1991 ел



Мәүлит Хәмидуллин (1927). Ахун авылы. 1991 ел

нык сизелә. Үзләренең тамырлары исә – мишәрләр һәм казан татарлары. Әңгәмә барышында берсе болай дип әйтә:

– *«Уел» – татар халык җыры.*

Икенче җырчы, ризалашмыйча:

– *«Уел» – башкорт халык җыры,* – ди.

Шулай бәхәсләшеп утырганнары әле дә исемдә.

Тагын бер мизгел. Озак итеп бер әбине яздырган чагында ул:

– *Син Уфаның кайсы оешмасыннан әле?* – дип сорады.

– *Апа, мин Уфадан түгел, Казаннан,* – дип җавап бирдем. Моны ишетүгә, дәфтәрен «шап» итеп ябып куйды да:

– *Бетте! Бүтән берни дә сөйләмим,* – диде.

Ахун авылында С.Рыбаков өч музыкаль үрнәк яздырган булган. Шулар арасында бик тә популяр «Җизнәкәй» көе дә бар иде. Әмма бүгенге көндә аны беркем дә башкара алмады (элек булганын гына беләләр, ә җыры истә түгел). Монда таралган халык иҗаты мисаллары арасында оригиналь исемле «Шлапур», «Нимәләтә» көйләре дә очрады. *Нимәләтә* (яисә *нимәлтә*) – туй йоласының бер өлеше. Гадәттә ул хатын-кызлар тарафыннан оештырыла. Мәҗлес ясыйлар. Борын заманда өлкән хатыннар сәке түрендә сыйланып, сөйләшеп утыралар иде. Яшь киленнәр, кызлар чиләк төбе, поднос сугып, кубызга (соңга таба – гармунга) биеп, җырлашып, күңел ачалар иде. Алда җәелгән ашъяулыкка бүләкләр салалар: тукымалар, савыт-саба, пәке, көзге, сабын, чәй, кәнфит, акча һ.б. Нимәлтәне үткәрү максаты – яшь парларга ярдәм итү, тормыш корып җибәрер өчен әйбер җыю (*нимәләтә – әйберләтә*, дигән сүз).

Әйтергә кирәк, С.Рыбаков чорында магнитофоннар әле юк иде. Ул, көйләрне тыңлап, шундук кәгазьгә төшергән. Башка милләт кешесе булганга да, аның нота язмаларына карап, еш кына нинди көй икәнен аңлап булмый. Шунлыктан, бурычларымның берсе – көйләргә идентификация ясау иде. Китапта 6 сан астында урнашкан «Акчарлак» көен җырлап күрсәткәч, Фәридә Тунгушбаева (1937 елгы) үзләренең *урам көе, яшьләр көен* таныды. Бу көй төрле төбәкләрдә яшәүче татарларда киң таралган *авыл көе* булып чыкты. Төрле чыганакларда мин аның дистәләгән вариантларын таптым («Акъяр авылы көе», «Отыз авылы көе», «Түреш авылы көе» һ.б.). Керәшеннәрдә ул *мәҗлес көе*



С.Г.Рыбаков. «Музыка и песни уральских мусульман, с очерком их быта» (СПб., 1897). «Акчарлак» көенең ноталары



Авыл көе. Нигмедзянов М. «Народные песни волжских татар». М., 1982. С.41

функциясендә яши. Рыбаковта «Акчарлак» дигән тагын бер охшаш мисал бар (№56), анысы «Салкын чишмә» исемле озын көйне хәтерләтә.

Ахун авылы Кидыш (Кыйдыш) елгасы буенда җәелгән. Якын-тирәсендә булган тауларның исемнәре җырларда да чагыла:

Кидышкаеның аръягында
Төлке ята чирәмдә.
Гакылын-холкын белмәенчә
Алданмагыз чибәргә.

Ахун тавы аръягында
Кайсы авыл күтүе?
Җан бирүдән авыр була
Аерышып китүе.

Лачбай тавы буйларында
Ак кар ятулары бар.
Яшь күкрәгем эчләрендә
Хәсрәт катулары бар.

Минем информантлар арасында хатын-кызлар да, ирләр дә булды. Җитез һәм сәләтле гармунчы әбиләр – Нәфисә Мөрсәлимова (1919) һәм Сара Кәримова (1911) аеруча истә калды. Ә Сергей Рыбаковның башкаручылары фәкать ирләрдән генә торган, чөнки ул вакытта хатын-кызларга чит ирләр күзенә күренергә ярамый иде.

Гомумән алганда, Ахун авылында музыкаль-шигъри әсәрләр күпләп җыелды. Җирле музейның тарих, этнография, фольклорга кагылышлы материалларга бай булуына да сокландым. Шуңа күрә биредә берничә көн эшләргә туры килде. Сәяхәт вакыты чикле булу сәбәпле, кайтыр чак та җитте. Тагын автобус, поездлар...

С.Рыбаков белән үземне чагыштырып карыйм да, уртаклыклар табам. 1892 елда, иң беренче (сынап карау өчен оештырылган) экспедициягә чыкканда, аңа 24-25 яшь була. Мин дә – шул тирәдә (сентябрь аенда 23 яшь туласы). Рус фольклорчысына да катлаулы эшендә туганнары булышканнар (1894 елгы сәяхәтендә энесе Петр катнаша). Замана авыр, михнәт күп. С.Рыбаков юлга револьвер белән чыга. Безгә, әлбәттә, алай ук куркыныч булмады. Бер гасыр аера бит!

Өйгә кайткач, язмаларны эшкәртеп, фәнни конференциядә чыгыш ясадым. Докладның тезислары (Й.Исәнбәт автордашлыгы белән) басылып ты чыкты*.

Дәвамы бар

*Фотолар **Э.Каюмова** архивыннан алынды.* ■

---

*Бухайрова Э.Р., Исанбет Ю.Н. По следам С.Г.Рыбакова (в преддверии столетия его экспедиций) // Тезисы докладов научной конференции студентов и преподавателей вузов ТССР. – Казань, октябрь-ноябрь 1991 г.: В 2 ч. Казань, 1991. Ч.2. С.42.

Безнең мирас №5 май 2018

СОЛДАТ БАБАЙ МИРГАЗИЗ

Альберт Гаделша

Миргазиз Бәдретдинов

Өч ел инде аяусыз сугыш бара. Өлкәнрәк ирләрне дә күптән инде сугышка алалар. Шулар рәтендә авыл советы рәисе Газинурны да. Озак та үтми, Газинурның гаиләсенә «похоронка» кәгазе зур кайгы алып килә. Газинур, беренче бәрелештә катнашып, көчле яраланып, сугыш кырында соңгы сулышын ала. Шул ук айларда Фатихның да хәбәрсез югалуын хәрби комиссариат авыл советына җиткерә. Яңа авыл советы рәисе, сугыштан бер аягын югалтып кайткан, күрше авыл кешесе Гыйззәт, Бәдретдин абзыйны кәнсәләргә чакыртып, улының билгесез югалуы кәгазен тапшырып, кайгысы белән уртаклаша. Фронтта үзе күргәннәрне сөйләп Бәдретдин абыйның күңелен, авыр кичерешләрен җиңеләйтергә теләп, озак кына сөйләшеп утыралар.

Шулай итеп, Бәдретдин абый белән Шәмсеямал апага бер улларын югалту авыр кайгысы килә. Кулдагы кайсы гына бармакны яраласаң да, кул авыртуын бөтен әгъзалар сизә, сыкрана. Әти-әнигә дә һәр баласын югалту, кайгы алып килә. Өй тулы дүрт ир бала, өч кыз үсәләр.

Төпчек уллары Миргазиз дә егет булып килә. Ул гармунда уйный, өздереп бии дә белә. Сукыр лампа яндырып булса да, үсеп килүче яшьләр клубка җыелалар. Миргазизнең гармунына кушылып җырлыйлар, тик биергә беркем дә батырчылык итми. Кызлар сирәк кенә булса да клубка тавышсыз кино карарга киләләр. Киножурналлар сугыш хәлләрен күрсәтә, андагы коточкыч шартлаулар, үлемнәр һәр яшь

йөрәкне тетрәндерә. Сугышка киткән күп кенә ир-егетләр инде мәңгелек йортка күчеп, «туганнар каберлеге»ннән урын алганнар. Күпме яшь кызлар, яшь аналар, егетләрен, ирләрен югалтып, «солдатка» – тол хатын булып калалар.

Болындагы чирәм-үләннәрне ел саен чапсаң да, алар яз килү белән яңадан калкып чыгалар. Кешеләр дә шулай: яшүсмерләр өлкәннәргә алмашка киләләр, тормышны үзләре «куа» башлыйлар. Ходай Тәгалә кешегә чагыштыру өчен төрле сынаулар биргән. Тормышның, яшәешнең кадерен, тәмен чагыштырып кына беләсең...

***

Мең дә тугыз йөз кырык дүртенче елның ноябрь ае, әле кар төшмәгән, ә шулай да җир катырган. Колхозчылар ындыр табагына җыелган иген көлтәләрен әвендә киптереп сукканнар.

Яшүсмер егетләр басудагы көлтә өемнәрен ындыр табагы янына ташып, әвеннәргә тезеп куялар. Урманнан, әрәмәлекләрдән корыган агачларны кисеп, әвенгә ягарга утын әзерлиләр. Монысы инде ир-егетләр эше. Ә хатын-кызлар әвендә кибеп өлгергән көлтәләрне сүтеп, суккычка салып суктырып, арыш, бодай бөртекләрен агач көрәкләр белән җилләтеп, көшелләргә өяләр.

Яшьләр булган җирдә уен-көлке булмый калмый. Инде үсеп җиткән Миргазиз дә иптәшләреннән бер дә ким түгел. Өйләреннән алып килгән ярык чуен табаны әвен утында кыздырып, бодай бөртекләрен куыра. Беренче булып кызларны сыйлый, үзе дә авыз итеп, яшьтәшләренә дә өлеш чыгара. Куырган бодай шулкадәр тәмле, прәннекләрең бер якта торсын.

Авыл советы рәисе Гыйззәт, кичкырын тарантаска җиккән атка утырып, ындыр табагына килә. Аның белән район үзәгеннән хәрби кеше дә бар. Алар, ындыр хуҗалыгын карап чыккач, ашлык суккычны туктаттырып, эшләүчеләрне көшелләргә утыртып, авылдан өч унҗиде яшьлек егеткә армиягә чакыру кәгазен тапшыра. Шулар арасында Миргазиз дә. Гыйззәт егетләргә, өйләренә кайтып мунча кереп ял иткәч, иртәгесен колхоз идарәсенә килергә куша.

Бәдретдин абый менә инде дүртенче улын сугышка озата. Олысы Фатих хәбәрсез югалса, Ямалетдин белән Зиятдин әле исән-саулар, шулай да яраланып госпитальдә дәваланып, яңадан фронтка алыналар.

Миргазизнең кайтуына мунчалары ягылган. Гыйззәт инде сугышка китүчеләрнең туганнарына алдан хәбәр итеп, мунча ягарга, озату өчен әзерләнергә кушкан була. Миргазиз дә апалары яккан мунчага кереп, иске булса да чиста өс киемен алыштыра. Бәдретдин абзыйның гаиләсе, барысы бергә җыелып, тыйнак кына кичке ашны ашый. Төне буена бишле лампа янып чыга. Барысының да йокысы кача. Бәдретдин абзыйга хис-тойгылары тынычлык бирми.

Сугышка китүче егетләр иртәсен колхоз идарәсенә җыела башлый. Түбән очтан Миргазиз дә гармунда уйнап, әтисе, әнисе, апалары белән килә. Миргазиз, халык көе – «Саубуллашу»ны барлык сәләтен биреп тырышып уйнап, гармунын әтисенә тапшыра.

– Ярар, улым, исән-сау әйләнеп кайткач, «Очрашу» көен уйнарсың, – дип, Бәдретдин абзый төпчеген кочаклый, еламаска тырышып, күз яше аша елмая. Хатын-кызлар да күз яшьләрен, башъяулыгы чите белән корытып, исән-сау кайтуларын теләп, сугышта сак-уяу булырга киңәшләр бирәләр.

Шәмсеямал апа да төпчеген кочып:

– Улым, үзеңне сакла, – ди.

Колхозның бердәнбер айгыры, авыл советы рәисе җигеп йөри торган тарантаска өч «никрут» егетне утыртып, район үзәгенә юл тота. Никрутларны озатучы, дилбегә

тотучы малай Шәфигулла, кызыгып, эх, миңа да унҗиде тулган булса, сезнең белән китәр идем, ди.

– Син, Шәфик, ашыкма, тагын ике елдан солдат булырсың, сугыш инде беткән булыр, – дип, Хәмит малайның аркасына дусларча сугып куя.

– Шулай шул, сугыш беткән була шул. Ә минем теге фашистларны кырып саласым килә.

Барысы да көлешәләр.

– Әйдә алайса безнең белән. Мин сиңа үземнең мылтыкны биреп торырмын, – дип, Камалетдин шаркылдап көлә.

Миргазиз сүзгә катнашмый, үз уйларына чумып бара.

Ниһаять, район үзәгенә килеп җитеп, хәрби комиссариат янына туктыйлар. Инде күп кенә авыллардан булачак солдатлар килеп өлгергән.

Хәрби комиссар – хәзергечә әйтсәк, военком, хезмәткә алынучы яшьләрне бер рәткә тезеп, исемлек буенча барлап, һәрберенең йөзенә карап чыккач, кемнең нинди машинага утырасын әйтеп, боерык бирә.

Биштәрләрен иңнәренә аскан яшьләр, иске полуторка машиналарына утырышып, Казанга юл тота.

Казанда Татвоенкомат Сукно бистәсендәге патша Петр I төзеткән сукно фабрикасы бинасына урнашкан. Сугышка китүчеләрне республика буенча шунда җыеп, төрле хәрби частьларга озаталар.

Миргазиз белән районлашларын зур, ике катлы бинага кертеп, шунда төн кундырып, иртәгесен Ульяновск шәһәрендәге «учебный пункт»ка озатырга тиешләр.

Стеналар буйлап сәкеләр тезелеп киткән. Урамнан керүгә, борынга тынчу һава бәрелә. Бөтен сәкеләр дә некрутлар белән тулган, идәндә утырырга гына урыннар калган.

Мескен авыл егетләренә идәндә чүгәләп утырып таң аттырасы гына кала. Сәкедә ятучылар барысы да русча сөйләшәләр. Бәдрәфкә дә чиратлашып баралар, урыннарын саклыйлар.

Миргазиз дә, авылдашлары белән бергәрәк булып, тынычрак җиргә чүгәли. Кичен капчыкларындагы ризыкларын алып, тамак ялгарга булалар. Һәр егетнең капчыгында түгәрәк ипи, пешкән дистәләгән йомырка, бәрәңге, шешә белән сөт. Шуңа өстәп, Миргазизгә дә өйдәгеләр пешкән ярты тавыкны гәҗиткә төреп тыкканнар.

Сәкедә ятучы таза гына гәүдәле бер рус егете кызмачарак булып, ярымшаярып:

– Эй, чеплашка, курицей поделись, давно кур не ел, – дип, тешләрен ыржайтып көлеп, кулын суза.

Миргазиз аны рәнҗетеп эндәшүләрен дә, нәрсә сораганнарын да аңламый, ашавын дәвам итә. Авылдашы Кыяметдин Миргазизгә шыпырт кына: «Кордаш, карале, теге теш ыржайтучы урыс синнән тавык ите сорый. Ничек уйлыйсың?» – ди.

Миргазиз уйланып тормый, тавыкның ботын өзеп алып рус егетенә суза. Тегесе:

– Смотри, какой добрый татарин, – дип шаркылдап көлеп, тавык ботын алып ашый ук башлый.

– Вкусно, рахмат малай, ты добрый пацан? – дип рәхмәтен кызганмый.

Шулай таш идәнгә чүгәләп утырып таң аттыралар. Иртән сәгать җидедә, булачак солдатларны ишегалдына тезеп, фамилияләрен кычкырып барлап чыккач, колоннага тезелешеп, тимер юл вокзалына юлга чыгалар. Тимер юл вокзалы артындагы иң соңгы рәттәге юлга товар ташый торган вагоннар тезелеп, үзенең булачак юлчыларына ишекләрен киң ачып тора.

Призывникларны ротага, взводларга бүлеп, вагоннарга утырталар. Һәр взводның

Миргазиз Бәдретдинов (рәсемдә сулда) сугышчан дусты белән

командиры старшина булып, үзенә буйсынган призывникларга ике катлы сәндерәләрдән урын алырга боера. Әзерләп куйган тимер мичне ягып, вагонны җылыттыралар.

Җитезрәк малайлар икенче кат сәндерәдән урын алалар, чөнки анда җылырак. Җылы һава өскә күтәрелә бит. Миргазизләргә исә беренче кат сәндерә кала. Караңгы төшә башлагач, ниһаять, поезд кузгалып китә һәм Ульяновск шәһәренә юл тота.

Товар вагоннарының ишекләре ябык, җылыны сакларга кирәк, вагон эчен ягылган мичтән төшкән яктылык кына яктырта. Урыс егетләре бераз «төшергәннәр» булса кирәк, үзләренең сагышлы җырларын сузалар. Ә безнең татар егетләре, оялыпмы, куркыпмы, сүзсез баралар. Караңгыда күз яшьләре күренми бит, бераз «балавыз сыгып» алсаң да оят түгел. Рәтле-башлы русча аңламагач, бернинди дә яңалыкны белмиләр.

Призывниклар төялгән поезд Ульяновск шәһәренә икенче көнне төштән соң гына килеп җитеп, аларны Инза шәһәре янындагы уку пунктына җәяү озаталар. Хәрби уку частена килеп җиткәнче өс-башлары тәмам чыланып бетеп, чыпылдап торган юлдан атлыйлар. Аларны турыдан мунчага җибәреп, һәрберсен фельдшер күздән узгарып, чәчләрен кыркытып мунчада юындыралар.

Авыл егетләренә сәер: берничә дистә ир-егет салкын мунчада юына. Ләгәннәр тавышы белән бер сүзне дә ишетеп-аңлап булмый. Ярый әле кайнар су бар, бармак башы кадәрле генә булса да кер сабыны, мунчала белән аркаларны ышкып юарга була. Мунчадан чыгуга, старшина ике ярдәмче солдат һәр солдатка өр-яңа эчке кием һәм хәрби формалар биреп тора. Миргазизгә эчке кием таман гына булса да, хәрби форма мулрак булып асылынып тора.

Старшина, мыек астыннан гына елмаеп, ярдәмчеләренә кечерәк үлчәмле форма сайлап бирергә куша. Сайлый торгач, Миргазиз үзенә яраклысын табып киенә.

Старшина аңа:

– Солдат, запомни! Твой размер второй, а обувь бери тридцать девятый! – ди.

Шулай итеп, старшина сүзе гомерлеккә хәтергә кереп кала. Армиядә җиде ел хезмәт иткәндә күп мәртәбәләр яңа форма кияргә туры килә аңа. Шулвакытларда уйлап та тормыйча: «Мне второй размер, тридцать девятый ботинка», – дип әйтергә күнегә.

Аякка чолгау урау – үзе бер бәла. Чолгауны тезгә кадәр урарга, ботинканың бауларын кыска вакытта бәйләп, сафка басарга кирәк. Чолгауны дөрес урамасаң, аяк бармакларың кысылып, сыдырылып җәрәхәтләнә. Аның өчен старшина бер наряд «бүләк итә».

Мунчадан соң казармага баргач, һәр солдатка ятак-койка бирелә. Миргазизгә урын икенче каттан туры килә. Салам матрас, салам мендәр, юка гына одеал. Икенче катта йоклау җылы булса да, һавасы тынчуга күрә, чолгау исе борыннарны ярып керә. Бер – рәхәттә, бер – михнәттә, дигәндәй, язмыш...

Мунчага тезелеп барып, аннан тезелешеп казармаларга кайту, ашханәгә юл тоту өлкән сержант, йә старшина боерыгы буенча гына үтәлә.

Беренче мәртәбә чын сугыш мылтыгын кулга алып, үзең сүтеп, үзең җыю кызыклы да, җаваплы да эш. Призывникларны икешәр сәгать вак таш җәйгән мәйданда сафта

йөрергә өйрәтү, винтовкага штык куеп, салам капчыкларга һөҗүм итү, граната атарга өйрәнү кебек күнегүләр бер айлап баргач, яшь солдатларның «краткий курс молодого бойца» тәмамланып, фронтка, хәрби частьларга җибәрү вакыты җитә. Авылдашлар гел бергә булып, аларны чит милләт яшьләре кыерсытырга батырчылык итми.

Ашханәдә – озын, ун кешелек өстәлләр. Өстәлнең ике ягында да бишәр солдат утыра. Һәр солдатның үз урыны билгеләнеп, Миргазизгә соңгы урын, кәстрүл белән аш куела торган җир туры килә.

Кем кәстрүл янында – шуңа аш бүләргә туры килә. Бу «мактаулы» эштән баш тартмыйча, Миргазиз һәр өстәлдәшенә дә тигез итеп аш сала, второйны да хәрәмсез бүлә. Аның гаделлеге барсына да ошый. Шулай итеп, ул курслар тәмамланганчы «мактаулы» бурыч үти. Өр-яңа солдат формасы, күнегүләр өйрәнү вакытында таушала да башлый. Яшьләр бер ай эчендә үзләрен солдат формасын гомер буе киеп йөргәндәй хис итеп, пөхтәлекне сакларга тырышалар.

Азмы-күпме сафта йөрергә, винтовкадан атарга өйрәнгән солдатларны фронтка җибәрү вакыты җитә. Укыту пункты җитәкчесе, өлкән яшьтәге майор курсларны тәмамлаучылардан тантаналы рәвештә хәрби ант кабул иттереп, аларга фашист илбасарларын үзләренең илендә тар-мар итеп исән-сау кайтуларын тели.

Казармада соңгы кичне йоклаганда кемдер Миргазиз белән авылдашы Хәмитнең ботинкаларының шнурын сүтеп ала.

Шнурсыз ботинка киеп ерак китеп булмый. Икесе дә, елардай булып, старшинага зарланалар. Старшина тыныч кына:

– Что ты будешь делать, в каждом наборе шнурки пропадают, – дип, каптеркадан яңа шнурларны кулларына тоттырып:

– Береги, солдат, иначе без шнурка пропадешь, – дип, ботинкаларын бәйләтеп, стройга басарга куша.

Һәр солдат үзенең капчыгын барлый, солдат кенәгәләрен күкрәк кесәләренә салып төймәли.

Курсантларга өч көнлек сухой паек бирелеп, капчыкларга салынгач, тезелешеп тимер юл вокзалына юл тоталар. Атаклы товар вагоннарына яшь солдатларны төяп, поездлар билгесез тормыш чоңгылына алып китә. Фронтка баручы поездлар, озак тукталып тормыйлар. Аларга яшел юл ачык. Юлда күренеп калган авыллар, шәһәрләр янып, җимерелеп беткәннәр.

Миргазиз Польша чиген йоклап уздыра. Шау-шу килеп төрткәләшүгә уянса, Пиляу дигән шәһәрчеккә килеп җиткәннәр икән. Хезмәт итәсе хәрби частьның командиры яшь солдатларны кабул итәргә дип тезеп бастыргач, аларның кайда хезмәт итәчәкләрен әйтеп, старшинага вокзалдан хәрби часть урнашкан шәһәр читендәге, ике-өч катлы биналарга алып барырга, дип боерык бирә.

Миргазиз танкларны утка тота торган дивизиягә эләгә. Икенче көнне үк пушкаларны өйрәнү башлана. Авыл малаеның акылына сыймаслык хәл – пушкалар янында солдатлар кырмыскалар кебек кайнашалар. Ике солдат көч куеп күтәрә торган снарядларны агач тартмадан алып, пушка көпшәсенә салырга кирәк.

Миргазизнең буена карап, аны наводчик-төзәүче итеп өйрәтә башлыйлар. Командир ялгышмый. Миргазиз, техниканы тиз үзләштереп, ярыйсы гына туры төзәп, уңышлы ата башлый.

Яшь солдатларны, пушкалардан атарга, техника янында хезмәт итәргә өйрәнгәч, Дания илендәге Брондхольем утравына җибәрәләр. Ул – диңгез капкасы буларак әһәмиятле урын.

Менә ул диңгез уртасындагы кечкенә утрау. Немецлар аны сугышып ала алмаслык

кирмәнгә әверелдергән булсалар да, чолганыштан калудан куркып, утрауны калдырганнар. Хәрби корылмаларны шартлатканнар, яшерен миналар куйганнар. Саперлар бөтен утрауны тикшереп, яшерен миналарны шартлатып чыккач, безнекеләр дошман корабларына капка-тозак ясап, еракка ята торган пушкаларын әзерләп куялар.

Сугышның хәлиткеч вакыты коры җиргә күчә, немец хәрби кораблары инде көчсезләнеп, активлык күрсәтми башлыйлар.

Сугыш вакытында һәр минут, һәр сәгать эчендә көтелмәгән хәлләр була. Утрауны төзекләндереп бетерүгә, аны Америка армиясенә бирергә боерык килеп, Миргазизләрне, инде сугышып алынган Германия шәһәре Дрезденга күчерәләр.

Дрезденны американлылар бик каты бомбага тотканнар. Шәһәр ярым җимерек хәлдә.

Каты сугышлар инде Берлинда бара. Яшь солдатлардан торган резерв – хәрби частьлар сугышка керергә әзер булып боерык көтәләр. Аларны, сугыш беткәч, герман җирендә хезмәт итәргә калдырачаклар.

Халык зарыгып көтеп алган Җиңү көне – 1945 елның 9 мае килеп җитә.

Хәрби частьларда шатлык: солдатларга бәйрәм ашы әзерләнеп, «Наркомовский» йөзәр грамм белән сыйланалар. Германиянең дә күп шәһәрләре җимерек хәлдә. Совет армиясенең көчлелеген таныту теләге белән, сугышта катнашкан союздаш илләрнең журналистлары, хәрби җитәкчеләре дә күрсен өчен, совет хәрби частьлары Германиянең төрле шәһәрләренә күченеп йөри. Ул хәрби хәйлә шулай да күзәтүчеләргә зур тәэсир ясый. Советлар Союзының «бетмәс-төкәнмәс» армиясе, хәрби техникасы барлыгына ишарә ясау була бу.

Авылда туып үскән татар баласы җиңүчеләр сафында Германияне аркылыга-буйга йөреп чыга. Атаклы Дрезден музеен саклауда катнаша. Командирлар Миргазизнең тырышлыгын, тәртиплелеген күреп, аны сержантлар әзерли торган мәктәпкә укырга җибәрәләр. Сугышның бөтен авырлыгын үз җилкәләрендә алып барган офицерлар кече командирлар – алмашка яшь кадрлар әзерли.

Өч айлык сержантлар мәктәбен тәмамлап, имтиханнар тоткач, аңа кече сержант дәрәҗәсе бирелә. Миргазизнең бәхете алдан йөгерә – аны аэродромда хезмәт итәргә билгелиләр.

Көнчыгышта Япония инде Совет армиясе белән сугыша. Миргазиз хезмәт иткән авиаполк илебезнең көнчыгышына – сугышка китәргә җыена башлый. Тимер юл вагоннарына самолетларны, ремонт ясау җиһазларын ашыгыч рәвештә төйиләр. Юлга кузгалырга боерык көтәләр.

Авиаполк, берничә тәүлек вагоннарга төялгән хәлдә булып, яңадан аэродромга кайтырга, дигән боерык ала.

Совет армиясе Японияенең Квантун армиясен аз көч белән кыска вакытта җиңеп, Икенче Бөтендөнья сугышы тәмамлануга якынлаша. Американлыларның Японияне атом бомбасына тоту хәбәре тиз тарала. Авиаполк яңадан үзләренең аэродромына – Фалькенберг шәһәре тирәсенә урнашкан җиргә кире кайтып, японнар белән сугышка катнашмый кала. Инде самолетларда күнегүләр ясар өчен генә һавага күтәреләләр. Ниһаять, Германия, сугышта катнашкан союздаш илләргә бүленеп, тынычлык урнаша башлый.

Сугыш тәмамлангач, чит илләрдә хезмәт итүче яшьләргә – сугышта катнашмаганнарга җиде ел хезмәт итү мәҗбүри була. Миргазизнең инде алты ел тырышып хезмәт итүен, спорт белән шөгыльләнүен искә алып, мең дә тугыз йөз илле беренче елда отпускага җибәрәләр. Бу шатлыкка өстәлеп, кече сержант Миргазизгә моторист булып яхшы хезмәт күрсәтүе өчен, бер мең тәңкә акча да түләнә.

Бер мең тәңкә – Миргазиз өчен зур күләмле акча. Егетнең күңеле авылда. Әзерләп

Миргазиз ага гаиләсе белән

куелган чемоданнарга бирәсе бүләкләр пөхтәләп салынган. Отпускага җибәрүләре турында авылга инде күптән хатта язылып хәбәр ителгән була.

***

Алты ел буена сагынып төшләргә кергән туганнар белән күрешү – Балык Бистәсе районының Зәңгәрле авылына кайту бәхете шулкадәр шатлыклы хисләр уята.

Миргазиз, туган-тумачалары, күршеләре белән күрешкәч, абыйлары, апалары, һәм әнисе белән бергә, әтиләре Бәдретдин абзый каберенә барып, аның рухына багышлап дога укый.

Ун көн отпуск бер көн кебек тиз узып, китәр көн дә килеп җитә. Кич буе сөйләшер сүзләре бетми. Миргазизнең армиядән бер елдан соң кайтуын көтәргә, дип, Мәрьям белән сүз куешалар.

***

Озакка сузылган җиде ел армия хезмәте артта калып Миргазиз туган авылына, кадерле әнисе, туган-тумачалары, булачак кәләше Мәрьям янына ашыгып кайта.

Яңа елга туй ясыйлар. Әниләре Шәмсеямал апа җыеп куйган солдат акчасына яшь гаиләгә авылда бушап калган йортны сатып алалар. Яшьләрнең үз тормышы башлана. Миргазиз җиң сызганып колхоз эшенә «җигелә». Коммунистлар партиясенә алына. Тракторда, комбайнда ару-талуны белми эшли.

Дүрт бала үстерәләр. Мария-Мәрьям апа, пенсиягә чыкканчы укытып ялга чыккач, авырып, август аенда вафат була. Миргазиз ага туксан беренче яше белән барса да*, әле һаман да үзен солдат итеп хис итә. Еш кына, яңадан армиягә алуларын, самолетлар төзәтүен төшендә күрә.

***

Кызы Рузалия ишекне тышкы яктан бикләгәч, карт, урыныннан торып тәрәзә янына килеп, кызының китеп баруын карап кала.

Ул яңадан берүзе. Калган гомерен ялгызы кыскарта. Өлкәннәрнең сагышын, юксынуын яшьләр аңлап бетерми шул.

Туксанны узгач та яшисе, сөясе-сөеләсе килә икән... ■

*Миргазиз ага Бәдретдинов 2018 елның мартында мәңгелек йортка күчте. – *Ред.*

Безнең мирас №5 май 2018

ӘТИЕМНЕҢ КҮРГӘННӘРЕ

Харис Закиров

Өй архивында саклануччы фотокарточкалар арасында икесе башкалардан аерылып тора. Аларны кулга алгач, озак кына карап торам. Чөнки икесендә дә минем иң якын кешем – әтием Закиров Миңнеәхмәт Әхмәтзакир улының сурәте бар. Берсенең артына, әти кулы белән, 1912 елда Казан шәһәрендә, икенчесенекенә 1915 елның апрелендә Голициядә Милләтләр сугышы вакытында төшелде, диеп язылган. Бүгенге көн сөйләме белән әйткәндә – Беренче Бөтендөнья сугышы вакытында булып чыга инде.



Армиядә хезмәт иткән вакыт. Миңнеәхмәт Закиров, Хаҗи Галиев (Чөшледән), Низамби Гарифуллин (Барҗыдан). Казан. 1912 ел

Беренче фотода әтидән тыш (уңнан сулга) тагы ике кеше бар. Утырып төшкәне – Яңа Аккуҗа (Иске Аккуҗадан күчкән) авылы егете Галиев Хаҗи, аның белән рәттән Гарифуллин Низамби – Барҗы авылыннан, дип язылган. Бу авыллар Әгерҗе районына караган авыллар иде. Кызганыч, Иске Аккуҗа белән Барҗы, Түбән Кама ГЭСы төзелә, дип күчерелүгә – чынлыкта таралып бетүгә дучар булды. Шөкер, Яңа Аккуҗа исән. Ул күп еллар Чөшле дигән исем белән йөрде. Күчә торган урынны карарга баргач, шөшле табылган. Күрәсең, берәрсе чабата йә

пичтәр (балык сала торган) үрергә юкә кайрысына урманга килгән булгандыр һәм шунда шөшлесен югалткандыр инде.

Исән чакта шушы фотоларга карагач, әти аларга мөнәсәбәтле рәвештә нинди дә булса истәлек-вакыйганы искә ала иде. Төрле эпизодлардан торган ул вакыйгалар, иҗтимагый-сәяси күзлектән караганда, бәлки, «ах-ух» итәрлек тә түгелдер, ләкин аларда шул чорның яшәеш рәвеше чагылмый калмый бит инде.

Беренче Бөтендөнья сугышы башлангач, солдатларны фронтка озаталар. Әлбәттә, әти дә алар арасында. Сугыш башында ук ул Георгий тәресе белән бүләкләнә. «Атышып ятканда безнекеләрнең снарядлары бетте. Туп янына узарга мөмкинлек тә, узарга тырышучы да юк. Сугыш әрәмәлек янында бара иде. Мин бер юкә агачының кайрысын салдырып алдым да, аңа ике снаряд бәйләп, җилкәмә киеп, шуыша-шуыша шул снарядларны тупчыларга илттем. Шул гамәлем өчен Георгий тәресе белән бүләкләүгә тәкъдим иткәннәр булып чыкты», – дип искә ала иде әти.

Күпмедер вакыт фронтта булганнан соң, әти әсирлеккә алына. «Өч йөздән артык кеше идек. Заманы өчен яхшы ук коралланган солдатлар. Безне камап алдылар, Австро-Венгриягә алып киттеләр. Юлда барганда, җаен туры китереп, Георгий тәресен атып бәрдем. Күреп алсалар, кирәксә-кирәкмәсә бәйләнерләр, дип уйладым», – дип сөйли иде ул.

Әсирлек газапларын өч ел кичергән алар. Өч ел эчендә өч тапкыр качканнар. Икесендә тотып алганнар. Өченче тапкырында Ватанга кайтып җиткәннәр. Араларында бер себер урысы булган. Ул кеше йолдызларны көндез дә күргән икән. Юнәлешне шул кеше күрсәтеп барган.

– Тотылуыгыз ничек булды соң?

– Без көн буе урманда качып ята, төн буе үзебезнең чиккә таба атлый-чаба кайта идек. Урманда яткан чак. Овчаркалар белән якынаялар. Этләр өргән тавышлар гына түгел, арттан куучыларның кычкырышканы да ишетелә башлады. Урманга якын гына басуда бер венгр хатыны нидер эшләп ята иде. Полицейскийлар безнең турында сорагандыр инде. Ул: «Гай, гай» – дия-дия безнең якка күрсәтте. «Гай» сүзе венгрча урман дигәнне аңлаткан булып чыга инде.

Бу – икенче тапкыр качуыбыз иде. Тотып алгач суд булды. Безне шпион дип уйладылар, төрмәгә яптылар. Көнгә бер стакан су, бер кашык он бирәләр иде. Шуны суда болгатып эчтек. Бик нык ябыктык, хәлсезләндек. Шпион түгеллегебезне ачыклагач, янә суд булды. Безне төрмәдән чыгардылар. Алты ай утырып чыкканда туры атларлык хәл юк иде, стенага тотына-тотына гына атладык.

– Ә ничек хәлгә кердегез соң?

– Янә алпавытка беркеттеләр. Аның хуҗалыгында нинди эш булса, шуны башкардык. Тырышып эшләгәнне күргәч, ипиен дә, сөтен дә бирде. Аш та әләккәли иде. Шулай адәм рәтенә кердек. Алпавыт хәтта миңа кызына өйләнергә тәкъдим ясады. «Мин бит магометанин, башка диндәге кешегә өйләнү ярамас», – дигәч, ул темага башка сүз кузгалтмады. Фамилиямне генә Закировтан Секиров ясады. Сөтне дә чүлмәге белән бирә. Калачын да җәлләми ашата иде.

– Әйбәт эшләгәнеңне күреп торганга шулай юмарт булгандыр ул.

– Әйе, ашлыгын да суктык, печәнен дә чаптык. Ул алпавытның килене бар иде. Эшкә бик уңган хатын иде. Шулай берсендә күмәкләшеп печән чабабыз. Килене гел алдан бара. Пакусны киң итеп ала да, безне берничә метр артта калдырып, печән чаба. Безгә – ирләргә оят. Уйлаштык та бер җаен китереп тегенең чалгысын «юешләдек». Арадан берсе шулай итәргә киңәш бирде. Чыннан да киленнең чалгысы үтмәсләнде. Хәзер инде без аннан калышмыйбыз, эзенә басып барабыз. Алпавыт – аның биатасы була инде

ул – чалгыны үткенләп тә карады. Юк, элекке кебек чаба алмый килен. Шуннан соң биата, чалгыны сабыннан салдырды да, әрмәлеккә атып бәрде. Аларда сапка утырту бездәге кебек божра белән түгел, гайка ярдәмендә башкарыла икән.

– Шундыйрак хәйләгә корылган башка гамәлләр эшләмәдегезме? Хәйләсез – дөнья файдасыз, диләр бит.

– Алпавытта мин бер татар, тагын өч урыс идек. Иртән барыбыз да бер чама. Ә кичке якка таба урыслар исерә төшкән кебек йөриләр. Бу хәл алпавытны да, мине дә гаҗәпләндерә. Шуннан сиздерми генә күзәтә башладык.

Хуҗаның утарында зур бер чан бар, ул анда сыра кайната иде. Теге урыслар, арыш саламының юанрак өлешен бер-берсенә ялгап, көпшә сыман нәрсә ясыйлар да шуны чанга тыгалар икән. Чан кырыеннан үткән-сүткәндә яки берәр эш белән шөгыльләнгәндә шул салам көпшә аша сыраны суыралар. Көн буена шулай итә торгач, сыра градусы үзен сиздерә икән. Бу хәл ни белән беткәндер – белмим. Миңа өченче тапкырын шушы алпавыт утарыннан качып китәргә туры килде. Һәм без бу юлы тотылмыйча илгә кайтып җитә алдык.

– Мәскәү сезне ничек каршы алды?

– Бу – 1918 ел иде. Россиядә инде революция булган. Безнең өчен ул яңалык иде. Дүрт хәрби комиссариат аша үттем. Соңгысы – Алабуга шәһәрендә. Беркайда да бәйләнеп теңкәгә тимәделәр. Кергән һәр военкоматта солдат киеме бирделәр. Анысы да ярап куйды. Арткан киемне сата бардык, тамак ялгарга ярады.

– Илгә кайткач, әсирлектә булган өчен эзәрлекләмәделәрме соң? Әнә Бөек Ватан сугышында әсирлектә булганнарны Сталин режимы тагын тәмуг аша үткәргән бит.

– Юк, миңа беркем дә бәйләнмәде. Шулай әйтергә яраса, әсирлектә булу хәтта мине үлемнән дә коткарды. Безнең нәсел гомер-гомердән паром тоткан. Иж елгасын кичү өчен, күпер салынганчы, кешеләрне, атлыларны, хәтта сыер һәм сарык көтүләрен Иж аша чыгару өчен паромнан файдаланганнар. Мин дә паромчы булып эшләдем әле. Шулай беркөнне дежурда торам. Ташкын булып Колчак солдатлары килеп тулды. Аларга да елга аша чыгарга кирәк. Күпер әле салынмаган. Кемдер көтә, кемдер елганы паром белән кичә. Менә яр буена, этен ияртеп, акларның офицеры килеп туктады. Офицер үзе ычкындырганмы, әллә эт бәйдән үзе ычкынганмы – яр буйлап чабып китте. Хуҗасы: «Ленин, Ленин, иди сюда, нам на тот берег перейти надо», – дип чакырып карый, ләкин эте килми, чабып йөрүен белә. Миңа Ленин исеме таныш, әсирлектән кайтканда революция җитәкчесе икәнен Мәскәүдә аңлаттылар. Түзмәдем, эт хуҗасына: «Господин офицер, эта же собака, а Вы называете ее Лениным», – дидем русчалатып.

– Ах ты, красная сволочь! Я покажу тебе Ленина, – дип җикерде дә, кобурасыннан пистолетын тартып чыгарды һәм миңа таба төзи башлады. Шул вакыт яр өстендә басып торган күрше карты: «Ваше благородие, он ни Ленина, ни Троцкого не знает, он только что вернулся с плена, – дигәнгә генә офицер пистолетының тәтесенә басмый калды.

– Где служил, где попал в плен?

– На Украине. В Галиции попал в плен. В Австро-Венгрии держали нас. Работали у помещика. Три раза сбежал, только последний раз не могли поймать. В восемнадцатом году пришел домой, – дип җавап бирдем.

– Твое счастье, правду говоришь, – дип, пистолетын кобурасына тыгып куйды.

Әтинең шушы сүзләрен ишеткәч: «Ә ничек пленга алдылар сезне?» – дигәнемне сизми дә калдым.

– Безнең командир сатлыкҗан булган. Бер генә тапкыр да атып карамадык. Киресенчә, «Атмаска!» – дигән приказ булды. Шулай җиңел генә әсир иттеләр безне. Меңләгән Россия солдатының әсирлектә булуын белгәндер ул акларның офицеры, шуңа күрә миңа атмый калгандыр.

Милләтләр сугышы вакытында – Галиция дигән җирдә.
Уңда – Миңнеәхмәт Әхмәтзакир улы Закиров.
1915 ел, апрель

– Колчак гаскәренең Ижны кичүе ничек бетте соң?

– Аклар ул көнне авылда кундылар. Кемдә тана, кемдә сарык бар – чалдырттылар, ашлар пешерттеләр. Ул арада Иж аша күпер салдырттылар. Таң атыр-атмас юлга кузгалдылар, чөнки авылга таба ата башладылар. Калкулыкта урнашкан Бетсемәс дигән авыл ягыннан: «Кызыллар килә!» – дигән хәбәр таралды. Аклар, үзләре салган күпер аша чыккач, аны ут төртеп яндырды.

– Димәк, сез кызылларны да күрдегез?

– Аклар чигенүгә, кызыллар килеп тулды. Дөресрәге, кызыллар акларны эзәрлекләп киләләр иде. Аларга да Ижны кичәргә кирәк. Кызыллар да күпер салды. Ашап-эчеп алырга да онытмадылар. Ризык әзерләтеп, тамак туйдырдылар. Кергән бер өйдә: «Сезгә яңа тормыш алып киләбез, байларга хезмәт итү булмаячак», – дип сөйләнделәр.

– Бу вакытта авыл халкы үзен ничек тотты?

– Атышлар башлангач, кем кайда кача алды – шунда яшеренде. Әнә хәзер «Качкан дугай» дип атала торган урынның исеме шушы вакыйгалар белән бәйле. Иж елгасының шундагы яры буенда, текә җирендә ядрәләрдән сакландылар. Кызыллар акларны җиңгәч, Совет власте урнашты. Мине авыл Советында эшләргә билгеләделәр. Тугыз ел буе шунда эшләдем. Ул вакытта председатель дә, секретарь да бер генә кешегә йөкләнгән иде.

Беркөнне бәйләм-бәйләм белән Ленин томнары килә, икенче көнне – Троцкий томнары.

Авылда аларны кем укысын инде. Шунда аунап йөри-йөри югалып бетте алар.

Минем әти белән сөйләшү әнә шулайрак булды. Яше илледән артып китү сәбәпле, аны Бөек Ватан сугышына алмаганнар. 1890 елда туган әти, 90 яшен тутырырга дүрт ел кала, 1976 нчы елда бакыйлыкка күчте. ■

Безнең мирас №5 май 2018

МИЛЛИЯТ СҮЗЛЕГЕ

Адлер Тимергалин

УҖЫМ – русча «озимь» сүзеннән. «Көзен чәчелеп, шытып чыгып кар астында кышлый торган берьеллык иген» («Татар теленең аңлатмалы сүзлеге»ннән). // *Уҗым бодае* – кышлау бодай (*диал.*, русча – *озимая пшеница*). Бу культура Татарстан шартларында иң уңдырышлысы исәпләнә. *Уҗым арышы* – Татарстанның төньяк районнарында чәчүлекләрнең күпчелек өлешен тәшкил итә торган культура. Бездә бөртекле ашлык уңышының 15-20%ы уҗым арышына туры килә.

Яңа үсеп килә торган игенне дә *уҗым* дип атыйлар.

Күп кенә игенчелек атамаларының татар теленә рус теленнән кергәнлеген танырга кирәк.

УКАЗЛЫ МУЛЛА – имамлыкка имтихан тотып, мөфтияттә шаһадәтнамә алган зат – *мәншүрле мулла*. *«Указлы мөәззин»* төшенчәсе дә булган. //*Үзе указлы мулла булмаса да, зур укыган кеше булганга, аннан соң балалар да укыткан-га, аның әтисен авылда «Насыйр мулла» дип йөртәләр.* М.Гали.

Дәвамы. 2014 елның 3 нче саныннан басылып килә.

Безнең мирас №5 май 2018

УКЛАУ – камыр җәю өчен хезмәт итә торган корал. Чыгтай телендә *уклагу* – цилиндр, борынгы төркичәдә *окла* фигыле җәймә җәюне белдерә. Р.Әхмәтҗанов: «Борынгы заманда уклау урынына ук сүзе кулланылмадымы икән?» – дигән сорау куя. Электә керне тигезләү өчен уклау һәм сырлы бәләк хезмәт иткән. Ләкин шуны да әйтик, җәймә җәю өчен ук сабагы артык нечкә, бу эш өчен уңайсыз һәм нәтиҗәле түгел. *//Сабан уклавы* – грядиль (русча); вәлүк. *Уклау сыман* – цилиндрик.

Техника терминологиясендә уклау – русча *вал, валик* (мәс., табаклы металл җәю станнарында). *//Алгы цехта, /юан корыч уклау /Калай җәя кызыл тимердән.* Х.Туфан.

Укчылар полкы гаскәриләре

УКУ – гомумтөрки *окы* – «кычкырып эндәшү, кычкырып өндәү; җырлау» сүзеннән дип карала. *«Рәхмәт уку, ләгънәт уку* кебек тәгъбирләрдә дә уку сүзенең шул «кычкырып әйтү» мәгънәсе саклана». (Р.Әхмәтҗанов.) «Мәктәптә уку», «өйрәнү», «оту» мәгънәсе соңрак өстәлгән. Фәнни әдәбиятта татарча *уку* сүзе белән рус телендәге *наука* (фән, гыйлем) сүзе арасында параллель барлыгы искәртелә (мәс., Риза Газизовта). Бу фикерне өстәмә дәлилләү сорала. *//Укымак – яктының караңгыны җиңүләренә иң үткен коралдыр.* Тукай. *Укудан туктаган кеше уйлаудан да туктый.* Дени Дидро. *Артык күп укуга караганда, мәгънәсенә төшенеп уку яхшырак. Китапны «су кебек» эчүдә әллә ни мәгънә юк.* Н. Крупская.

УКЧЫ – 1. Ук атучы; хәзерге мәгънәсе – гомумән утлы корал белән коралланган гаскәри. Русча – *стрелец*. Гарәпчә – *рами*. Русиядә беренче укчылар полкы («стрелецкий полк») Явыз Иван заманында барлыкка килә (1550 нче еллар). Ул вакытларда *мылтык-пищальләр* белән коралланган бу полкны *приказ* дип атап йөрткәннәр, приказны *голова* (хәзергечә – полковник) җитәкләгән. Укчылар гомер буе хәрби хезмәттә булганнар, аларның уллары да хәрби исәптә торган. *//Йадаг окчы* – җәяүле укчы. «Котадгу белек»тән. 2. Ук ясаучы, каувас/кавәс. 3. Зодиак йолдызлыкларыннан берсе. Башкача: *Җәя, Кавәс*. Борынгы төркичәдә – *Йап*.

ХА́РАМ г. – «Изге» мәгънәсендәге бу сүзне татар телендә «тыелган» мәгънәсендәге «хәрәм»/«хәрам» сүзе белән бутамаска кирәк, «ха́рам» сүзендә басым беренче иҗеккә төшереп әйтелә. «Харам» атамасын Мәккә белән Мәдинә шәһәрләренә карата кулланалар. Мәс., электә Мәккә шәһәре (Кәгъбә һәм якынтирәдәге табыну урыннары белән бергә) көнчыгыш вә көнбатышка таба 15-18 километрга һәм көньяк вә төньякка таба 8-10 километрга изге территория дип исәпләнгән. Монда бөтен тереклек ияләре аллалар химаясендә торган, кан коярга ярамаган, хәтта сунарчылык та тыелган (ләкин бу кагыйдә корбан чалуга һәм харамда яшәүчеләр өчен мал суюга кагылмаган). Ә ха́рамның чикләре махсус ташлар белән билгеләнгән була. Чыганакларда мондый урыннар *«хима»* дип тә телгә алына. ■

Татарстан Республикасының Милли китапханәсе

КОРЪӘН ТУПЛАНМАСЫ

Милли китапханәбездә кульязма һәм сирәк китаплар бүлегенең җәүһәри кыйммәткә ия байлыгы – Коръән тупланмасы. Бу изге эшнең бисмилласы 1996 елда башланды. Хәзерге көндә инде 200 берәмлектән артык басма Коръәнебез бар. Тупланмага тәфсирләр, төрле телләргә тәрҗемә ителгән нөсхәләр (татар, рус, фарсы, башкорт, төрек, инглиз, француз, алман, урду, үзбәк, азәрбайҗан, казакъ һ.б.), аудио һәм авазлы башка төр электрон язмалар да керә.

*Дәвамы. Башы журналның 2017 елгы 10 нчы санында.



Казан ханлыгы чорында китап күчереп язу үзе бер һөнәргә әйләнгән, бу чорда китап күчереп язучылар мәктәбе дә яшәп килгән. Китап күчереп язу киң таралган, профессиягә әйләнгән. Хәтта Казанда хәреф җыеп китап басу ысулы барлыкка килгәч тә, XIX гасыр дәвамында кулдан күчереп китап язу тукталмаган, меңнәрчә кулъязма китаплар барлыкка килгән.

Әбрар Кәримуллин

Тупланмада хаттатлар күчереп язган кулъязма Коръәннәр һәм дөньяның төрле почмакларында басылган нөсхәләр бар. Тупланмадагы Коръәннәрнең иң борынгы кулъязма нөсхәсе 1699 елга туры килә. Дөньяның төрле кыйтгаларында һәм илләрендә (Россия, Төркия, Иран, Согуд Гарәбстаны һ.б.) типография ысулы белән басылган Коръәннәр тупланманың зур бер өлешен тәшкил итә. Революциягә кадәр дөнья күргән, мөселман халыкларында «Казан басмасы» дип дан алган Изге Китап һәм шулай ук Казанда басылган тәфсирләр инде күз карасы кебек сакларлык бик аз калганнар. Шундыйлардан Мөхәммәтсадыйк Иманколый тәфсирен һәм Ногман бине Госманныкын («Ногмани

Безнең мирас №5 май 2018





Коръән

И Бөек Китап икән бу –
Аңлының аңы кебек.
И моңлы Китап икән бу –
Татарның җаны кебек.
И төзек, матур өй, дисәм,
Бу гына бик аз булыр.
Ул – галәмнәрнең галәме,
Тәрбияви наз булыр.

Бикә Рәхимова

тәфсире») мисалга китереп була. Согуд Гарәбстанында, Брайль системасы шрифтын кулланып, сукырлар өчен махсус басылган Коръән – уникаль басма.

Тупланманы И.Ю.Крачковский, Г.С.Саблуков, Р.Батулла, Ф.Сәлман, Д.Н.Богуславский, М.-Н.О.Османов, В.Порохова һ.б. башкарып чыккан Коръән тәрҗемәләре һәм тәфсирләре тулыландыра.

Мөселманнарның Изге Китабы – Коръән Кәримнең һәрберсе, полиграфик яктан кабатланмыйча, гаҗәеп бизәлгән тышлыкта, гасырлар зилзиләсенә бирешмәслек затлы кәгазьдә, гарәп язуының сәнгати югарылыгын тантана итеп бастырылганнар. Могҗиза бит, керфеккә куйсаң, тирбәлеп торырлык иң нәни Коръән дә бар! Аның иңе – 1, буе – 2 см. Ә иң зурысының үлчәме – 35х50 см.

Иң мөһиме – тупланмабыз яңадан-яңа басмаларга елдан-ел баеый бара.

Гомернең иң читен, җайсыз, уңайсыз бер минутында,
Әгәр янсам каты хәсрәт вә кайгының мин утында,
Укыйм тиз-тиз күңелдән гаҗаиб сүрә Коръәннән, –
Газаплар мәгънәви бер кул илән алынадыр җаннан.
Оча дилдән бөтен шик-шөһбәләр һәм мин җылый башлыйм:
Яңакларны мөкатдәс күз яше илә энҗели башлыйм.
Бөтенләй сафлана күңелем; укыйм иман, булам мөэмин.
Килә рәхәт, җиңеллекләр, хәлас булам, авыр йөкдин.
Ходаем! Син тыйган эшләр тәмам әкътаг вә әбтәр дим;
Иям баш сәҗдәгә: «Аллаһу Хак! Аллаһы әкбәр!» – дим.

Габдулла Тукай



Тормышта китаптан да тугрылыклырак юлдаш булуы мөмкин түгел. Ул – беркайчан да «сатмый» һәм хыянәт итми торган дус-иптәш. Ул – авыр минутларда ышанычлы ярдәмче дә, салулап-таеп киткән чакларда ышанычлы таяныч та, җан җылысы да. Ялгыз калганда исә эчкерсез киңәшче дә.

Әхәт Мушинский ■

ЗАТЛЫ КИТАП

«Татарский Геродот»... Халкыбызның бөек улы, атаклы дин галиме, тарихчы Шиһабетдин Мәрҗанинең тууына 200 ел тулу уңаеннан чыгарылган китап шул исем белән атала. Әлеге җыентыкның беренче бүлегендә олуг галимнең тормыш юлы, аның турында революциягә кадәр язган ***Шәһер Шәрәф, Кәшшаф Тәрҗемани, Галимҗан Баруди, Ризаэддин Фәхреддин, Йосыф Акчура, Һади Атласи, Морад Рәмзи, Хәсәнгата Гобәши һәм Әхмәтзәки Вәлиди*** *кебек шәхесләрнең истәлек-хатирәләре, гыйльми хезмәтләре турында фикер-карашлары рус теленә тәрҗемәдә бирелгән.*

Китапның икенче өлешендә хәзерге заман галимнәре **Айдар Хәбетдинов, Радик Салихов, Дамир Шаһавиев, Айдар Юзиев, Людмила Жуковская** һәм башкаларның Ш.Мәрҗани турындагы фәнни мәкаләләре тупланган. Өченче кисәк – Шиһабетдин Мәрҗани исемен сүз, фәнни мәкалә белән генә түгел, ә гамәли

Татарский Геродот.
К 200-летию со дня рождения Шигабутдина Марджани / Казань: Издательский дом Маковского,
2017. - 416 с.



эш белән дә мәңгеләштергән «ТАТТЕЛЕКОМ» АҖ егетләренең хезмәте, алар башкарган проектлар турында. Биредә Әтнә районының Ябынчы авылындагы Мәрҗаниләр нигез-комплексы һәм коесы, Арча районы Ташкичү авылында Мәрҗаниләргә багышланган мемориаль һәйкәлләр, музей һәм чишмә, Югары Курса авылында Габденнасыйр Курсави мемориаль һәйкәле һәм чишмәсе, галимнең Яңа татар бистәсе зиратындагы кабер ташы, Симетбаш авылында Шиһаб хәзрәтнең 200 еллыгына ачылган «Нурислам» мәчете турында укып белергә, бу объектларны төзекләндерү яки төзелеш процессы һәм аларны тантаналы ачу мәрасименең фотолары белән танышырга мөмкин. Шунысы да игътибарга лаек: 1915 елда Шиһабетдин Мәрҗанинең тууына 100 ел тулу уңаеннан чыгарылган «Мәрҗани» китабының иганәчесе Арча төбәгеннән чыккан сәүдәгәр, хәйрияче **Салих Гобәйдуллин** булса, 200 ел тулу уңаеннан дөнья күргән китапның да идея авторы – Арча районы Симетбаш авылы егете, «ТАТТЕЛЕКОМ» АҖнең генераль директоры **Лотфулла Шәфигуллин**. ■

КУКМАРА МИРАСЫ

Киез итекләр иле

Әгәр Кукмараны үзенә күрә бер кечкенә ил дип гоман кылсак, аны, һичбер икеләнүсез, «Киез итекләр иле» дип йөртергә булыр иде.

«БЕРТУГАН РОДИГИННАР» ШИРКӘТЕ

1897 елда Кукмарада бертуган Родигиннар үз ширкәтләрен булдыра. Комаровныкылардан кала икенче урынга дәгъва иткән әлеге ширкәтне өч бертуган – Михаил, Иван һәм Николай җитәкли. Аңарчы алар, Комаровлар шикелле, киез итек басу эшен 1878 елда кечкенә авылларда башлап җибәрә. 1890 елда Иван һәм Николай Родигиннарның һөнәрханәсендә 45 мең сумлык 20 мең пар киез ката әзерләнә. Бу эшне 100 кеше башкара. Аларның уртача хезмәт хакы унике сум була.

Фабрика-сәүдә ширкәте оешканга кадәр, бертуган Родигиннарның өченчесе – Михаил дигәне үз эшен аерым алып бара. 1890 елда аның Рудниктагы һөнәрханәсендә 15 эшче бер елга 2000 сумлык 1000 пар киез итек баса.

1894 елның 14 маенда бертуган Родигиннар берләшеп эшли башлый. Иң әүвәл алар Кукмара авылында киез итек фабрикасы төзү өчен Мамадыш купецы Самарцевтан җир

«Бертуган Родигиннар» фабрика-сәүдә ширкәтенең фирма бланкысы

Иван Дмитриевич һәм Михаил Дмитриевич Родигиннар

кишәрлеге сатып ала. 1897 елда ике катлы бина төзелеп бетә. 1909 елда инде бертуган Родигиннарның Кукмара һәм Рудниктагы фабрикалары зур табыш китереп эшли.

«Бертуган Родигиннар» ширкәтенең идарәсе Кукмарада урнашкан була. Николай Дмитриевич – идарә рәисе (управляющий), Михаил Дмитриевич исә директор-җитәкче вазыйфасын башкара. Ширкәтнең вәкиллекләре Казанда һәм Мәскәүдә эшли.

1914 елның февралендә Родигиннарның Кукмара авылындагы фабрикасында 468 кеше хезмәт куйганлыгы мәгълүм.

Фабриканың Кукмарадагы биналары бер-берсенә бик якын, әйтик, чиркәүнең уң һәм сул якларында урнашкан була. Бер бинада исә һәркем өчен ачык булган китапханә эшли. Бүгенге көндә бу биналарда Туган якны өйрәнү музее, киез-киез итек комбинаты һәм «Хыял» тегү фабрикасының тулай торагы урнашкан.

Фабрикант Родигиннар эшчеләр мәнфәгатен кайгыртып та йортлар төзеткән. 1908 елда фабрика биләмәсендә өстәмә такта корылмалар белән бергә агач йорт салына. 1910 елда агач мунча, кое һәм азык-төлек саклау өчен базы да булган ашханә файдалануга тапшырыла.

1914 елда фабрикада җәмгысы 259 эшче исәпләнә. Эш көне ун сәгать була. Айга 25 көн эшлиләр. Эшчеләрнең айлык эш хакы 8-10 сум тәшкил иткән. Чималны Түбән Нов-

Бертуган Родигиннар фабрикасының элекке бинасы. 1960 нчы еллар. Р.Нигъмәтҗанов фотосы

город ярминкәсеннән, Сарапул һәм Нолинск шәһәрләреннән сатып алып кайтканнар.

Бертуган Родигиннар бертуган Комаровлар белән ярышып эшләгән, дияргә тулы нигез бар: алар да фабриканы киңәйтүгә, товарларның сыйфатын яхшыртуга зур игътибар биргән, төрле ярминкәләрдә, Бөтендөнья һәм Бөтенроссия күргәзмәләрендә катнашкан. «Бертуган Родигиннар» ширкәте Брюссель (1905), Санкт-Петербург (1906), Ростов-Дон (1907), Екатеринбург (1887) һәм Казанда (1890) узган күргәзмәләрдән алтын медаль алып кайткан.

Бертуган Родигиннар турында әллә ни мәгълүмат сакланмаган. Михаил Дмитриевич Родигинның гаиләсе белән хәзер «Хыял» тегү фабрикасы урнашкан йортта яшәгәнлеге билгеле. Михаил Дмитриевич 1912 елда вафат була. Кукмара зиратында җирләнә. Аның кабере өстендә гранит таш куелган. Иван Дмитриевич Родигин исә 1910 елда үлә. Николай Иванович Родигин турында әлегә бернинди мәгълүмат та юк.

Родигиннар эшен дәвам итүчеләрнең берсе – Александр Иванович Родигин. Аның кискен үзгәреш кичергән тормышы ул заманда яшәгән бик күп фабрикантларныкына охшаш. А.И.Родигин 1894 елның 30 июнендә туган. Казан гимназияләренең берсендә биш сыйныф тәмамлый (1911), Мәскәүдә укуын дәвам итә. 1918 елга кадәр «Бертуган Родигиннар» ширкәтенең уртак милектәше була. 1918 елда аны Мамадыш чекистла-

Шамил Михәйдәр улы Әхмәтшин (1954-2017), «Кукмара киез-киез итек комбинаты»ның 1988-2017 еллардагы генераль директоры:

«Тарихны кайтарырга беркайчан да соң түгел. Без бертуган Комаровларны да, Кукмара тарихында якты эз калдырган башка фабрикантларны да истән чыгармаска тиеш!»

Бертуган Родигиннар фабрикасының бер бинасы. Хәзер монда Кукмара туган якны өйрәнү музее урнашкан

Бертуган Родигиннар фабрикасының икенче бинасы

ры кулга ала. Элекке хуҗасын бу вакытта завод-фабрика комитеты рәисе булып алган Фёдор Мастряков коткарып өлгерә: ул, Александр Ивановичны азат итүләрен сорап, фабрика эшчеләре исеменнән чекистларга үтенеч белән мөрәҗәгать итә. А.И.Родигин 1918 елның сентябреннән 1919 елның гыйнварына хәтле үз фабрикасында мөдир булып эшли. Шул ук елның маенда Кызыл Армия сафларына алына. 1921 елның октябрендә армиядән азат ителеп, Кукмарага – кабат үз фабрикасына эшкә кайта һәм шунда мөдир вазыйфасын башкара.

*Язманы **Ләбиб Лерон** әзерләде.* ■

М.Д.Родигин кабере. Кукмара зираты

АПРЕЛЬ

Фотолар һәм видео beznenmiras.ru сайтында

● Апрель башында Хабаровскида Татар яшьләре үзәгенең «Сәлам» театр төркеме драматаург Рәдиф Сәгъди әсәре буенча куелган «Баһадир бәхете» спектаклен (режиссеры – Наил Арсланов) сәхнәләштерде.

● 2 апрельдә Чаллының 54 нче мәктәбендә «Илһам» Бөтенроссия бәйгесенә нисбәтле чара узды. Анда жюри әгъзалары – язучылар Ркаил Зәйдулла, Сирень Якупова һәм Ләбиб Лерон катнашты.

● 3 апрельдә Арчада, жюри әгъзалары Васил Гарифуллин, Гөлзадә Бәйрәмова һәм Ләбиб Лерон катнашында, «Илһам» Бөтенроссия бәйгесенә нисбәтле чара үтте.

● 5 апрельдә «Безнең мирас» журналы авторы, күптән түгел генә Әгерҗедә 90 яшен киң җәмәгатьчелек белән бергә бәйрәм иткән аксакал әдип Габдулла ага Галиев кинәт вафат булды. Мәрхүмнең җәсәде 6 мартта Кырынды авылы зиратында җирләнде. Бисмилләәһир-рахмәәнир-рахиим! Иннә лилләһи үә иннә иләйһи раҗигун!

● 5 апрельдә Кукмарадагы Үзәк мәчеттә вәгазь кичәсе үтте. Чарада «Мөхәммәдия» мәдрәсәсенең уку-укыту бүлеге мөдире – мөдәррис Зөлфәт хәзрәт Габдуллин вәгазь сөйләде.

● 6 апрельдә Татарстан мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин Казан шәһәрендә салынырга тиешле «Җомга» мәчетенең эскиз-проектын хуплады. Очрашуда «Өмет йолдызы» хәйрия фонды президенты Миңнегол Сафин һәм төзеләчәк мәчетнең имамы Равил хәзрәт Вәлиев әлеге проект турында мәгълүмат бирде.

● 6 апрельдә «Безнең мирас»ның даими авторы, табиб һәм җәмәгать эшлеклесе Морат ага Кәримов фатирында, күренекле галим Хатыйп Миңнегулов, Казакъстандагы «Идел» татар һәм

татар-башкорт иҗтимагый-мәдәни үзәге президенты Габделхәй Ишморатов һәм «Безнең мирас» журналының баш мөхәррире Ләбиб Лерон катнашында, тугандаш татар һәм казакъ халыкларының үзара мөнәсәбәтләренә нисбәтле сөйләшү булды.

● 7 апрельдә Чаллыда Татарстан Республикасы мөселманнарының диния нәзарәте кубогына татарча көрәш һәм кул көрәше буенча X Мөселман яшьләренең берләшкән турниры тәмамланды. Диния нәзарәте кубогына Әлмәт командасы лаек булды.

● 8 апрельдә Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясенең гамәлгә куелуына (1958) 60 ел тулды. Кырык ел элек (1978), «Шигырьләр һәм поэмалар» китабы (1976) өчен шагыйрь Равил Фәйзуллинга әлеге мәртәбәле премия бирелде.

● 9 апрельдә Г.Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрында Татарстанның һәм Россиянең халык артисты Равил Шәрәфиевкә 80 яшь тулу уңаеннан юбилей кичәсе үтте.

● 10 апрельдә татар зыялылары күренекле артист, нәфис сүз остасы Айрат Арслановның каберен зыярәт кылды.

● 11 апрельдә Мамадышта Татарстанның халык язучысы Рабит Батулла, Татарстанның халык артисты Миңгол Галиев, 91 яшьлек ветеран-шагыйрь Вахит Галиев, «Безнең мирас» һәм «Казан утлары» журналларының баш мөхәррирләре Ләбиб Лерон, Рөстәм Галиуллин район хакимияте башлыгы А.П.Иванов белән очрашты. Шул ук көнне алар районның үзәк китапханәсендә һәм 4 нче мәктәптә узган очрашуларда да катнашты.

● 12 апрельдә Арчаның Яңа Кырлай авылында нәүбәттәге VII Республикакүләм «Габдулла Тукай укулары» узды. Әлеге чарада язучылар Вакыйф Нуриев, Рифат Җамал, «Безнең мирас» журналының баш мөхәррире Ләбиб Лерон, «Мәгариф» журналының баш мөхәррир урынбасары Сиринә Мөхәммәтҗанова, филология фәннәре кандидаты Рәсимә Шәмсетдинова, «Казан арты» тарих-этнография музее директоры урынбасары Шәфигулла Гарипов, Татарстанның атказанган укытучысы Фәргать Зыятов, әдәбият белгечләре Рәмзия Хәлиуллина белән Алисә Заһретдинова һ.б. катнашты.

● 23 апрельдә Г.Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрында күренекле шагыйрә Эльмира Шәрифуллинаның «Без – Тукайлы халык!» дип исемләнгән юбилей кичәсе булып узды.

● 23 апрельдә Казандагы Милли-мәдәни үзәктә Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты, шагыйрь Ркаил Зәйдулланың «Янды сөю чатырлары» дигән китабы нәшер ителү уңаеннан әдәби-музыкаль кичә үтте. ■

Мирасворд

Рәис Габдулла төзеде.

Әмир, кенәз

Чатыр тавы белән мәшһүр район

Кайсын Кулиевның милләте

Болытсыз, явым-төшемсез

Гази ... (әдәбият галиме, тәнкыйтьче)

«Ялт - ...» журналы (Казан, 1910-1918)

Язучы ... Фәизов

Скиф кылычы

Ашарга яраклы үлән

Бу, шушы (иск.)

Йолдыз-намә билгесе

Язучы ... Тимби-кова

Ат кыргычы (диал.)

Атлы гаскәри (бор.)

Шәһиди, Шәрәф

Бер өркәчле дөя

Жак - ... Кусто

Җырларга кергән елга

Аш пешерүче (бор.)

Борынгы әрмән каласы

Такта шомарту коралы

Борынгы Болгар дәүләте, Казан ханлыгында кече офицер

Юкәдән үрелгән кәрзин (диал.)

Ирексез кеше

Такташ, Атласи

Әдәби әсәр, китап бүлеге

Алдан бара торган гаскәр, авангард (бор.)

Эре сөякле, зур (диал.)

Кубрат, Олуг Мөхәммәд, Чыңгыз

... де Бальзак

Җирле, төп халык (бор.)

Граж-даннар сугышы герое

Бөек, атаклы

Аяз Гыйләҗев повесте

Бәхет (иск.)

Башкорт телендә чыгучы юмор-сатира журналы

Зәя кушылдыгы

Морза

Язучы ... Хафизова

Иртешнең сул кушылдыгы

Шарт теркәгече

4 нче санда дөнья күргән мирасвордның җаваплары:
Сулдан уңга: Азат, ро, Агиев, Блок, «Ант», колт, майор, ал, «Сайфия», атлату, терчә, шатлану, ышкы, «Тәфтиләү», Гали, фирн, Апуш, Хәсән, «Афәт», намә, Рог, Әлмән.
Өстән аска: «Сабыйга», «Золым», ап, аел, улак, Тукай, ашы, ишан, оста, Фаил, раут, «Әлхәм», әрәтә, тафта, он, Галлиен, Гарәфи, Рино, Яруллин, оеткы, әр, Зәйтүнә.

Башкалабыз Казан шәһәрендә Мулланур Вахитовка куелган һәйкәл. 1985 елның 22 августында ачыла.

«БЕЗНЕҢ МИРАС» ЕЛЪЯЗМАСЫ / МАЙ

• 795 ел элек (1223)

31 майда Чыңгызханның Сүбәдәй баһадир һәм Җибә нойон җитәкчелегендәге гаскәре, Калка елгасы буенда урыс дружиналарын пыран-заран китереп, җиңүгә ирешә.

• 145 ел элек (1873)

Шагыйрь, тәрҗемәче, мәгърифәтче Даут Гобәйдулла улы Гобәйди (1873-1919) дөньяга килә.1919 елның апрель башларында Колчак гаскәриләре шагыйрьне кулга алалар һәм җәзалап үтерәләр.

• 100 ел элек (1918)

10-17 майда Татар-Башкорт Советлар республикасын оештыру корылтаен җыю хакында Мәскәүдә киңәшмә уздырыла. Аны кереш сүз белән Милли эшләр халык комиссары Иосиф Сталин ача. Киңәшмәдә Мулланур Вахитов, Галимҗан Ибраһимов һәм Камил Якупов катнаша һәм чыгыш ясый.

Сембердә (хәзерге Ульяновск) татар телендә большевистик «Көн» газетасы нәшер ителә башлый.

• 95 ел элек (1923)

15 майда Царицында (хәзерге Волгоград) әдәби һәм сәяси «Чаткы» журналының тәүге саны чыга.

30 майда Казанда, татар халкының мәдәниятен өйрәнү өчен, Татарстанны фәнни өйрәнү җәмгыяте төзелә.

• 80 ел элек (1938)

«Татарстан Республикасы матбугат елъязмасы» исемле дәүләт библиографик күрсәткече чыга башлый.

• 75 ел элек (1943)

19 майда Көньяк-Көнбатыш (III Украина) фронтында «Совет сугышчысы» исемле татарча газета редакциясе оештырыла. Газетаның редактор урынбасары – Мәхмүд Максуд, хәрби хәбәрчесе – Мостай Кәрим.

• 65 ел элек (1953)

«Совет әдәбияты» журналында Муса Җәлилнең тоткынлыкта язылган шигырьләре басыла башлый.

• 50 ел элек (1968)

«Казан утлары» журналында Мөхәммәт Мәһдиевнең «Без – кырык беренче ел балалары» повесте дөнья күрә.

• 25 ел элек (1993)

26-29 майда Төркиянең Кайсәри каласында Әхмәт Ясәвинең тууына 900 ел тулуга багышланган Халыкара җыен үткәрелә.Анда башкалабыз Казаннан галим һәм әдип Әбрар Кәримуллин катнаша һәм нотык тота.

Уфада «Татар морзалары мәҗлесе»нең чираттагы җыелышы уза, биредә, махсус чакыру буенча, Әмирхан Еники катнаша.

Журналга ***Айдар Закиров*** әзерләде. ■



СОДЕРЖАНИЕ. МАЙ 2018

Историческое наследие: «Нурсултан». О.Иванова; «Каляме Шариф» или «Калям Шариф»?» А.Хайрутдин; «Древная ценность Старых Жори». И.Хадиев, Р.Марданов; «Великий Мухаммад». М.Амирханов; «Книга, написанная народом». Э.Ихсанова; «Яуширма с тысячелетней историей». Н.Фатихова-Потеева; «Суп по-немецки». Э.Салахова; «Аутодафе в Российском государстве». Р.Фахретдинов; «Маргарет ханум». С.Цвиклински.

Тюркский мир: «Великий сын казахского народа».

Религиозное наследие: «Исламский мир». Г.Ибрагимов; «Молитва по случаю проводов на поломничество». Дж. Фазлыев.

Литературное наследие: «Аяз Гилязов и я». Ф.Кутлу; «Два заявления Булата Сулейманова». Л.Лерон.

В глубине памяти: «Поэт Макс Гатау и его родная деревня Тозау».; «В памяти, до сих пор в памяти!»

Художественное наследие: «Немного о себе». Р.Шарафи; «По-настоящему творческий человек». Ю.Сафиуллин.

Перебирая музыкальное наследие: «Странствуя вслед за песнями...» Э.Каюмова.

Эхо войны: «Миргазиз – дедушка солдат». А.Гадельша; «Пережитое моим отцом». Х.Закиров.

На страже памяти: «Национальная библиотека Республики Татарстан»; «Изящная книга»; «Страна валенок». Л.Лерон.

Журнал регулярно освещает все значимые события в жизни нашей нации.

CONTENT. MAY 2018

Historic heritage: «Nursultan» by O.Ivanova; «Kalyame Sharif or Kalyam Sharif?» by A.Khairutdin; «The ancient treasure of Djori village» by I.Khadiev, R.Mardanov; «The Great Mukhammad» by M.Amirkhanov; «The book written by people» by E.Ikhsanova; «Yaushirma village with 1000 years' history» by N.Fatikhova-Poteeva; «Soup prepared in By German traditions» by E.Salakhova; «Auto-da-fe in the Russian state» By R.Fakhretdinov; «Margareth khanum» by S. Tsviklinski.

Turkic world: «The great son of epy Cossack people».

Religious heritage: «Islamic world» by G.Ibragimov; «The prayer for sending off the pilgrims» by J.Fazliev.

Literary heritage: «Ayaz Gilyazov and me» by F.Kutlu; «Two appeals of Bulat Suleymanov» by L.Leron.

From the deepest storage of memory: «The poet Max Gatau and native village Tozay»; «Keeping in mind, still keeping!».

Creative heritage: «Something about myself» by R.Sharafi; «He is really a creative man» by U.Safiullin.

Sorting out musical heritage: «Travelling after the songs...» by E.Kayumova.

The war's echo: «The old man soldier Mirgaziz» by A.Gadelsha; «The experience lived through by my father» by Kh.Zakirov.

On the guard of the memory: «The National library of the Republic of Tatarstan»; «The precious book»; «The felt-boots country» by L.Leron.

The magazine constantly brings to light all the most important events of our nation life.

Яулар кичкән әдипләр – хәтеребез түрендә!

1985 елның маенда язучыларның Г.Тукай исемендәге клубында (Бауман урамы, 19 нчы йорт) сурәткә бергәләп төшкән әлеге әдипләребезнең бүген берсе дә исән түгел инде... Әйдәгез, ошбу күренекле шәхесләребезне искә алып, аларның бай мирас булып калган күркәм әсәрләрен кабат хәтеребездә яңартыйк әле...

Рәсемдә: беренче рәттә (сулдан уңга) – **Нури Арслан, ..., Мөхәммәд Садри, Риза Ишморат, Әхмәт Исхак, Гариф Галиев, Хатип Госман, Салих Баттал;**
икенче рәттә – **Шамил Шаһгали, Әмирхан Еники, Мөнир Мазунов, Мәхмүт Хөсәен, Ибраһим Нуруллин, Атилла Расих, Сафа Сабиров, Әбрар Кәримуллин, Баян Гыйззәт;**
өченче рәттә – **Нәби Дәүли, Сәет Шәкүров, Әдип Маликов, Кави Латыйп, Мәгъсүм Насыйбуллин, Маннур Саттаров.**

«Татар аты».
Рәдиф Сәгъди

АЛДАГЫ САНДА УКЫГЫЗ:

Диване лөгатет-төрек – тарихи чыганак. Иршад Гафаров
Якташларым – онытылган сугышта. Әнәс Сафуанов
Сандугач. Габдулла Галиев
Мәчти авылы тарихы. Дәлия Ханнанова
Татар аты. Рәдиф Сәгъди
Галимҗан Ибраһимов онышы. Фәнис Фәтхи

ИНДЕКС:
ТАТАРСТАНДА – 54132 (П-2343)
РОССИЯДӘ – 70275
www.beznenmiras.ru

«БЕЗНЕҢ МИРАС» журналына башкача язылу:
- *www.uslugi.tatarstan.ru сайты ярдәмендә*
- *редакциядә*
- *www.tatpodpiska.ru сайты ярдәмендә электрон версия*

4 612750 670172

«БЕЗНЕҢ МИРАС» журналын башкалабыз Казандагы «Книги-Китаплар» кибетеннән (Бауман ур., 19 һәм 29/11), «ТАТМЕДИА» бинасының китап кибетеннән (Декабристлар ур., 2), республикабыз киоскларыннан сатып алырга мөмкин.